Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты

'21 Год науки и технологий

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ
И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
2021
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ
ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

# ТАТАР ТӘРБИЯСЕ

## Г. Биктимерия һәм Ф. Сөләймания
## ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ
## гаилә тәрбиясе мәсьәләләре

Казан – 2021

УДК 396.4 (376.72)
ББК 74.03 (2)
Т 23

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Ш.Мәрҗани исем.Тарих институты
Гыйльми советы карары нигезендә басыла*

«ТАТАР ТӘРБИЯСЕ» сериясе

**Фәнни редактор**
*М.М. Гибатдинов*

**Рецензентлар:**
*Л.Р. Габдрафикова*, тарих фәннәре докторы
*Р.А. Гыймазова*, тарих фәннәре кандидаты

Т 23 **ТАТАР ТӘРБИЯСЕ: Г. Биктимерия һәм Ф. Сөләймания хезмәтләрендә гаилә тәрбиясе мәсьәләләре** / төзүче-авторлар *Мортазина Л.Р., Зиннәтуллина А.Ә.* – Казан: ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты, 2021. – 232 б.

ISBN 978-5-94981-366-9

«Татар тәрбиясе» сериясеннән тәкъдим ителгән әлеге җыентыкта күренекле мәгърифәтчеләр Г.Биктимерия һәм Ф.Сөләйманиянең XIX–XX гасырлар чигендә дөнья күргән, хатын-кызның гаиләдәге урыны, гаилә тәрбиясенең үзенчәлекләренә багышланган китаплары туплап бирелде.

Хезмәт XX гасыр башы татар мәгарифе тарихы, хатын-кыз мәгърифәтчеләр һәм аларның иҗаты, татар халкының көнкүреш тарихы мәсьәләләре белән кызыксынучыларга, педагогларга тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-94981-366-9 УДК 396.4 (376.72)
ББК 74.03 (2)

© Мортазина Л.Р., Зиннәтуллина А.Ә., 2021
© ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты, 2021

# *«ГАИЛӘНЕҢ БӘХЕТ ВӘ СӘГАДӘТЛӘРЕ ХАТЫННАРНЫҢ ГАКЫЛЛЫ ВӘ ГЫЙЛЕМЛЕ БУЛУЛАРЫНА БАГЛАНМЫШТЫР»*

XIX гасырның ахырында татар җәмгыятендә, мәдәният һәм мәгърифәт үсешендә күзәтелгән яңарыш, милли уяну хәрәкәте хатын-кызларга да хәлиткеч тәэсир итә. Татар ханымнары, Р.Фәхреддин, И.Гаспралы кебек мәшһүр фикер ияләренең хезмәтләрендә күтәрелгән фикерләр белән рухланып, хатын-кызларның азатлыгы, җәмгыятьтәге һәм гаиләдәге урыннары, тигез хокуклылыгы өчен көрәш юлына басалар. «Бер милләтнең тәрәккые хатыннарның мәгариф юлына кертелүеннән башка мөмкин түгеллеген бәян иткән»[1] И.Гаспралының фикерләре татар хатын-кызлары өчен төп таяныч булып хезмәт иткән. Хатын-кызлар өчен ачылган яңа, җәдиди мәктәпләрдә, заманча укыту белән беррәттән, хатын-кызны яңа шартларда яшәргә өйрәтүгә, аларга тәрбия бирүгә зур игътибар бирелгән.

Хатын-кыз мәсьәләсе XX гасыр башы татар матбугатында күтәрелгән иң мөһим проблемаларның берсе булып әверелә. Күренекле мәгърифәтчеләр, педагоглар, мөгаллим-мөгаллимәләр генә түгел, хатын-кызлар, мәктәпләрдә укучы шәкерт кызлар, аларның әниләре, тута-сеңелләре һәмширәләренең – кыз кардәшләренең тормыштагы хәленә, яшәешенә битараф кала алмаганнар, хатын-кызга белем һәм тәрбия бирүнең әһәмиятен ассызыклаган мәкаләләре белән чыгыш ясаганнар. Татар вакытлы матбугатында дөнья күргән язмаларда хатын-кыз дөньясына караган бик күп проблемалар күтәрелгән. Фәхрелбәнат Сөләймания, Маһруй Мозаффария, Камилә Мозаффария, Багбостан Мөэминова, Сания Гыйффәт, Хәтимә-Нәзифә, Гайшә Абызгилдина, Фатыйма-Фәридә Нәүрузова, Фәүзия Ибраһимова кебек атаклы педагоглар,

---

[1] Ф.К. Һиндыстанда беренче ысул саутия мәктәбе // Вакыт. 1912. 29 март.

журналистлар хатын-кызларның аянычлы язмышларын, проблемаларын, зар-моңнарын, авыр тормышларын тасвирлаганнар, бу хәлдән чыгу юлларын эзләгәннәр[2]. Мәгърифәтчеләр хатын-кызның гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге хәлен яхшырту, хокукларын яклау һ.б. бик күп мәсьәләләрне хәл итүдә төп юлны хатын-кызларны мәгърифәтле итү, аң-белем тарату, тәрбияләүдә күргәннәр. Аларның фикеренчә, хатын-кыз – ул милләтнең киләчәге булган яшь буынны тәрбия кылучы, шуңа да аның җитәрлек дәрәҗәдә белеме, акылы, тәрбияви куәте булырга тиеш. Р.Фәхреддин билгеләп үткәнчә, «Бала тәрбияләү – ананың гаиләдәге генә түгел, ә бөтен җәмгыять алдындагы изге һәм җаваплы бурычы». Бу фикер башка мәгърифәтчеләрнең язмаларында да үстерелә.

Хатын-кыз мәсьәләсе татар әдипләренең әсәрләрендә дә чагылыш тапкан – алар хатын-кызларның гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге хәлен кискен тәнкыйтьләгәннәр, мәгърифәтчелек идеалларын гәүдәләндергән хатын-кыз образларын иҗат иткәннәр. Шушы чорда әдәбият мәйданына хатын-кызлар үзләре дә килә башлаганнар. Галимнәр тарафыннан «татар әдәбиятының тәүге карлыгачлары» дип бәя бирелгән татар ханымнары хатын-кызны мәгърифәтле итүне максат итеп, әсәрләрендә кыз баланы тәрбияләү, йорт эшләренә өйрәтү, гаиләдәге мөнәсәбәтләрне дөрес төзү кебек мәсьәләләргә тукталганнар. Тик бу чорда җәмгыять, җәмәгатьчелек хатын-кызларның күпләп әдәбиятка килүләренә бик үк әзер булмый әле. Аларның язган китапларының күбесе тиз генә басылмый, кайберләре бөтенләй дә дөнья күрми кала. Күренекле мәгърифәтче һәм педагог Фәхрелбәнат Сөләймания 1906 елда «Вакыт» газетасында басылып чыккан бер мәкаләсендә татар җәмгыятендә хатын-кызларга карата мөнәсәбәтнең түбән дәрәҗәдә булуын тәнкыйтьләп яза. 1893 елда, хатын-кызлар өчен бала тәрбиясенә багышланган китапларның юклыгы сәбәпле, ханым-

[2] Әлеге авторларның хатын-кыз мәгарифе мәсьәләләренә багышланган язмалары белән тулырак «XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында хатын-кыз мәгарифе мәсьәләләре» (Казан, 2020) китабы аша танышырга мөмкин.

нарыбызга бер файда булсын дип, хатын-кызларның сәламәтлеге һәм бала тәрбиясе турында бер китап язып, аны бастырыр өчен берничә кешегә мөрәҗәгать итүе, цензорга биреп, нәшер итәргә рөхсәт алганнан соң, кулъязманың кемдер кулында ятып, юкка чыгуы турында яза. Тагын берничә китабын шундый ук язмыш көтә. «Аларны хатын кеше тәртип кылган, бәлки хатыннар әсәрен табгы кылу шәригатебездә дөрес тә түгелдер, ир кешенеке булса, аю такмагы кеби мәгънәсез такмак булса, күптән табгы кылган булырлар иде», – дип ачынып яза[3].

Бу елларда татар хатын-кызлары арасында үзе язган әдәби әсәрләрен, фәнни хезмәтләрен аерым китап итеп бастырып чыгарган мәгърифәтчеләрдән Хәнифә Гыйсмәтуллина, Хәбирә Насыйрия, Галимә Рәхмәтуллина һәм Галимәтелбәнат Биктимерияне атарга мөмкин[4]. Аларның китапларында хатын-кызларга белем һәм тәрбия бирү, балалар тәрбиясен яхшырту, гаиләдә һәм җәмгыятьтә ханымнарның токтан урыны һәм аны күтәрү һ.б. бик күп мәсьәләләр күтәрелә. Әле татар вакытлы матбугаты барлыкка килгәнче үк каләмен чарлаган, хатын-кыз, балалар һәм гаилә тәрбиясенә багышланган китаплар төзеп бастырган мәшһүр әдибә-педагоглар арасында апалы-сеңелле Галимәтелбәнат Биктимерия (1876–1906) һәм Фәхрелбәнат Сөләймания (1854–1959)[5] бар. Алар үзләренең китапларында хатын-кызлар арасында гыйлем-мәгърифәт тарату, аларның гаиләдәге хәлен җиңеләйтү, бурыч һәм вазыйфаларын, хокукларын аңлатуны, бала тәрбиясен яхшыртуны максат иткәннәр. Бу китапларны, чын мәгънәсендә, XX гасыр башы татар хатын-кызларының энциклопедиясе дип атарга да мөмкин.

Гомумән алганда, бу чор татар мәгърифәтчеләренең мирасы бик бай, эчтәлекле. Бу мирас арасында әлегәчә киң җәмәгатьчелеккә билгеле булмаган, яисә аз билгеле булганнары да шактый.

---

[3] Сөләймания Ф. Мөселман хатыннарыннан Вәкил әфәндегә бер-ике сүз // Вакыт. 1906. 11 май.

[4] Гайнуллин М. Өмет йолдызлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. Б.3.

[5] Бу ике мәгърифәтче якын кардәшләр: Галимәтелбәнатның әтисе Лотфулла Сибгатулла улы – Фәхрелбәнат ханымның бертуган абыйсы.

Әлеге кыйммәтле чыганакларны барлау, өйрәнү, укучыларга таныту максатыннан, татар мәгърифәтчеләренең тәрбия турындагы фикерләрен туплаган хезмәтләрен бүгенге имляга күчереп тәкъдим итүне күздә тоткан «Татар тәрбиясе» сериясен башлап җибәрәбез. Әлеге сериядән беренче китапта – Галимәтелбәнат Биктимерия һәм Фәхрелбәнат Сөләйманиянең XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында дөнья күргән, хатын-кызның гаиләдәге урыны, гаилә һәм бала тәрбиясенең үзенчәлекләренә багышланган хезмәтләре урын алды. Текстлар хәзерге татар әдәби теленә якынайтылды, иске кулланылышлы сүзләргә һәм гарәп-фарсы алынмаларына аңлатмалар бирелде. Китап текстларының темадан читләшкән өлешләре һәм гарәп телендәге гыйбарәләр төшереп калдырылды.

# I БҮЛЕК

# ГАЛИМӘТЕЛБӘНАТ БИКТИМЕРИЯ



**Галимәтелбәнат Биктимерия**
**(1876–1906)**

# *ГАЛИМ КЫЗЫ ГАЛИМӘ*

«Әгәр хатын-кызларыбыз арасында
бу ханым кеби мөхәррирләре вә
хакларын химая итүчеләр[1] булса иде,
бәлки алар да үз хакларын белерләр вә
ирләрнең аларга булган илтифатсызлыкларын
бетерергә мәҗбүр итәрләр иде»

*(Фатих Әмирхан)*

Күренекле татар мәгърифәтчесе, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар иҗтимагый фикере үсешенә өлеш керткән педагог һәм әдибә Галимәтелбәнат Лотфулла кызы Биктимерия (Биктимирова) 1876 елның ноябрендә Казан губернасы Чар өязе (Татарстанның хәзерге Әтнә районы) Кышлау авылында[2] имам һәм ахунд Лотфулла бине Сибгатулла бине Габделкадыйр әс-Сөләймани гаиләсендә дөньяга килә. Гомерен балаларга белем бирү белән үткәргән, «хәсән холыклы, гакыллы һәм галим» Лотфулла хәзрәт үзенең балаларына, бигрәк тә кызларына дөрес тәрбия, заманча төпле белем бирергә тырышкан[3].

Татар мәгарифе тарихы белгече Т.Биктимированың билгеләп үтүенчә, Лотфулла хәзрәтне лаеклы рәвештә авыл җирендә кыз балаларга җәдитчә укытуга башлап юл салучыларның берсе дип санарга мөмкин[4]. Хәзрәтнең үз кызларын мөгаллимәлеккә әзерләү өчен махсус укыту планы – программалар, кулланмалар төзегәнлеге «һәм шулай үзенә күрә бер хосусый мәктәп – дарелмөгаллимат булдырган»лыгы мәгълүм[5].

---

[1] Химая итү – яклау.

[2] Р.Фәхреддин авылның элеккеге исемен күрсәтеп, Котаймас дип яза.

[3] Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. Б. 334.

[4] Биктимирова Т.Ә. Татар хатын-кызлары мәгърифәт юлында. Казан: «Печатный Двор», 2002. Б. 31.

[5] Вакыт инде: без дә торыйк… (Җәдидчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу): очерклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. Б. 24.

Риза Фәхреддин билгеләп үткәнчә, «үзенең кыз балаларының тәрбиясенә дә әһәмият биреп, һәммәсен гыйлем вә мәгълүмат сахибәләре итеп җитештергән» Лотфулла ахунның кызларының «һәммәсе дә мөгаллимәлек вазыйфаларын башкарып»[6] торганнар. Галимәтелбәнат кына түгел, хәзрәтнең башка кызлары да кыз балалар укыту белән шөгыльләнгәннәр: Гайшә – Уфада ахун Җиһангир Абызгилдинның җәмәгате, кызлар мәктәбендә укыткан; Гафифә Алмата шәһәрендә имам Хөсәен никахында булып, шулай ук гомерен кыз балаларга тәрбия бирүгә багышлаган[7]. Фатыйма исемле кызы – Касыйм шәһәрендә имам Фатыйх Дәүликамовның җәмәгате була[8].

Галимәтелбәнат башлангыч белемне атасыннан ала. 12 яшьләрендә кыз үзлегеннән гарәп телен, шәригать белемен өйрәнә башлый. Гарәп әдәбияты белән таныша, фарсы теле белән кызыксына, хисап, география фәннәре буенча башлангыч белемнәрне үзләштерә[9]. 16 яшеннән үзе дә мөгаллимәлек эшенә керешә, әтисенә кызлар укытуда ярдәм итә, тәҗрибә туплый[10].

Фатих Әмирхан Галимәтелбәнат Биктимериянең гаять күркәм холыклы, һәркемгә яхшы мөгамәләле, шәфкатьле булуы турында яза. 1895 елда кыз Рязань губернасының Касыйм өязе (хәзерге Рязань өлкәсенең Касыйм районы) Яубаш авылы имамы Мөхәммәдгариф бине Биктимергә кияүгә чыга һәм ире гаиләсенә күченеп китә[11]. Яңа урында Галимәтелбәнат үзенең хыялын тормышка ашыра – кызлар өчен җәдит мәктәбе ачып җибәрә,

[6] Вакыт инде: без дә торыйк… (Җәдидчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу): очерклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. Б. 439.
[7] Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. Б. 335.
[8] Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. Б. 438.
[9] Әмирхан Ф. (журналда авторның исеме күрсәтелмәгән). Галимәтелбәнат (Тәрҗемәи әхвале мөшаһир) // Тәрбияи-этфаль. 1907. №4. Б.65.
[10] Вакыт инде: без дә торыйк… (Җәдидчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу): очерклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. Б. 24.
[11] Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. Б. 438.

мөгаллимәлек итә. Күп тә үтми, бу мәктәп тирә-юньдә үрнәк мәктәпләрнең берсе булып әверелә.



Биктимериянең татар кызларын укыту эшендә алга таба зур планнары була: киләчәктә ул мөгаллимәләр әзерләү өчен ике еллык кызлар мәктәбе ачу, мәктәпнең уку программасына география, табигать, тарих кебек дөньяви фәннәрне кертү уе белән яна[12]. Тик бу хыялы, кызганычка каршы, тормышка ашарга өлгерми кала – аяусыз үлем яшь мөгаллимәне вакытсыз алып китә.

Галимәтелбәнат Биктимериянең мәгърифәтчелек эшчәнлегендәге икенче бер мөһим юнәлеш – ул язучылык эше. Бу эшне ул, әдәбият галиме Мөхәммәт Гайнуллин билгеләвенчә, мөгаллимәлек итү белән бер үк вакытта алып бара: 1892–1903 елларда Галимәтелбәнат ханымның тәрбия һәм мәгърифәтчелек темасына караган «Тәргыйбел-бәнат фи тәгълимел-әдәбият» («Хатын-кызларны әдәбият өйрәнүгә кызыксындыру»), «Хөснел-васыять» («Күркәм васыять»), «Мәгашәрәт адабе» («Аралашу кагыйдәләре») исемле әсәрләре басылып чыга[13].

Моннан тыш, әдибәнең тагын берничә китап өстендә эшләве билгеле: «Әхлаке җәлалия» («Бөеклек әхлагы») һәм «Ләвамигыль-ширакъ» («Укучыларны хурлаучылар»). Тик, кызганычка каршы, күзләре һәм куллары авырту сәбәпле, Г.Биктимерия әлеге

---

[12] Гайнуллин М. Өмет йолдызлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. Б. 42.

[13] Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 2 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. Б. 408.

китапларны тәмам итәргә өлгерми[14], 1906 елның 29 ноябрендә яшьнәп торган ханым бакыйлыкка күчә[15]. Бу вакытта аңа бары тик 30 яшь кенә була. Бу турыда «Тәрбияи-әтфаль» журналында хәбәр ителә[16]. Шул ук журналның 4 нче санында Фатих Әмирханның Галимәтелбәнат Биктимериянең вафаты мөнәсәбәте белән «Галимәтелбәнат (Тәрҗемәи әхвале мөшаһир)» дигән мәкаләсе басылып чыга[17]. Икенче бер чыганакка караганда, Галимәтелбәнат ханым бала тапканда вафат була[18].

Исемнәреннән үк күренеп торганча, Галимәтелбәнат Биктимериянең барлык китаплары кыз балаларны укыту һәм белемле итү, аларның гаиләдәге хокукларын һәм вазыйфаларын аңлату һәм яклау, җәмгыятьтә тоткан урыннарын билгеләү, гаиләнең бәхетле булуының төп сәбәпчеләре булган ханымнарга юл күрсәтү һ.б. мәсьәләләргә багышланган. Аның фикеренчә, хатын-кызны укыту һәм аңа дөрес тәрбия бирүнең максаты аның үзен белемле һәм мәгърифәтле итү генә түгел, ә бәлки гаиләсенең, балаларының, һәм, гомумән, җәмгыятьнең яшәеше, алгарышы өчен дә кирәк. Шуңа күрә «күркәм тереклек итмәк хакында иҗтиһад итмәк[19] беренче дәрәҗәдә хатыннар өстенә лязем вә тиештер»[20].

1897 елда чыккан «Мәгашәрәт адабе» китабына язган сүз башында әдибә үз алдына куйган максатын түбәндәгечә билгели: «Фикерем исә җенестәшебез булган хатыннар таифәсе арасында гыйлем вә мәгърифәт таратмак вә аларны мәгълүмат сахибәләре[21]

---

[14] Әмирхан Ф. Галимәтелбәнат (Тәрҗемәи әхвале мөшаһир) // Тәрбияи-әтфаль. 1907. №4. Б.65.

[15] Фәхреддин Р. Асар. 2 том. Казан: Рухият, 2009. Б. 142.

[16] Тәрбияи-әтфаль. 1907. №1. Б.17.

[17] Әмирхан Ф. Галимәтелбәнат (Тәрҗемәи әхвале мөшаһир) // Тәрбияи-әтфаль. 1907. №4. Б.65.

[18] Гайнуллин М. Өмет йолдызлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. Б. 42.

[19] Иҗтиһад итү – тырышу.

[20] Биктимерия Г. Мәгашәрәт адабе. С.-Пб.: «И.Бораганский вә компаниясе»нең матбагасы, 1898. Б.3.

[21] Сахибә – ия.

итмәктер. Чөнки хатыннар дөньяда булган инсаннарның ярымнарыдыр. Гаиләнең бәхет вә сәгадәтләре хатыннарның гакыллы вә гыйлемле булуларына багланмыштыр. Хатыннар тәрбияле балалар җитештерәләр. Аларның тәрбияләре сәбәбендә дөньяга олуг затлар булыныр. Әгәр дә бер хатын укыр исә, үзенең кем идеген, вазыйфасы (хезмәте) нидән гыйбарәт идеген белер, балаларын гүзәл тәрбия кылыр, ире илә яхшы вә Аллаһы Тәгаләнең әмерләренә муафикъ тереклек итәр. Вә бу сәбәпле үзе һәм ире вә балалары дөньяда вә ахирәттә бәхетле булырлар»[22]. Г.Биктимериянең әлеге китабына зур бәя биреп, Р.Фәхреддин: «Язучы Галимә ханым, бер өй әһеленә аналык хезмәте иткәне кеби, никадәр кыз балаларга мөгаллимәлек һәм итмәктәдер. Фикеренең бәләнд[23] идеген белмәк өчен, рисаләсенең башында булган берике сүзне укымак җитсә кирәк. Вакыйган[24] бер-ике сүзләрдер, ләкин миллион сүзләрдән хәерле сүзләрдер. Фикерне эшләтмәк яки гыйлеме илә гамәл итмәк нияте илә ханым әфәнде ошбу рисаләсен дә һәм язмыштыр... Гүзәл хезмәттер. Тәбрик итәбез!» – дип яза[25].

Г. Биктимерия әлеге китабында гаилә мөнәсәбәтләренең күп якларына туктала: кайнана һәм килен, үги ана һәм үги балалар, ир белән хатын, ата-ана һәм балалар һ.б. Бу проблемаларның күбесе бүген дә актуальлекләрен югалтмыйлар, заман укучысы да, әлеге китаплар белән танышканнан соң, үзенә нәтиҗәләр ясар, карашларын тагын бер кат күздән кичерер. Мисал өчен, ятимлек проблемасын гына алыйк. Бүгенге көндә әллә никадәр ятим (күп очракта әтиле-әниле ятимнәр) балалар йортларында, ятимханәләрдә көн күрәләр. Ә бит татар халкының гомер-гомергә әтиәнисез калган балаларны чит кулларга бирү гадәте булмаган, ятим баланың тәрбиясе гаилә, кардәш-ыруг, хәтта күрше-күлән

[22] Биктимерия Г. Мәгашәрәт адабе. СПб.: «И.Бораганский вә компаниясе»нең матбагасы, 1898. Т. б.

[23] Бәләнд – югары.

[24] Вакыйган – чынлыкта.

[25] Биктимерия Г. Мәгашәрәт адабе. СПб.: «И.Бораганский вә компаниясе»нең матбагасы, 1898. 21 б.

ярдәме белән алып барылган, аның киләчәге өчен туган-тумача үзендә җаваплылык тойган. Китап авторы «хатыннарның, киленнәрнең акыллылыклары, уңганлыклары, изгелекләре үги балалар, үги киленнәр арасына килгән вакытта мәгълүм буладыр», – дип саный. Аның карашынча, «Үгиләргә иткән җәфалары табыш (процент) илә үзенә кайтыр. Бу исә дөньяның иң иске холкыдыр»[26].

Г.Биктимерия ир – хатын, килен һәм кайнана, үги балалар һәм үги аналар арасындагы каршылыкларны киметү, бетерү юлларын күрсәтергә омтылган, һәм, әлбәттә, бу каршылыкларны хәл итүнең иң беренче һәм әһәмиятле юлын хатын-кызга дөрес тәрбия һәм белем бирүдә күргән. Чөнки гаиләдә туган аңлашылмаучылыкларны уңышлы хәл итү күп очракта хатын-кыз – акыллы әни, килен, кайнана кулында булган. «Инде безнең халкыбыз, дигәнебезчә хатыннары изге булуларын эстәсәләр[27], хатыннар турысында бәхетле булырга рәгъбәт кылсалар[28], кыз балаларыбызны яхшы мөгаллимәләрдән укытырга вә ислам тәрбиясе илә тәрбия итәргә иҗтиһад кылсыннар! Ислам тәрбиясен күргән кызлар ирләренә гакыллы киңәшчеләр, балаларны яхшы үстерүче аналар булачаклары кеби, ирләренең тәүфикъларына сәбәпчеләр, малларына каравылчы, ирләреннән артык йорт җыяргa тырышучы бәндәләр булырлар»[29], – дип яза ул.

Ир белән хатынның тату, аңлашып яшәүләренең әһәмиятенә басым ясап: «Ир илә хатын арасында булган тереклектә мәслихәт булмас исә, – дип яза әдибә, – һәр икесе өчен олуг хәсрәт вә зур мәшәкать булыр. Мәгыйшәтнең ләззәте бетәр, рәхәте китәр, тәдбирләр бозылыр – җөмлә өй җәмәгате арасында дошманлык заһир булыр, балалар тынычсызланырлар. Моннан исә күп хәерсез эшләр мәйдан алыр»[30].

---

[26] Биктимерия Г. Мәгашәрәт адабе. СПб., 1898. Б. 14, 15.
[27] Әстәү – теләү.
[28] Рәгъбәт кылу – теләү, омтылу.
[29] Биктимерия Г. Мәгашәрәт адабе. СПб., 1898. Б. 8.
[30] Биктимерия Г. Мәгашәрәт адабе. СПб., 1898. Б. 3.

Шулай да гаиләдәге вазгыятьне җайлау, аны дөрес итеп коруда иң әһәмиятле нәрсә – ул бала тәрбиясе. Чөнки «тәрбия илә бер баланы алтын итмәк тә мөмкин, балчык ясамак та мөмкиндер»[31]. Бала – ата-анага Ходай тарафыннан тапшырылган газиз әманәт ул, шуңа да аның тәрбиясе, яхшы холкы, гүзәл табигате, белеме һәм тәрбиясе, һәм, димәк, нинди кеше булып җитешәчәге өчен дә, иң беренче чиратта, алар җаваплы.

Әлеге китапта күтәрелгән мәсьәләләр татарлар өчен генә түгел, барлык мөселман халыклары өчен дә бер үк дәрәҗәдә әһәмиятле булган. Күп тә үтми, аның үзбәк теленә тәрҗемә ителеп, Ташкент шәһәрендә басылып чыгуы шул хакта сөйли[32].

Г.Биктимерия үзенең балалар һәм гаилә тәрбиясенә караган фикерләрен Коръән аятьләре, гарәп әдәбиятыннан алынган үрнәкләр, шигъри текстлар ярдәмендә дәлилли, укучы игътибарына үзе иҗат иткән аерым шигъри парчаларны тәкъдим итә. Шулай итеп, үзен язучылык эшендә дә сыный.

Г.Биктимериянең «Тәргыйбел-бәнат фи тәгълимел-әдәбият» дигән китабында кыз балаларны укыту кирәклеге мәсьәләсе күтәрелә. Автор кыз балаларның тәрәккый итүләре өчен кемнәр генә тырышыр икән, дигән сорауны куя һәм бу заманда җәдитчә укытуның кирәклеге турында фикерен җиткерә[33].

«Хөснел-васыять» дип исемләнгән икенче бер китабында Г.Биктимерия васыять һәм аның төрләре, үтәүнең үзенчәлекләре, опекуннар билгеләү кебек мәсьәләләрне тикшерә, васыятьнең хатын-кызларга кагылышлы өлешләренә җентекләп туктала. «Хатын-кызларны мирастан мәхрүм кылмак Рәсүлуллаһтан мөкаддим җаһилият халкының гореф вә гадәтләредер», – ди[34].

[31] Биктимерия Г. Мәгашәрәт адабе. СПб., 1898. Б. 17.

[32] Adilhan Adiloğlu. Ceditçilik Dönemi Kazan Tatar Edebiyatında Kadın Hak Ve Hürriyetleri Meselesi. Gece Kitaplığı Yayınevi, Ankara, 2020. Б. 226.

[33] Галимәтелбәнат әл-Биктимерия әл-Җаубашия әл-Ханкирмәния ибнәт әл-ахунд Лотфулла әс-Сөләймани. Тәргыйбел-бәнат фи тәгълифмел-әдәбият. Петербург, 1897. Б. 4–5.

[34] Биктимерия Г. Хөснел-васыять. С.-Пб.: «И.Бораганский вә компаниясе» матбагасы, 1899. 20 б.


Шулай итеп, Г.Биктимерия үзенең хезмәтләрендә хатын-кызларның гаиләдә тоткан урыннары, вазыйфалары, хаклары, бала тәрбиясе, өйне карау, хуҗалыкны алып бару, ханымнарның, балаларның хокукларын саклау кебек әһәмиятле мәсьәләләргә туктала, көндәлек тормышта, яшәештә иң кирәкле булган киңәшләрен бирә.

Галимәтелбәнат Биктимерия – XX гасыр башының зур шөһрәт казана алган педагогы, шагыйрә, бик аз гына вакыт яшәвенә һәм иҗат итүенә карамастан, әдәби-педагогик эшчәнлеге заманының олуг галимнәре һәм киң җәмәгатьчелек тарафыннан танылган һәм зур бәя бирелгән мәгърифәтче. Кыска гына гомере эчендә шактый күп һәм әһәмиятле хезмәтләр язып калдырган, XX гасыр башы татар педагогик фикере үсешенә өлеш керткән Галимәтелбәнат Биктимериянең күренекле татар галиме Риза Фәхреддиннең атаклы «Мәшһүр хатыннар» китабына да кертелүе[35] (билгеле булганча, бу мәртәбәгә иң күренекле, төрки-мөселман халыклары тарихында зур роль уйнаган шәхесләр генә ия булган) шул хакта сөйли.

*Л.Р. Мортазина*

[35] Фәхреддин Р. Мәшһүр хатыннар. Оренбург: Тип. М.-Ф. Г. Каримова, 1904. Б.289–290.

# *МӘГАШӘРӘТ АДАБЕ*[1]



معاشرت آدابی

لعالمة البنات البكتمرية الحاوباشية الخانكرمانية
ابنة الآخوند لطف الله السليمانى .

باصلمه‌سنه رخصت ویرلدی پترسبرغده دیکابر ۲۴ سنه ۱۸۹۷

Дозволено Цензурою С.-Петербургъ 24 Декабря 1897 г.

❊ سانکت پترسبرغ ❊
* الیاس میرزا بوراغان‌اسکی و قومپانیه‌سی‌نك مطبعه‌سنده *
باصلدی . سنه ۱۸۹۸

Типо-Лит. И. БОРАГАНСКАГО и К°. Волкова дер. С.П.Б.

[1] Галимәтелбәнат Биктимерия. Мәгашәрәт адабе. С.-Пб.: «И.Бораганский вә компаниясе»нең матбагасы, 1898. 23 б.

# Мөәллифә[2] тарафыннан бер-ике сүз

Дөньяда күп кемсәләр[3] бер төрле фикер илә мәшгуль булып яшәдекләре мәгълүмдер. Мондый фикер, кирәк дөрес, кирәк хата булсын, әмма сахибе[4] исә мотлакан[5], күркәм күрмәктә вә дөрес белмәктә булыначагы табигый бер эштер. Шуның өчен миндә һәм бер фикер бардыр. Ләкин шәригать илә гакылга муафикъ булдыгы өчен, бу фикерне мотлакан дөрес игътикад итмәктә[6] вә тугры дип белмәктәмен. Ул фикерем исә җенестәшебез булган хатыннар таифәсе[7] арасында гыйлем вә мәгърифәт таратмак вә аларны мәгълүмат сахибәләре итмәктер. Чөнки хатыннар – дөньяда булган инсаннарның ярымнарыдыр. Гаиләнең бәхет вә сәгадәтләре хатыннарның гакыллы вә гыйлемле булуларына бәгланмыштыр. Хатыннар тәрбияле балалар җитештерәләр. Аларның тәрбияләре сәбәбендә дөньяга олуг затлар булыныр. Әгәр дә бер хатын укыр исә, үзенең кем идеген, вазыйфасы (хезмәте) нидән гыйбарәт идеген белер, балаларны гүзәл тәрбия кылыр, ире илә яхшы вә Аллаһы Тәгаләнең әмерләренә муафикъ тереклек итәр. Вә бу сәбәпле үзе һәм ире вә балалары дөньяда вә ахирәттә бәхетле булырлар.

Инде югарыда бәян итдекем үзрә мәмләкәтебездә булган хатыннар вә кызларга мәгашәрәт адабе[8] бәян итеп, ошбу рисаләне яздым. Исеменә һәм «Мәгашәрәт адабе» дидем. Мөмкин кадәр үз телебез илә язарга гайрәт иттем. Инша Аллаһ, кайсы бер кемсәләр файда алырлар, дия өмет итәм. Минем өчен ошбу нигъмәт кифаять итәр[9].

---

[2] Мөәллифә – китапны язучы, автор.
[3] Кемсә – кеше, зат.
[4] Сахиб – ия.
[5] Мотлакан – һичшиксез.
[6] Игътикад итү – ышану.
[7] Таифә – төркем.
[8] Мәгашәрәт адабе – аралашу кагыйдәләре, әдәпләре.
[9] Кифаять итү – җитәрлек булу.

**Бисмилләһир-рахманир-рахим!**

Күркәм тереклек (хәсән мәгашәрәт) хуш вә рәхәтлек үзерендә гомер уздырмактан гыйбарәт. Гомернең һичбер туктап тормагы юктыр, бәлки һәмишә[10] үтмәктә вә бетмәктәдер. Узган гомерне бөтен дөнья малы биреп кайтармак мөмкин түгелдер. Шуның өчен бу аз гомерләрне рәхәт илә кичермәк, заегъ[11] вә тәләф булмагыннан[12] сакламак тиеш буладыр. Күркәм булган аз тереклек озын хисап ителмәктер, вә күркәм булмаган озын тереклек кыска күрелмәктәдер. Күркәм тереклек исә хәсән холык (яхшы вә күркәм холык)ка багышланмыштыр. Күркәм холык сахибләре[13] һәрвакытта хуш тереклек итүләре тәҗрибә илә мәгълүм буладыр. Күркәм холык исә олуг фазыйләттер[14]. Аның хакында шәригатебездә мөкатдәс әмер ушандак[15] вәгазь вә нәсыйхәтләр әйтеленер; гакылы булган кемсәләр үзләре һәм ачык белмәктәләрдер. Хәсән холыктан берсе – өлфәттер[16]. Өлфәт – димәк ачык йөзле һәм татлы (затлы) сүзле булмактыр. Ушандак кешенең алдында вә артында хөрмәтне вә хакны ригая итмәктән[17] гыйбарәт. Ошбу өлфәтнең мәгашәрәт хакында олуг сәбәплеге булдыгы өчен шәригать вә гакыл карамагында мәмдух булмыштыр[18].

### *Хатыннар илә ирләр арасында булган әдәп бәянында*

Тәҗрибәләргә күрә, хатыннарның гүзәл холыклы булмаклары сәбәбеннән ирләре һәм гүзәл холыклы булыр. Моның хилафынча[19], әгәр дә хатыннар явыз холыклы булырлар исә, ирләрнең

[10] Һәмишә – һаман, һәрвакыт, өзлексез.
[11] Заегъ – әрәм, файдасыз.
[12] Тәләф булу – әрәм-шәрәм булу.
[13] Сахиб – ия, хуҗа.
[14] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш.
[15] Ушандак – шулай ук.
[16] Өлфәт – аралашу, дуслашу, бердәмлек.
[17] Ригая итү – кайгырту, олылау, хөрмәтләү.
[18] Мәмдух булу – макталу, мактап сөйләү.
[19] Хилаф – киресе, каршы.

холыклары һәм бозылыр, явызга булырлар. Ир илә хатын арасында булган тереклектә мәслихәт[20] булмас исә, һәр икесе өчен олуг хәсрәт вә зур мәшәкать булыр. Мәгыйшәтнең[21] ләззәте бетәр, рәхәте китәр, тәдбирләре[22] бозылыр, җөмлә[23] өе, җәмәгате арасында дошманлык заһир булыр[24], балалар тынычсызланырлар, моннан исә күп хәерсез эшләр мәйдан алыр. Шуның өчен күркәм тереклек итмәк хакында иҗтиһад итмәк[25] беренче дәрәҗәдә хатыннар өстенә лязем вә тиештер.

Ирләр илә күркәм тереклек итмәк өчен хатыннарга ошбу ике төрле нәрсәне игътибар итмәк лязем буладыр.

Беренче. Ирләрнең табигатен (мизаҗ[26]) вә холкын яхшы белмәк вә моның өчен күп мәртәбәләр сынамак тиештер. Соңра шуңар муафикъ эш кылмак лязем буладыр. Ягъни ир булган кеше нинди нәрсәләрдән хушланадыр вә ни кеби эшләрдән күңеле буладыр. Яки нинди гамәлләрне сөйми вә ни өчен күңеле бозыладыр. Һәрвакытта хатыннар ошбу рәвештә ирләрнең табигатьләрен ачык белеп, аларның яраткан нәрсәләрен кылырга вә яратмаганнарыннан тыелырга тиеш буладыр.

Икенчесе. Ирләренә итагатьле[27] хатыннар хакында булган сөенеч хәбәрләрне вә итагатьсез хатыннар хакында булган куркынычлы хәбәрләрне белмәк лязем буладыр. Шәригатебез исә итагатьле хатыннарга «изге хатыннар» исемен биреп, гамәлләре бәрабәренә һәм күп саваплар вәгъдә итмештер. Итагатьсез хатыннарга «усал хатыннар» дия атап, дөньяда күргән мәшәкатьләреннән артык ахирәттә һәм беркадәр авырлыклар булыначагыннан хәбәр бирелмештер.

---

[20] Мәслихәт – тиеш, яраклы, киңәш ителгән.
[21] Мәгыйшәт – тормыш, яшәеш.
[22] Тәдбир – алдан күреп эш итү.
[23] Җөмлә – барлык.
[24] Заһир булу – ачык, күренеп тору.
[25] Иҗтиһад итү – тырышу.
[26] Мизаҗ – сәламәтлек.
[27] Итагать – күндәм булу, сүз тыңлау.

Изге хатыннар, гөнаһ булмаган сурәттә, ирләре кушкан хезмәтләрне кылырлар вә көчләре җиткән кадәр ирләренең сүзләрен камил кылырлар.

Бәет:

Нигә затига иде бер нигә хой[28],
Ирерсен бу әлгаҗәб мөнкадәт шөй,
Диде касдым бәнем тәңрем ризасы,
Бетәр бу уртада ир мәддәгасе[29]
Ике тагать[30] мөяссәрдер[31] бер囚штә.
Ничек соңмый буен әмер әйләмештә,
Вә дәхый[32] хәбәр дә килмештер ки:

Ирне риза итеп вафат булган хатыннарның урыны җәнәттә булыр, дию.

Вә дәхый Әбу Һөрәйрә[33] разый Аллаһ кына риваять итәдер: әгәр дә бер хатын биш вакыт намазны укыса, шәһре рамазанда руза[34] тотса, үзен харамнан сакласа, иренә итагать кылса, аның урыны җәнәттә булыр, дию. Ләкин югарыда һәм әйткәнебезчә, әгәр дә ире берәр төрле гөнаһ эшләргә боерса, әлбәттә, ул вакытта кабул итмәс.

Чөнки Аллаһы Тәгаләгә гөнаһ булган сурәттә, һич вакытта бәндә әмерләренә игътибар булмас.

Имде бер хатын ошбу рәвештә бозык гөнаһ эшләргә көчләүче ир илә мөбтәля булса[35], мөмкин кадәр сабыр итеп, Аллаһы Тәгаләгә иренә тәүфикъ сорап дога кылыр, моның илә эш бетмәс исә, аннан аерылмак юлны карарга шәригать тарафыннан рөхсәт ителенәдер.

Ирләргә ярамакның олуг шарты һәм ошбу нәрсәләрдер: тән вә киемнәрне әшәке исләрдән, тузан вә пычраклыклардан пакь

[28] Хой – табигать, холык.
[29] Мәддәга – дәгъва ителгән нәрсә.
[30] Тагать – сүз тыңлау, буйсыну.
[31] Мөяссәр – җиңел, җайлы, җиңел үтәлешле.
[32] Дәхый – тагы, тагын да.
[33] Әбү Һөрәйрә (603–681) – билгеле сәхаб, иң күп хәдисләр тапшыручы.
[34] Руза – ураза.
[35] Мөбтәля булу – бәхетсезлеккә эләгү, дучар булу.

итмәк вә мөмкин кадәр юынып, тәмизләнеп[36] йөрмәк. Ирләрне риза итмәк нияте илә бу эшләрне кылмак шәригать каршында һәм хуш эш буладыр. Моңар муафикъ бер гарәп хатынының үзенең кызын кияүгә тапшырган вакытта әйткән нәсыйхәтләрен бу урында язабыз. Бу гарәп хатынының нәсыйхәтләре һәм безнең кызларыбызга әйтелергә дә яраралыктыр. Нәсыйхәтләре гүзәлдер.

Димешләр ки:

«Кызым, өлфәт иткән ояңнан чыктың, белмәгән түшәккә кердең. Танымаган кешегә юлдаш булдың, имде ошбу юлдашыңа син җир бул! Ул сиңа күк булыр, җир кеби түбәнчелек кыл! Ул сиңа күк шикелле күләгә булып торыр, шифалы ягъмурлары[37] илә күк йөзе рәхәтләндердеге кеби, ул һәм сиңа мәрхәмәтле булыр димәктер. Син аңар түшәк бул, ул сиңа терәк булыр! Син аңар кәнизәк[38] бул, ул сиңа кол булыр, тәкате җитмәгән нәрсәләр өчен аны көчләмә! Чөнки бу илә эш ачуга сәбәп булыр. Аннан ерак булма, үзеңне оныттырырсың. Никадәр сиңа якын булса, син һәм шулкадәр якын бул! Аның борынын әшәке исләрдән сакла! Колагын яман вә ачы сүзләрдән сакла! Пакизәлеккә[39] гадәт ит! Синнән һәрвакыт хуш ис килеп торсын! Сүзеңне тәмле, татлы, йөзеңне ачык итеп сөйлә! Яхшы вә мөлаем сүзләрдән башканы синнән һич ишетмәсен! Әшәке вә рәгъбәтсез[40] кыяфәт илә аның күзенә күренмә! Гадәт (күрем) вакытларыннан башкада ирең сине рәгъбәтсез рәвештә күрмәсен!»

Гарәп хатынының нәсыйхәте ошбу урында бетте.

Вә дәхый[41] хатыннарга лязем буладыр: үзләренең ирләре гайрәт иткән, ачуланган вакытларында сабыр итмәк, түзмәк, чыдамак вә моның өчен һәм Аллаһы Тәгаләдән савап өмет итмәк. Моңар муафикъ бер гарәп шагыйре (бәет әйтүче) үзенең хатынына вәгазь йөзеннән гарәп телендә бәетләр сөйләмештер.

---

[36] Тәмизләнү – чистарыну, пакьлану.
[37] Ягъмур – яңгыр.
[38] Кәнизәк – кол хатын, җария.
[39] Пакизәлек – чисталык, пөхтәлек.
[40] Рәгъбәтсез – ямьсез, тиешсез.
[41] Дәхый – тагы, тагын да.

Асыл бәет будыр:[42] [...]

Тәрҗемәсе исә ошбудыр:

Әгәр дә сиңа ачу итсәм, җәфа кылсам, мине гафу кыл!

Мин сине даим яратырмын, ачу иткән вакытымда миңа каршы әйтмә!

Җавап бирмә! Барабан суккан шикелле какма!

Аның өчен гаиб тә булачагын[43] белмәссең,

Бер күңелдә мәхәббәт илә ачу җыелдылар исә,

Һич тормый мәхәббәт чыгып китәр.

Ягъни бу гарәп үзенең хатынына әйтәдер: «Минем ачулы вакытымда холыксызланып һәм мине куркытмак вә миннән өстен булмак фикере илә минем ачуымны арттырма, кабартма, чөнки бу илә итеп, миңа өстен булмагың ихтимал исә дә, әмма минем ачуымны арттырып, олуг зарур итүең һәм мөмкиндер. Ул вакытта минем мәхәббәтемне сүндерерсең, аның өчен мин ачык белдем: мәхәббәт илә дошманлык бер күңелдә җыелдылар исә, ул күңелдә мәхәббәт тормас, чыгар, китәр».

Изге хатыннар ирләренең күзләре төшкәндә ачык йөзләре илә шатландырырлар, кушкан йомышларын ихлас илә кабул кылырлар, ирләре сәфәрдә булса, үзен һәм иренең малын яхшы сакларлар, фарыз[44] намазларны укырлар, үзләрен харам вә әдәпсезлекләрдән пакь тотарлар, иткән хезмәтләре илә ирләренә миннәт итмәсләр[45] («мин шу илә итәм, бу илә итәм, кадеремне белмисең», димәсләр). Бергә тереклек итү мөмкин булган сурәттә, талак сорамаслар, ирләренә аш (ашарга-эчәргә) хәзерләрләр, киемнәрен юарлар, тәһарәт әсбабын хәзер кылырлар, нәфәка[46] хосусында ирләренең күңеленә кайгы вә хәсрәт салмаслар, ирләренә каты кычкырып сөйләмәсләр, бәлки мөлаем вә ачык, шатлык илә сөйләрләр. Ирләренең өйләрен ташлап чыгып китмәсләр, хәтта ки ата-анага вә башка мәхрүм карендәшләренә барган вакытта да, ирләреннән сорап вә рөхсәт алып

[42] Гарәп телендәге шигъри текст бирелә.

[43] Гаиб булу – юкка чыгу.

[44] Фарыз – үтәлергә тиешле.

[45] Миннәт итү – искә төшереп тору, битәрләү.

[46] Нәфәка – яшәү өчен кирәк булган мал.

барырлар, малны исраф вә тәләф итмәсләр[47], хәтта ки, ирләреннән изен[48] юк икән, аның малыннан садака да бирмәсләр, ирләренең балаларына җәфа вә золым итмәсләр.

Бу сыйфатлы изге хатыннар гәрчә аз булсалар да, дөнья йөзендә бардыр. Мондый хөрмәтле хатыннарга тугры килгән ирләр кадәр бәхетле кемсә һич булмас. Шуның өчен бу рәвешле изге хатыннар хакында бер кемсә ошбу хуш бәетләрне әйтәләр:

Бәет:
Әгәр бар алганыңның яхшы хәле,
Димә хатын, дигел, диннең кәмале.
Хуш ул, зән[49] белмәсә, биһудә[50] дирне,
Сөчук[51] ләфзы[52] билә шат итсә ирне
Әгәр ун ел өендә булмаса он,
Өне чыкмас – аны әйтергә бер көн.
Серен фаш әйләмәс, гәр гамьдә булсын,
Әгәр тәң булса, әйтер: булса булсын.
Әгәр зәннең бонындик булса хиште[53].
Аны белгел – бу дөньяның биһиште[54].
Әлеңә төшсә мондый назнәйен[55] гөл,
Дигел – бу сәндәдер, бу сәндә мин кол.
Сәраи[56] ахирәтнең задидер[57] ул.
Гыйнаять[58] килешенең бадедер[59] ул.

---

[47] Тәләф итү – әрәм-шәрәм итү.
[48] Изен – рөхсәт.
[49] Зән – хатын-кыз.
[50] Биһудә – буш, файдасыз.
[51] Сөчук – төче.
[52] Ләфыз – сүз.
[53] Хишт – кирпеч.
[54] Биһишт – җәннәт.
[55] Назнәйен – иркә, назлы, сөекле.
[56] Сәр – баш, башлык.
[57] Зад – ризык, ашамлык.
[58] Гыйнаять – кайгыртучанлык, ярдәм.
[59] Бад – җил.

Инде безнең халкыбыз, дигәнебезчә хатыннары изге булуларын эстәсәләр[60], хатыннар турысында бәхетле булырга рәгъбәт кылсалар[61], кыз балаларыбызны яхшы мөгаллимәләрдән укытырга вә ислам тәрбиясе илә тәрбия итәргә иҗтиһад кылсыннар[62]! Ислам тәрбиясен күргән кызлар ирләренә гакыллы киңәшчеләр, балаларны яхшы үстерүче аналар булачаклары кеби, ирләренең тәүфикъларына сәбәпчеләр, малларына каравылчы, ирләреннән артык йорт җыярга тырышучы бәндәләр булырлар.

## *Бозык хатыннар*

Бозык вә явыз хатыннарның гадәтләре югарыда әйткәнебез изге хатыннарның гадәтләренә тәмам башка булмактадыр. Явыз хатыннар юк нәрсәләр өчен ирләре белән кычкырышалар. Ирләренең бер эшен ошатмаслар исә, шуның хакында озак вакыт сүз көрәштерәләр, үз сүзләрен дөрес итәр өчен, бар көчләрен сарыф кылалар[63], ирләре туктамас яки чыгып китмәсләр исә, болар һәмишә[64] туктамый сөйләрләр, ушандак[65] үзләренең кечкенә генә хезмәтләрен бик олуг санап, миннәт кылырлар[66], дөньяны төзәтеп торучы гүя алар гына булгандай итеп сөйләрләр, ирләрдән күргән изгелекләрне инкяр кылырлар, хәтта ки: «Мин синнән һич яхшылык күрмәдем», – дип әйтерләр.

Ахырында: «Гомерем синең илә заегъ[67] үтте», – дип, аерылышырга сорарлар. Хәлбуки, бу хатыннардан күпләренең кайтып китәрлек урыннары да булмас. Шуның өчен мондый хатыннардан файда чыкмас, үзләре һәлак булдыклары кеби, икенчеләрнең һәм хәсрәт илә тереклек итүләренә сәбәп булырлар.

---

[60] Эстәү – теләү.
[61] Рәгъбәт кылу – теләү, омтылу.
[62] Иҗтиһад кылу – тырышу.
[63] Сарыф кылу – тоту.
[64] Һәмишә – һаман.
[65] Ушандак – шулай ук.
[66] Миннәт кылу – искә төшереп тору, битәрләү.
[67] Заегъ – әрәм, файдасыз.

Әгәр дә бу холыксызлыкларны әйткәнче, ирләренең ачулары басылганны көтсәләр, аннан соң җайлап вә йомшаклык илә максудларын сөйләрләр, ирләре тарафыннан кат-кат рәхмәтләр вә афәриннәр ишетерләр иде, ушандак ирләренең ихлас вә мәхәббәтләре артуына сәбәп булырлар иде.

## *Ирләр*

Тереклек вә мәгыйшәт[68] ирләр илә хатыннар арасында уртак бер эш булдыгы өчен, хатыннар хакында язганыбыз кеби, беркадәр булса да, ирләр хакында һәм язмак тиеш буладыр. Шуның өчен бу урында ирләрдән бәхәс итәбез.

Ирләрнең гакыл, куәт җәһәтенчә хатыннардан артык икәннәрендә шөбһә юктыр. Шуның өчен дөньяның иң ачы терекләренә зәгыйфь хатыннар сабыр иткән вә түзгән хәлдә, куәтле вә гакыллы ирләр түзә алмаслар исә, олуг гаеп булыр. Хатыннар хакында шәфкатьле вә мәрхәмәтле булмак, ушандак[69] хаталарны гафу итмәк лязем буладыр. Рәсүл әкрам (салләллааһү галәйһи вә сәлләм)нән «Сезнең изгеләрегез хатынына изге булганыгыз» мәзмунында[70] хәдис күчерелмештер. Вә дәхый[71] Рәсүл әкрам (салләллааһү галәйһи вә сәлләм)нән «Мөэминнәр арасында нинди мөэминнең иманы камил (нурлы) булыр?» – диеп сорадыкларында: «Хатынына яхшы булганның», – дип җавап бирмештер.

Ирләр үзләренең өй җәмәгатьләренә көтүче мисалындадыр. Көтүдә булган хайваннар хакында көтүчеләр мәсъүл[72] булдыклары кеби, өй җәмәгатьләре хакында һәм ирләрдән сорамак булыр. Шуның өчен хатыннарның тыш вә эчләрен (күңелләрен) тәрбия итмәк, кагыйдәңә төшендермәк, вакыт вә заман илә мөдарәт кылмак[73], якты йөз, ачык сүзләр илә булмак тиеш буладыр.

---

[68] Мәгыйшәт – тереклек итү, көнкүреш, тормыш.
[69] Ушандак – шулай ук.
[70] Мәзмун – эчтәлек, мәгънә.
[71] Дәхый – тагы, тагын да.
[72] Мәсъүл – җаваплы.
[73] Мөдарәт кылу – яхшы, күркәм мөгамәләдә булу.

Бәгъзе[74] хәкимнәр[75] (дөрес белүче кемсә)дән риваять ителенәдер ки, әйтер имеш: әһеленә[76] якты йөз бирмәсә, ушандак тиешле вакытында мөдарәт итмәс исә, ул кемсәдән тереклек ләззәте китәр, дип. Бу исә тугры вә тәҗрибә илә дөрес беленмештер.

Тереклек күркәм булсын дип, арада әйткән кеше өчен үзенең хатынының табигате илә үз табигатен бер урынга җыярга, ягъни ике табигатьне бер-беренә якынлаштырмак өчен тырышмак лязем буладыр. Ушандак тәдбирләрне[77] вә хезмәтләрләрне мөнәсәбәтенчә ике арада булмак тиеш буладыр. Гыйлем вә фазыл[78] әһелләренең боерган вә үзләре кылган гадәтләренә вә әмерләренә һәм иярмәк мөнасибтер[79]. Чөнки ир илә хатын арасында булачак тереклекнең әдәпләрен бәян итеп әйтелгән сүзләр вә язылган китаплар хисапсыздыр. Бу җөмләдән мәшһүр галим фәкыйһ Әбү әл-Ләйс[80] (Рәхмәтуллаһи Тәгалә) димештер.

Хатыннарның үзләренең ирләре өстендә ошбу төрле хаклары бардыр:

1) әгәр дә хатын бик олуг кемсәләр баласы булмас исә, өй эчендә булган хезмәтләрне (аш пешермәк, чәй хәзерләмәк һәм җыймак кеби) хатыннардан кылдырсын;

2) иман, ислам, тәһарәт, фарыз, важиб[81], харам булган гыйлемнәрне ушандак[82] хатыннарның үзләренә генә махсус булган нәрсәләре тугрысында җөмләсен белдерсен, үгрәтсен;

3) хәләлдән ашатып-эчертсен, ушандак хәләлдән кидерсен;

4) аларга золым вә җәфа кылмасын;

---

[74] Бәгъзе – кайбер, кайсыбер.
[75] Хәким – акыл иясе, галим.
[76] Әһел – тормыш иптәше.
[77] Тәдбир – тиешле чара, эшне алдан уйлап эшләү.
[78] Фазыл – белемлелек.
[79] Мөнасиб – яраклы, кирәкле.
[80] Әбү әл-Ләйс – Мисырда яшәгән мөселман галиме, хәдисләр белгече.
[81] Важиб – шиксез үтәлергә тиешле.
[82] Ушандак – шулай ук.

5) әгәр дә алар каршы әйтсәләр, әдәпсезлек кылсалар, сабыр кылсын вә нәсыйхәт әйтсен, вә аларда кимчелекләрне гафу итеп, белмәмешкә салынсын.

Җөмләбезгә[83] мәгълүмдер ки: өй эчендә булган җөмлә вак эшләрне хатыннар башкарып тәмам кылмакталардыр. Бөтен өенең эчендә булган нәрсәләр һәр көндә күп мәртәбә боларның кулына кереп чыгадыр. Хәлбуки, мәшгуль булган нәрсәләренең күбесе чынаяк, чәйнек, пыяла, лампа, чүлмәк, таш савытлар кеби ватылырга вә уалырга сәляхиятлеләрдер[84], болар илә күп шөгыльләндекләре сәбәбеннән кайсыбер вакытта бу шәйләрне[85] ватсалар, эштән чыгарсалар, моның өчен холыксызланып ачу кабартмак гакыллы ирләргә аслан[86] мөнасиб булмас, чөнки бу нәрсәләр илә хатыннар кадәр шөгыльләнсәләр иде, әлбәттә үзләре дә ватарлар вә тәләф кылырлар[87] иде. Шуның өчен мондый урыннарда мотлакан[88] гафу итмәк ляземдер. Иң гайрәтле патша булган Хәзрәт Гомәр (Рәсүлуллаһ кына) әйтер имеш: «Хатыннар мине гөнаһтан сакларга сәбәп буларак, йортымны карыйлар вә малымны барлыйлар, киемнәремне юалар, балаларымны имезәләр вә тәрбия кылалар, ашымны вә икмәгемне пешерәләр, шуның өчен мин аларны гафу кыламын», – дип. Сезләрнең хатыннарыгыз һәм шундый түгелләр? Шундый булса, Хәзрәт Гомәрнең холкы сезгә һәм күчергеч булырга яраса кирәк иде.

## *Кайнаналар илә киленнәр арасында булган әдәп бәянында*

Ислам шәригатендә күп гыйлемнәрне вә изгелекләрне җыйган вә һәркем өчен белергә җиңел булган «Үзеңә сәүгәнне кешегә һәм сәү»[89] дигән бер кагыйдә бардыр. Киленнәрне сөй-

[83] Җөмлә – һәммә, бөтен.
[84] Сәляхият – сәләтлелек, осталык.
[85] Шәй – әйбер.
[86] Аслан – һич, һичбер вакытта, беркайчан да.
[87] Тәләф кылу – әрәм-шәрәм итү.
[88] Мотлакан – һичшиксез.
[89] «Үзең сөйгәнне (ошаганны) башкаларга да тәкъдим ит» мәгънәсендә.

ләгәндә бу кагыйдәне хәтердә тотарга тиешле булган өчен сүз башында зикер иттек[90].

Тавыш вә дошманлык булган өй эчендә рәхәт булмаганлык кемсәгә мәгълүмдер. Тавыш вә дошманлык кайбер вакытта кайналалар илә киленнәр арасында буладыр. Гәрчә бу эш башта аз вә игътибарга алырлык булмаса исә дә, мөнасиб дәрәҗәсендә бастырылмас вә сүндерелмәс исә, бара-бара зураеп китәр вә төрле-төрле зарарларга тоташадыр. Бабаларыбыз «Утның башы бер очкын», – димешләр.

Имде кайнаналар өй эчендә күп яшәгән хөрмәтле кемсәнәләр улдыклары өчен, үзләренең уңганлыклары вә тәдбирлекләре[91] илә киленнәрне яхшы гадәтләргә төшендермәк, кыз балаларына бирер кеби гүзәл әдәпләргә өйрәтмәк тиеш буладыр. Моның хилафынча[92], боларга җәбер вә золым итмәк гаеп һәм гөнаһтыр.

Бу көндә күзеңез нуры кеби күреп үстермәктә булган кызларыгыз, сезнең тәрбиягездән аерылып, киләчәктә бер көндә чит йортларга вә белмәгән кемсә арасына килеп килен булып китәрләр, бәлки киткәннәр дәдер. Шул кызларыгызның хуш тереклек вә рәхәтлектә гомер итүләрен күрсәгез, никадәр шатланырсыз вә никадәр сөенерсез; әгәр дә аларны аяк астында, золым вә җәфа эчендә күрсәгез, кан-яшьләрегезне түгеп кайгырырсыз, аны котылдырмак өчен кулыгызда булган көчегезне бетергәнчә тырышырсыз. Бу илә түгелме? Бу сездә булган киленнәр дә берәүләрнең күз карасы вә гомеренең сәрмаясе[93] иде. Алар һәм тәмам сезнең кеби кызларының рәхәт гомер итүләрен эстәп[94], кара хәбәрләрне ишетергә һич разый түгелләрдер. Шуның өчен сез, кайнаналар, үзегезгә яраткан нәрсәне кешегә һәм яратыгыз! Бу бер гакылдыр, кызыл алтыннарга алмаштырылмас.

Бәгъзе бер кайнаналар бардыр ки: киленнәре илә һәрвакыт хурлашыр, аларның эшләгән нәрсәләреннән, әйткән сүзләреннән гаеп табып торырлар, вә форсат булганда, кайнаталарына,

---

[90] Зикер итү – искә алу.
[91] Тәдбирле – алдан күрүчән.
[92] Хилаф – киресе, каршы.
[93] Сәрмая – акча, капитал.
[94] Эстәү – теләү.

ушандак[95] вә угылларына яманлап, булса да, булмаса да, алар өстеннән сөйләп, мәкруһ[96] күстерергә[97] тырышырлар. Соңра угылына: «Хатыныңны аер!», – дияргә башларлар, аермас исә, «Башка чык!» – дип тыгызларлар, ашамак вә эчмәк хакында һәм күп михнәтләр чиктерерләр. Моның сәбәпле һич юк урыннан бер йортның бәхете кире китәр, арага дошманлык чыгар, тереклекләре тәмсез (тәгамсез), дөньялары ләззәтсез булыр. Ахырында бу өй халкы таралып, вәйран булырлар. Вә хәлбуки моңа асыл сәбәп кайнананың холыксызлыгыннан башка булмас. Дөньяда торачак өч-биш көнлек гомерне дә, чәчәк атарга, җимеш бирергә хәзерләнгән яшьләрнең гомерләренә агу катыштырып, рәхәтләренә зәһәр салып китәр. Мондый гакылсыз хатыннарга дөньяда икән вакытында рәхмәт әйтмәдекләре кеби, үлгәне соңында һәм сагынмаслар. Чөнки сагынырдай кешеләрне черетеп-корытып китмеш булыр.

Әмма яхшы кайнаналарны һәркем мактар, үлгәннәре соңында рәхмәт илә яд кылырлар[98], кечерәге вә үрнәк итеп күстәрерләр.

Болар җөмләсеннән ятим кайнанам Тутыя Фәйзулла кызы иде. Аллаһы Тәгалә рәхмәт әйләсен! Өй эчендә гакыл вә шәфкать илә тәдбир итүеннән[99] башка гыйлем итә, гамәлдән ләззәт алмыш иде. Килене улдыгым хәлендә, мин фәкыйрәдән гыйлем өйрәнер иде. Күргәнем изге хатыннарның берсе булып, Аллаһы Тәгалә нигъмәтләренә шөкер итеп дөньядан үтте.

Кайнаналарга шәфкать вә мәрхәмәтле булмак тиеш булганы кеби, киленнәргә һәм үзләренең кайнаналарына итагать итмәк[100] вә хезмәт итмәк гүзәл эш идегенә шөбһә юктыр. Бу илә рәвештә яхшы хезмәтләр итеп, кайнаналардан дога алган киленнәргә бер көн килер, үз киленнәре һәм хезмәт кылырлар. «Хезмәт иткән – хезмәт күрер», – димешләр.

[95] Ушандак – шулай ук.
[96] Мәкруһ – ямьсез.
[97] Күстерү – күрсәтү.
[98] Яд кылу – хәтергә китерү, искә төшерү.
[99] Тәдбир итү – алдан күрү.
[100] Итагать итү – күндәм булу, сүз тыңлау.

Яхшы мәгыйшәт итүне киленнәр ишеткәннәре кеби, кайнаналар һәм ничә еллар тәрбияләп үстергән угланнары өчен өмет итсәләр кирәк. Әгәр дә кайнаналар киленнәрне үз кызлары кеби хисап итсәләр, киленнәр һәм аналарны тугъдыклары аналары мисалында күп хезмәтләре илә риза кылсалар, һәр ике тарафыннан вазыйфасы камил ителмеш булыр. Ошбуның сәбәбеннән ул өенең хәсән мәгыйшәте[101], күркәм тереклеге һәм җирендә булыр.

## *Үги балалар, үги киленнәр хакында*

Хатыннарның гакыллылыклары, уңганлыклары, изгелекләре үги балалар, үги киленнәр арасына килгән вакытта мәгълүм буладыр. Ошбу вакытта үзен үгиләргә мәхәббәтле күстәрергә тырышыр, акрын аларны бер сүзгә җыярга, җөмләсен[102] бер оя итәргә иҗтиһад итәр[103]. Шуның илә өенең эчендә бер низам вә тәдбир итеп, дошманлык чыгарырдай сәбәпләрне бетерер. Әгәр дә башта бер кыз тырышып, тәртипкә салыр исә, гомер барынча рәхәт яшәп, күп хатыннарның үз балаларыдай күрә алмаган хезмәт вә рәхәтләрне бу хатын үгиләрдән күреп ятыр. Хәтта ки бәгъзе[104] бер хатыннар булыр ки, әүвәлдә тавыш вә дошманлык илә уздырган йортларга килеп кермәк илә, шул тавышларны бастырып, тынычлыкка әйләндереп җибәрәләр. Мондый хатыннардан дөнья һәм күз йомып тормас, бәлки моны күрерләр вә һәркем рәхмәт укып, мәддах[105] вә сәна[106] кылырлар. Мәрхәмәтле Аллаһы Тәгалә моңа һәм ахирәттә үзенең чиксез савапларыннан өлеш чыгарыр.

Бәгъзе бер хатыннар үгиләр арасына килеп кердекләре соңында йортта таш калкыр, күркәм тереклек күтәрелер, өе эчендә булган барча халык рәхәтсез булырлар. Моның өстенә, «Фәлән кемсә яшь хатын алды да, азды да тузды», – дип сөйләр, хәтта ки,

---

[101] Мәгыйшәт – тереклек итү, көнкүреш, тормыш.
[102] Җөмлә – һәммә, бөтен.
[103] Иҗтиһад итү – тырышу.
[104] Бәгъзе – кайбер, кайсыбер.
[105] Мәддах – арттырып мактау.
[106] Сәна – мактау.

һич тә бу хатын сәбәп булмаган гаепләрне моңа яба башларлар, бәлки ахырында ире һәм моны гаепле табып, ихласын алыр. Шул вакытта фетнә җепләренең очлары чишелер, хәйлә арканнарының үзәкләре үзләре дә бу хатынны «Рәхим ит!» дип, килгән юлына кире озатып җибәрерләр. Бу ике төрле хатыннарның кайсысының хәле яхшы? Сез кайсысын яратасыз?!

Хәлбуки әйткән усаллык бер вакытта җиргә сеңмәс. Үгиләргә иткән җәфалары табыш (процент) илә үзенә кайтыр. Бу исә дөньяның иң иске холкыдыр. Бабаларыбыз «Без капчыкта ятмас», димешләр.

## *Хезмәтчеләр хакында*

Адәм баласының кайсысы белүче, кайсысы белмәс улдыгы кеби, байлык та һәм бертигез түгелдер. Аллаһы Тәгаләнең олуг хикмәтедер ки: бертуган улдыклары хәлдә, бәгъзеләре хуҗа вә бәгъзеләре ялчы булып гомер уздырмакталардыр.

Гакыллы кемсәләр ялчыларының үзләре илә бер тугъма идекләрен һич онытмаслар. Аларның ашамак өчен, кимәк-салмакларында җиңел итәрләр. Тәкатьләре[107] җитмәстәй эшләр илә көчләмәсләр. Руза[108] вә бәйрәм вакытларында хезмәтләрен җиңел кылырлар, хаталарын гафу итәрләр. Эш кушканда, йомыш итеп кушар, хезмәте беткәннән соң, рәхмәт әйтеп, күңелләрен табарлар.

Адәм булган кешеләр, бервакытта ялчылары илә кычкырышып йөрмәсләр, чөнки алар холыксыз кешеләрне ялчы итеп тотмаслар, шуның өчен кычкырышып йөрергә хаҗәт һәм булмас.

## *Балаларны тәрбия итмәк хакында*

Балаларны тәрбия итмәк, ислам шәригатемезнең беренче дәрәҗәдә игътибар иткән мәсьәләседер. Ләкин без, бу урында ялгыз бәгъзе бер ригаясе[109] лязем булмас әдәпләрне генә әйтәбез.

[107] Тәкать – көч.
[108] Руза – ураза.
[109] Ригая (ригаять) – кайгырту, карау, хөрмәтләү.

Бала дөньяга килгәндә аның элек ишеткән тавышы Аллаһы Тәгаләнең исеме булырга тиешледер. Шуның өчен, тугач та уң колагына азан вә сул колагына камәт[110] укылыныр. Аннан соң бал яки хөрмә илә башка нәрсә илә авызландырырлар. Җиденче көнендә сачен[111] алып, саче авырлыгынча көмеш яки алтын садака бирелер. Шул көндә исем бирелер. Биреләчәк исем яхшы вә мәэсүр[112] булырга тиешледер. Шуның өчен балага биреләчәк исемне әби-карчыклар түгел, галим имамнар сайлап куялар. Вә дәхый[113] шул җиденче көндә ир бала өчен ике, кыз бала өчен бер куй корбан чалыныр. Моны исә «гакыйка корбаны» дип әйтәләр. Бу корбанның ботын әби-карчыкка бирерләр. Калганы фәкыйрьләргә таратылыр. Һич нәрсәсе сындырылмый, бәлки буыннарыннан аерылыр. Корбанга дөрес булган куй гакыйка чалынырга һәм дөрес булыр. Гакыйка корбаны баланың сәламәт булуына сәбәп була имеш...

Мөмкин булганда, баланы үз анасы имезергә тиеш, чөнки бала өчен ана сөте кадәр яхшы нәрсә булмас. Анасы имезергә мөмкин булмас исә, ул вакытта бер изге хатын булып, аңар бирелер. Бала имезүче хатын (сөт анасы)ның яше егерме биш илә утыз арасында булса яхшы булыр. Сөт анасы изге вә күркәм холыклы, әгъзасы сәламәт булырга тиеш. Ачучан, кайгыручан хатыннар сөт анасы булырга муафикъ түгелләр. Баланы тәрбия итмәктә пакьлеккә ригаять итмәк[114] бик тиеш.

Ата вә аналар кулында балалар газиз әманәтләрдер. Шуның өчен боларны гүзәл тәрбия итмәк, яхшы холыкларга үгрәтмәк вә күркәм гадәтләргә төшендермәк лязем буладыр. Тәрбия илә бер баланы алтын итмәк тә мөмкин, балчык ясамак мөмкин. Боларның һәр икесенә дә өлге сәбәп – аналарыдыр. Имде фикер вә игътибар кылынсын! Балаларны тәрбия итүче аналарның үзләренең алган тәрбияләре, белгән нәрсәләре ни дәрәҗәдә булырга тиеш!...

---

[110] Камәт – намазга керешер алдыннан аягурә укыла торган дога.
[111] Сач – чәч.
[112] Мәэсүр – борынгылардан язма яки телдән күчерелеп килengән.
[113] Дәхый – тагы, тагын да.
[114] Ригаять итү – кайгырту.

Сөйләргә белә башлар исә, балаларга үз телемез «төркичә» илә «иман» белдерерләр. «Әлхәмдү», «Аятелкөрси» кеби сүрә вә аятьләр һәм хифыз итәрләр[115] (ядына алдырырлар). Ошбу вакыттан башлап, ислам әдәпләре илә балаларны тәрбия итәргә башланыр. Тәрбия хосусында тырышмак бик тиештер. Чөнки бу чагында балалар тал чыбыгы кеби, кая гына бөкләсә дә, бөкләнергә хәзер булыр.

Алты-җиде яшьләре булганда, укытырга башланып, мәктәпләргә һәм җибәрелер. Ошбу яшьләрендә һәм кызлар илә ир балаларны аерым ятырга вә йоклатырга өйрәтеленер. Намаз укырга һәм белдерерләр. Һәмишә[116] балаларның холыкларын төзәтергә тырышылыныр. Холыксызлык, хосусан тиз ачуланмак, юкка кайгырмак кеби нәрсәләр чире хәстәлек җөмләсеннәндер. Шуның өчен аларны бетерергә иҗтиһад итмәк[117] лязем буладыр.

Балалар өчен бер-берсен куркытмак вә куркытачак итеп яман хикәятләр сөйләмәк бик зарарлыдыр. Моның сәбәпле хәтта ки балалар кичәләрдә үз күләгәләреннән вә яки башка күләгәләрдән курка башларлар, яткач йоклый алмый, йокласа һәм рәхәтсезләнеп, куркыныч нәрсәләр илә саташып уянырлар. Моның ахыры бер хәстәлек булыр.

Ушандак[118] балаларның тәннәре, өс-башлары пакь булырга тиеш. Тырнаклары һәм киселгән булып, кием кимәк, ашамак-эчмәк, олуглар илә утырдаш булмакның әдәпләрен белдермәк һәм лязем буладыр.

Ашаган вакытларда һәмишә селкенеп, кыймылдап тормак, каш вә күзләре илә ишарәт итмәк, кием вә әгъзалары илә уйнамак, читләргә әйләнеп карамак яки кешенең ашаганына карап тормак, таянып киерелмәк, кешегә вә ашка карап йөткермәк, янында булганнар илә яшерен сөйләмәк, кычкырып көлмәк, артык кычкырып яки ишеттерми акрын сөйләмәк, олуглар янына кергәндә кулына зонтик яки таяк тотып кермәк кеби нәр-

[115] Хифыз итү – саклау, күзәтү.
[116] Һәмишә – һәммә, бөтен.
[117] Иҗтиһад итү – тырышу.
[118] Ушандак – шулай ук.

сәләр җөмләсе әдәпсезлекләрдер. Ошбулардан балаларны сакларга иҗтиһад ителенер.

Балаларга мәрхәмәтле булмак, күңелләрне тапмак олуглыктыр. Бүләк биргәндә кечкенәләрдән вә кызлардан башлап бирмәк әдәптер. Мөбах[119] вә уеннарга һәм рөхсәт бирелер. Зиһен вә хәтерләрне ачарга уенның файдасы бардыр.

## *Өйне тәрбияләмәк хакында*

Ислам шәригатемез һәрвакытта пакьлек вә сафлык илә боерадыр. Вакыйган пакь булмакта бер рәхәтлек һәм бардыр ки: һәркем үзе сынап белсә кирәк. Шуның өчен өйләрне, йортларны чүп-чарлардан, тузан-туфрактан себереп торырга гадәт итмәк лязем буладыр. Ушандак[120] аш савытларын, кашык вә табакларны, казан вә самавырларны, чынаякларны, пычак вә калакларны һәрвакытта пакь итеп тотмак тиештер.

Үрмәкүч ояларын алмак вә өй тирәләрен саф тотмак – хатыннарның уңганлыкларына олуг дәлил буладыр. Һәрничек булса да, мөселман кешегә пакь тереклек әйләмәк илә шәригать бирәдер.

Балыкларның судан башка тора алмадыкларын һәркем беләдер. Шуның кебек, безләр һәм дөньяда торуыбызда һавага мохтаҗбыз. Суладыгымызда иске һаваны чыгарып, яңа һаваны эчкә җибәреп торабыз. Һавадан башка тереклек мөмкин түгелдер. Иске вә исләнгән суларда балыклар үлдекләре кеби, һава начар вә бозык булса, адәмнәргә һәм хәстәлек вә рәнҗүлек заһир буладыр[121]. Шуның өчен тереклек итә торган урыннарны, хосусан өйләрнең эчләрен, юешлек, корылык, ис вә бу кеби нәрсәләрдән саф итмәк тиеш буладыр. Җәй көннәре булганда, тәрәзәләрне ачып, өйнең һавасын алмаштырмак файдалы булыр. Ушандак артык эссе булмаганда, кояшта йөрмәк тә файда булыр. Өйнең кечкенәлеге сәбәпле лампа, шәм вә яки кешеләрнең үзләренең

[119] Мөбах – тыелмаган да, кушылмаган да эш.
[120] Ушандак – шулай ук.
[121] Заһир булу – ачык булу, күренеп тору.

сулаулары илә һава бозылса, ул вакытта ишек ачып булса да, һаваны яңартмак лязем буладыр. Ләкин терелгән хәлдә ачык тәрәзә алдында утырмак зарарлы булыр. Яңа салган өйләрдә тәмам кибеп бетмәстән элек тормак һәм зарарлыдыр.

## *Бәгъзе бер әдәпләр хакында*

Кичәдә «Бисмилла» укып ишекләрне ябып бикләмәк, тәрәзәдә пәрдә булса, төшермәк, шәм вә лампаларны сүндермәк, учак, самавыр, чүлмәк кеби ут куркынычы булырдай нәрсәләрне яхшы карап, камил сүндереп бетермәк, ит вә май исе булган кул вә авызларны вә башка нәрсәләрне юып пакьләмәк җөмләсе әдәптер. Тарих ихтитам[122] вә фи бәреҗ октябрь[123], 1897 сәнә.

**Мәхкәмәи шәргыя вә идарәи рухания исламиянең әгъзасы кираменнән[124] фазыйль[125] мөхтәрәм казый дамелла Ризаэддин бине әл-хаҗ мулла Фәхреддин җәнабләреннән...**

## Мәгашәрәт адабе яки Галимә ханым

Ошбу «Мәгашәрәт адабе» атлы китап, үзебезнең тереклек итүебездә булган бәгъзе хәлләрне шәригатькә татбикъ итмәк[126] (үлчәмәк) өчен язылмыштыр. Укучылар вә караучылар күп файда алыр дип өмет итәбез. Язучысы Галимә ханым бер өе әһеленә аналык хезмәте итүе кеби кадәр кыз балаларга мөгаллимәлек итмәктәдер. Фикеренең бәләнд[127] идеген белмәк өчен, рисаләсенең[128] башында булган бер-ике сүзне укымак җитсә кирәк. Вакыйган бер-ике сүзләрдер, ләкин миллион сүзләрдән хәерле сүзләрдер.

---

[122] Ихтитам – тәмамлану, төгәлләнү, бетү.
[123] Фи бәреҗ октябрь – октябрь аенда.
[124] Кирам – хөрмәтле, затлы, данлыклы.
[125] Фазыйль – галим кешегә карата кулланыла торган эпитет.
[126] Татбикъ итү – яраштыру, чагыштырып карау.
[127] Бәләнд – бөек, югары.
[128] Рисалә – брошюра, хат, кечкенә фәнни мәкалә.

Фикерне эшләтмәк яки гыйлеме илә гамәл итмәк нияте илә ханым әфәнде ошбу рисаләсен дә һәм дә язмыштыр. Гайрәт вә җенестәшләргә хезмәт итмәк бу илә булыр: гүзәл хезмәттер. Тәбрик итәбез!

Безгә язган мәктүбендә, рисаләсен җиңел язганы өчен фәсахәт[129], бәлягатьтән[130] вә күп зиннәтле сүзләрдән ялангач улдыгыннан шикаять итәдер. Ләкин гаеп боермасыннар, бу фикерләре, безнең белдегебезгә, тәмам хилафтыр[131]. Шуның өчен бу фикерләренә кушылмакка ниятебез һич юктыр. Риҗа итәбез[132]: ханым хәзрәтләре гарәпләр тарафыннан әйтелгән фәсахәт вә бәлягать тәгърифләрен[133] күңелләренә китерсеннәр! Вакыйган боларга ун төрле, йөз төрле тәгъриф ителмештер; ләкин ләфызларда[134] булган башкалыкларны игътибарга алмас исә, җөмләсеннән максуд бер эш булыр; ул да: «Максудны дөрес вә җиңел аңлатмак», – димәктән гыйбарәттер.

Имде фәсахәт вә бәлягать ошбуыннан гыйбарәт улдыгы хәлендә, үз кавемебез өчен үзебезнең ана телебездә язылган бер рисаләне фәсахәт вә бәлягатьтән ялангач үлде димәк муафикъ булмас!..

Миллионнар илә хатыннарыбыз вә балаларыбыз сез кеби хөрмәтле әдибәләребездән тел вә әдәп үгрәнергә мохтаҗлардыр. Шуның өчен сезләрнең язачак рисаләләрегез алар укырлык вә файда алырлык сурәттә улмагы ляземдер. Телебезне сакламак тиеш идеге хакында «Таң йолдызы» атлы бер кыска рисалә язмыш идем. Әгәр дә ул вакытта күңелемә төшкән нәрсәләр хәзерендә төшсә иде, һич ялыкмас, барчасын язар идем...

Ишетдегем ялгыш булмас исә, Япониянең гакылларны хәйран калдырырлык рәвеш илә алга китүләренең бер сәбәбе дә галимнәре вә белүчеләре булмыш имеш. Ягъни китап язучыларының гадәтләре: ачык язмак вә иң читен нәрсәләрне җиңел итеп

---

[129] Фәсахәт – матур, тәмле теллелек.
[130] Бәлягать – язуда, сөйләмдә матурлык, төзеклелек.
[131] Хилаф – киресе, каршы.
[132] Риҗа итү – сорау, үтенү.
[133] Тәгъриф – аңлату, билгеләү.
[134] Ләфыз – сүз.

белдермәк булмыш. Иң олуг шәһәрләрендә утырып, иң олуг бер галимнәре язып чыгарган рисаләне иң гади голүмнәр[135], авыл кешеләре укып вә аңлап файда алырлык имеш. Бу гадәтне без һәм кабул итәр итсәк, шаять зарар улмас иде... Хәлбуки гыйлем бабында улган «Куәт вә икътидар» җиңел сүзләрне чит итеп сүзләмәктән гыйбарәт булмас, бәлки чит сүзләрне җиңел аңлата белмәктән гыйбарәттер.


Һәрни «Кирәкләрдән элек бик кирәкләрне белдерергә тиеш» дигән кагыйдәне ригая итәр[136] исәк, ачык язмак, җиңел укымак ысулын истигъмаль итмәкләребез[137] лязем булыр. Дусларыбыз вә гасырдашларыбыздан күп кемсәләрне беләбез ки: әйтелмеш ысулга (ачык язмак, җиңел укымак) ике куллары илә тотынмышлардыр.

Фикерегезгә кушылдыгыбызның сәбәбе исә ошбу яздыкларыбыздандыр. Шулай булса да, фикеребезне моталәга[138] тугры дия дәгъвә итмимен. Сөйләнгән сүзләр арасында бәгъзесе тугры, бәгъзесе ялгыш булмак гадәттер. Минем бу сүзләрем дә һәм бәлки бер ялгышлык булыр. Әгәр дә дөресләндерәчәк урыннары күп бәян әйләсәгез, мәмнүният[139] илә кабул итәрбез.

Ризаэддин бин Фәхреддин фи бәрҗ ноябрь[140], 1898 сәнә.

[135] Голүм – гыйлемнәр.
[136] Ригая итү – кайгырту, аңлау.
[137] Истигъмаль итү – куллану, файдалану, тоту.
[138] Моталәга – уку, өйрәнү; мәсьәләне төрле яклап өйрәнеп, хөкем чыгару.
[139] Мәмнүният – ризалык, риза булучанлык.
[140] Фи бәрҗ ноябрь – ноябрь аенда.

# ХӨСНЕЛ-ВАСЫЯТЬ[1]


حسن الوصية

قاسم اویازی جاوباش قریه‌سنده عالمة البنات خانمك اثریدر.

مقال طعن طاعندين نه غم ارباب عرفانه
آتارلر طاش البته درخت میوه دار اوزره

( سانكت پيتربورغ )
الیاس میرزا بورغان‌اسكی و(قومپانیه)‌سی‌نك مطبعه‌سنده باصلدی سنه ۱۸۹۹
Типо-лит. И. БОРАГАНСКАГО и К. въ С.-Петербургѣ.

[1] Галимәтелбәнат Биктимерия. Хөснел-васыять. С.-Пб.: «И.Бораганский вә компаниясе» матбагасы, 1899. 20 б.

**Бисмилләһир-рахманир-рахим!**

Ислам шәригатебез васыятьне кичектермәенчә, күркәм кылмак илә боерадыр. Бу хосуста Рәсүлуллаһ салләллааһү вә сәлләмнән хәдис шәрифләр[2] килмештер.

[...]

«Тиешле булмас мөселман кемсәгә васыятьне язмаенча аз гына вакытын да үткәрмәк. Әҗәлнең тизлектә килмәк ихтималы өчен».

[...]

«Бер кемсә васыять кылып вафат булса, гөнаһлары кичелер, изге вә шәһит булып, раст юл үзерендә[3] вафат булыр».

[...]

«Бер мән[4] васыятьсез вафат итсә, тәхкыйк[5] вафат итте. Җәһлия[6] үлеме берлән гафләт[7] хәлендә».

[...]

Һәркаюларыбызга ляземдер: ошбу кеби сөенеч вә куркыныч хәбәрләргә инанып, вә Рәсүлуллаһ салләллааһү вә сәлләмнең сөннәтенә ияреп, вафат үтмәсеннән әүвәл, васыятьләребезне шәригъ шәрифә вә сөннәт Рәсүлуллаһка муафикъ язып яки яздырып, васый[8] вә опекуннарын билгеләп, тәүбә вә истигъфар[9] вә гыйбадәткә тырышмак вә барча эшләребезне тәмам итеп, һәр кемсәгә[10] киләчәк әҗәлне хәтеребездән чыгармый, Аллаһны зикерне даим кылып, әҗәл кайвакытта килсә дә, тел (дил)ләремез Аллаһы Тәгаләне зикер[11] илә юыш булган хәлдә әҗәлеңә хәзерләнмәк.

---

[2] Шәриф – кадерле, кадерләүгә лаек.
[3] Үзерендә – эчендә.
[4] Мән – кем, зат, шәхес.
[5] Тәхкыйк – шиксез, һичшиксез.
[6] Җәһлия – наданлык, белмәүчелек.
[7] Гафләт – игътибарсызлык, саксызлык, ваемсызлык.
[8] Васый – берәүнең васыятен тормышка ашыручы кеше.
[9] Истигъфар – гафу итүне, ярлыкауны сорау.
[10] Кемсә – кеше.
[11] Зикер – искә алу, телгә алу.

Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре: җөмләбезгә ахыр сулуларыбызда хәсән хатимә[12] насыйп әйлия.

## *Васыять биш төрле*

Харам васыять, мәкруһ[13] васыять, вәҗиб[14] васыять, мөстәхәб[15] васыять, мөбаһ[16] васыять.

### *Харам васыять*

Вариска[17] васыять кылмак башка варислар разый булмаганда һәм варисларга зарар кыла торган васыятьләр һәркаюсы харам вә батыйльдер[18].

Варисларга зарар кылмак өч төрле була:

Беренче. Малиянең өченче өлешеннән артык икән, васыятьтер.

Әгәр варислар хәсән ихтыярлары илә разый булмасалар, бу сурәттә өченче өлешеннән артканда, васыятьне йөртмәклек алсаң дөрес булмас. Варислар разый булсалар, васыятьне әйткәнчә йөртелер.

Икенче. Малиянең өченче өлеше илә, я өченче өлешеннән ким илә васыять. Савапны ният кылмаенча, мөҗәррәд[19] варислардан малны кызганып, аларга аз калдырмак нияте илә.

Өченче. Зәмәсендә[20] сабит[21] булмаган бурыч илә ялган икърардыр[22]. Фәлән кешегә фәлән кадәр бурычым бар, дип ялган

---

[12] Хатимә – ахыр, азак.
[13] Мәкруһ – дин тарафыннан кискен тыелмаган, ләкин җиңелчә читкә кагылган эш.
[14] Вәҗиб – тиешле, шиксез үтәргә тиешле.
[15] Мөстәхәб – эшләнсә яхшы, эшләнмәсә зарары, гөнаһысы булмаган эш.
[16] Мөбаһ – тыелмаган да, кушылмаган да.
[17] Варис – мирас алучы.
[18] Батыйль – бозык, дөрес түгел, чын түгел.
[19] Мөҗәррәд – ялгыз.
[20] Зәм – шелтә, орышу.
[21] Сабит – даими; ачык.
[22] Икърар – тану.

хәбәр бирмәк кеби. Ушандык[23] бәгъзе вариска васыять кылмак яки бәгъзе вариска терек вакытында барча малны һибә кылмак[24]. Яки ялгыз сокүк[25] (документ)лар яздырмак һәркайсы варисларга зарар кылмак җөмләсеннәндер.

Бу эшләр һәркайсы китап, вә сөннәт, вә шәригатькә олуг хилаф[26] вә харамдыр. Гаклән[27] вә табиган[28] ифрат мәзмүм[29] вә кабих[30] әмерләрдер.

[...]

«Дөреслектә Аллаһы Тәгалә һәр хак иясенә үзенең хакын бирде. Аңа ул варислыкка васыять юктыр».

[...]

«Бер кемсә җитмеш ел изгелек кылган булса да, васыять кылмагында хыянәт вә варисларга зарар кылса, ул кемсә явыз гамәле илә дөньядан чыгып утка керер».

[...]

Варисларны, хосусан хатын-кызларны, мирастан мәхрүм кылмак Рәсүлуллаһтан мөкаддәм[31] җаһилият[32] халкының гореф вә гадәтләредер.

Җаһилият халкы үзләренең кем гакыллары берлә ирләрен хатын вә кызлар вә сабыйлардан артык дип уйлап, мирасның барчасын ирләргә генә тәкъсим кылып[33], бичара хатын-кыз, сабыйлары мирастан мәхрүм калалар иде.

---

[23] Ушандык – шулай ук.
[24] Һибә кылу – бүләк итү, бушка бирү.
[25] Сокүк – дәлил, факт.
[26] Хилаф – кире, тискәре.
[27] Гаклән – акыл буенча, акылга нигезләнгән.
[28] Табиган – табигый, чынлыкта.
[29] Мәзмүм – хурланган, сүгелгән.
[30] Кабих – чиркангыч, әшәке.
[31] Мөкаддәм – элекке, әүвәлге.
[32] Җаһилият – наданлык, белемсезлек.
[33] Тәкъсим кылу – бүлү, кисәкләргә аеру.

Аллаһы Тәгалә җаһилият халкының бу гадәт шәнига[34] вә рәсем[35] вә гореф кабихләренә инкярны мөтәзаммин[36] булгыдай вә я үзеренә балаларның мирасы хакында ир вә кызларның өлешләрен аерып бәян кылып, [...] аять кәримәсен иңдерде. Балаларның һәм ата вә ананың вә башка варисларның өлешләрен тәгаен кылды. Бу өлешләрне ошбу рәвешчә тәгаен вә тәкъдир кылмакның[37] хикмәт вә сәбәбенә һичкемнең гакылы ирешмәс.

[...]

«Сезләр белмисез үзегезнең мирас малыгызны алган кешеләрдән каюсы файдалырак икәнне, аталарыгызмы әллә балаларыгызмы?»

Сезләр варислар хакында Аллаһы Тәгалә әмер вә гаһед кылган[38] хөкемнәр, фикерегезне сарыф кылыныгыз[39] вә ул хөкемнәр итагать кылыныгыз[40]. Кыска фикер вә ким гакылларыгыз илән бәгъзе варисларны артык күреп, бәгъзесен мирастан мәхрүм кылмакны касд кылмагыз[41].

## *Малны вариска һөббә кылмак[42] вә сатып бирмәк бәянында*

Сәламәт вә терек вакытта малны бәгъзе вариска һөббә (подарить) итмәк һәм сатып бирмәк, башка варисны мирастан мәхрүм кылмак нияте илән олуг гөнаһтыр. Бу хосуста куркынычлы хәбәрләр варид улмыштыр[43]. Рәсүлуллаһ салләллааһү галәйһи вә сәлләмнән риваять кылынды.

---

[34] Шәнига – әшәке, начар.
[35] Рәсем – гадәт.
[36] Мөтәзаммин – эченә алган.
[37] Тәкъдир кылу – тану, бәя бирү.
[38] Гаһед кылу – йөкләмә алу, өскә бурыч итеп алу.
[39] Сарыф кылу – тоту.
[40] Итагать кылу – күндәм булу, сүз тыңлау.
[41] Касд кылу – уйлау, ният итү.
[42] Һөббә кылу – бүләк итү.
[43] Варид булу – килеп ирешү.

«Бер кемсә варисны мирастан мәхрүм кылса, Аллаһы Тәгалә ул кемсәне җәннәттән вә җәннәт нигъмәтләреннән мәхрүм кылыр».

[...]

Әгәр дә үзенең кан-тирләре илән чалышып, гомер сәрмаясен[44] бетереп тапкан малын, Аллаһ ризасы өчен важиб[45] вә мөстәхәб[46] булган васыятьләр кылып, үзеннән соң шул васыятьләр әҗран кылынып[47], калган малны низагъ вә фетнәсез, Аллаһы Тәгалә боерганча варислар арасында тәкъсим кылынып[48], варислар тынычлык вә хушлык үзерә файдалансалар иде, Аллаһы Тәгалә вә Рәсүле һәм варислар, разый булып, садакаи җари[49] шикелле, мәеткә һәм савабы булып, бу җәһәттән жаны рәхәттә булыр иде.

Бу илә улдыкта һәркаюмызга фикер кылмак лязем, варисларыбызны хосусый бигрәк, шәфкать вә мәрхәмәт кылырга тиеш, гаҗизә вә һәрвакыт ярдәмгә мохтаҗ, кызларыбызны гаиләбездә булсын, яки башка чыккан булсын, Аллаһы Тәгалә вә Рәсүле билгеләгән мирас өлешләрен кызганып, мәхрүм вә өметсез калдырып, Аллаһы Тәгаләнең шәригатенә мөхаләфә кылып[50], варистан вә балаларыбыздан сөеклерәк кәнде[51], үзләребезне мәңгелек җәннәт нигъмәтләреннән мәхрүм кылмак гакыллы адәмнең эше ирерме.

Бу эшләрдән зиядә сакланмак ляземдер.

[...]

[44] Сәрмая – акча, капитал.
[45] Важиб – тиешле, шиксез үтәлергә тиешле.
[46] Мөстәхәб – эшләнсә яхшы, эшләнмәсә зарары, гөнаһысы булмаган эш.
[47] Әҗран кылыну – бер эш өчен бирелү.
[48] Тәкъсим кылу – бүлү, кисәкләргә аеру.
[49] Садакаи җари – кулланыла торган, дәвамлы садака.
[50] Мөхаләфә кылу – кара-каршы ант итешү.
[51] Кәнде – үзе.

# II БҮЛЕК

# ФӘХРЕЛБӘНАТ СӨЛӘЙМАНИЯ



**Фәхрелбәнат Сөләймания**
**(1854–1959)**

# *«ГАЛИМӘ ҺӘМ ФАЗЫЙЛӘ» ХАНЫМ*

«Мөһим бер рисалә вөҗүдкә китердеге
өчен, мөхтәрәмә мөхәррирәсе
Фәхрелбәнат ханымны тәбрик.
Башка ханымнарыбызның да тәгълим
вә хезмәт юлында һичбер шәйгә бакмаенча,
каһарманагә бер сурәттә мәйданга
чыкмаларын телибез.
Чөнки моңа вакыт пакь килмештер!»
*(Фатих Кәрими)*

Хезмәтләрендә бала тәрбиясе, гаилә мөнәсәбәтләре, хатын-кызлар арасында гыйлем-мәгърифәт тарату кебек заманы өчен актуаль булган мәсьәләләрне күтәреп чыгып, XX гасыр башы татар мәгарифе тарихында якты эз калдырган күренекле милләтпәрвәр хатын-кызларыбызның тагын берсе – Фәхрелбәнат Сөләймания.

Фәхрелбәнат Сибгатулла кызы Сөләйманова 1854 елның 1 ноябрендә[1] Казан губернасы Чар өязе (Татарстанның хәзерге Арча районы) Түбән Оры авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Сибгатулла, Уфа өязе Шәриф авылы мулласы Габделкадыйр ахун улы, Иж-Бубый, Казан мәдрәсәләрендә укыган,

[1] Фәхрелбәнат Сөләйманиянең туган елы төрле чыганакларда төрлечә бирелгән. Мәсәлән, татар әдәбияты тарихын өйрәнүче галим М.Гайнуллин «Өмет йолдызлары» китабында 1852 елны күрсәтә; матбугат белгече һәм библиограф И.Рәминең «Әдәби сүзлегендә» 1857 ел куелган; XX гасыр башында татар хатын-кызларының җәмгыятьтәге эшчәнлеген өйрәнгән галимә А.Мәхмүтова үзенең хезмәтләрендә 1865 елга туктала. Чар өязе Түбән Оры (Служилая Ура) авылының I мәхәлләсе метрика мәгълүматлары буенча, Биби-Фәхрелбәнат 1854 елның 1 ноябрендә Сибгатулла белән Бәдриҗиһан гаиләсендә дөньяга килә.

заманы өчен тиешле белеме булган, «галим, пакь бер зат»[2] була. Сибгатулла мулла ир балалар укыту белән беррәттән, үзенең кызы Фәхрелбәнатка дә тиешле белем бирергә омтыла. Нәтиҗәдә, Фәхрелбәнат мәдрәсә күләмендә белем дәрәҗәсенә ия булган «галимә һәм фазыйлә кыз»[3] булып җитешә, бик теләп үзлегеннән гарәп телен өйрәнә.

Фәхрелбәнатның әнисе ягыннан әби-бабасы да белемле, ислам дине кануннарын төгәл үти торган, әдәп-әхлак, чисталык-тәртип мәсьәләләренә нык игътибар бирә торган кешеләр булалар. «Йортлары зур, мәшәкатьләре күп булып та, белмим, ничектер һәрбер эшләре тәртип илә эшләнеп, өйләре вә киемнәре гаять чиста, ашлары бик тәмле, кунаклары күп була торган иде», – дип искә ала аларны галимә үзенең хатирәләрендә[4]. Алар Бәрәңге авылында (хәзер Мари Республикасы) гомер итәләр. Бабасы авылның имамы һәм мөхтәсибе, ә әбисе абыстай булып тора[5]. Кыз бала чагында күп вакытын алар янында үткәрә һәм, әлбәттә, өйдә урнашкан тәртипне күзәтеп, бу сыйфатларны үзенә сеңдереп, гыйлем-мәгърифәткә омтылып үсә.

Фәхрелбәнат, үсеп-буйга җиткәч, үзеннән күпкә олы, әтисенең бертуганы Габделгалләмнең Мөхәммәдхәлил исемле улына[6] кияүгә чыга[7]. Мөхәммәдхәлил казый Түбән Новгородтагы Мәкәрҗә ярминкәсе мәчетендә имам һәм ахун булып хезмәт итә.

---

[2] Фәхреддин Р. Асар. 2 том. Казан: Рухият, 2009. Б. 141; Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б.341.

[3] Фәхреддин Р. Асар. 2 том. Казан: Рухият, 2009. Б. 141.

[4] Сөләйманова Ф. Мөгаллимәтел-бәнат: Кызлар мәктәбенә махсус кыйраәт китабы. Уфа: Кәримов, Хөсәеновның матбугат ширкәте, [елы күрсәтелмәгән]. Б. 35.

[5] Сөләйманова Ф. Мөгаллимәтел-бәнат: Кызлар мәктәбенә махсус кыйраәт китабы. Уфа: Кәримов, Хөсәеновның матбугат ширкәте, [елы күрсәтелмәгән]. Б. 35–36.

[6] Ш.Мәрҗани мәгълүматлары буенча, Сибгатулла мулла белән Габделгалләмнең этиләре бер булып, әниләре башка була.

[7] Фәхреддин Р. Асар. 2 том. Казан: Рухият, 2009. Б. 141.

Бу елларда Фәхрелбәнат Түбән Новгород, Уфа, Оренбург якларында балалар укыту белән шөгыльләнә. Мөхәммәдхәлил хәзрәт белән Фәхрелбәнат ханымның Габдулла (1886–1937) исемле уллары туа[8]. Габдулла Сөләймани заманы өчен танылган шәхес. Ул Мәкәрҗә ярминкәсе һәм Мәскәү мәчетләрендә имам; гает, җомга көннәрендә сөйләнә торган хөтбә һәм вәгазьләрне татар телендә укыган, дини йолаларга үзгәреш кертү, Коръәнне татар теленә тәрҗемә итеп, намазда укыла торган сурәләрне татарча уку мәсьәләләрен күтәргән кеше. Г.Сөләймани 1917 елда Түбән Новгород губернасы мөселманнары комитеты төзи, берничә тапкыр Мөселман Үзәк Диния нәзарәте казые булып сайлана, Бөтенроссия мөселман корылтайларында хатын-кызларның хокукларын яклап чыгышлар ясый[9].

Фәхрелбәнат Сөләйманиянең Октябрь революциясеннән соңгы тормышы турында мәгълүмат бик аз. Аның XX гасырның беренче дистәсе ахырларында иренең туган төбәге Байлар Сабасы якларына китүе мәгълүм. Монда ул халык иҗаты әсәрләре җыю белән шөгыльләнә. 1920 еллар ахырында Фәхрелбәнат ханым тарафыннан туплап калдырылган халык иҗаты әсәрләре (халык медицинасы материаллары, әкият һәм легендалар, халык мәкальләре, хорафат, ышанулар, им-томнар, кушаматлар, авыл яшьләренең яңа җырлары) Казан (Идел буе) федераль университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә (КСКБ) саклана[10]. Алар арасында Сөләйманиянең үз шигырьләре дә бар.

Ф.Сөләймания, татар вакытлы матбугаты дөньяга килү белән, газета-журнал битләрендә беренчеләрдән булып языша

[8] Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. Б. 85.

[9] Хабутдинова М. Габдулла Сулеймани // Медина аль-Ислам. 2005. №8 (11). С.14.

[10] Фәхрелбәнат Сөләймания тарафыннан язып алынган халык иҗаты әсәрләре (табышмаклар, «Шамак карак» әкияте, уеннар, җырлар) // КФУ КСКБ. 1815 т.; Фәхрелбәнат Сөләйманова. Җыентык (Җырлар, табышмаклар) // КФУ КСКБ. 290 т; Фәхрелбәнат Сөләймания. Халык медицинасы материаллары // КФУ КСКБ. 955 т.

башлаган хатын-кыз авторларның берсе. 1905–1906 елларда «Казан мөхбире» газетасы битләрендә аның «Мөсарәт, яки Хөррият» шигыре, «Бал, бал димәк берлә, авыз балланмас», «Ханымнарга хитаб» мәкаләләре, «Вакыт» газетасында Вәкил әфәндегә язган рәддияләре[11] һ.б. басылып чыга.

Әмма аның әле моннан күпкә алда дөнья күргән язмалары да билгеле. Борынгы кульязмаларны өйрәнүче галим М.Әхмәтҗанов раславынча, Фәхрелбәнат Сөләйманиянең 1870 еллар тирәсендә язылган шигъри хатлары табылган[12]. Димәк, кыз, үсмер елларында ук инде, үз уй-фикерләрен дәфтәр битләренә төшерә башлаган.

Татар вакытлы матбугатына юл ачылу белән, XX гасыр башының иң актуаль мәсьәләләренең берсе – хатын-кыз мәсьәләсен төрле яклап яктырткан махсус басма кирәклеге көн алдына килеп баса. Моны аңлаган Фәхрелбәнатның «Аналар» исемле журнал чыгарырга нияте була, әмма «Сөембикә» журналы чыга башлау белән, хатын-кызлар өчен махсус ике журналның дәвам итә алуына шикләнеп, «әгәр «Сөембикә» журналы яхшырса, бәлки мин чыгармый да калырмын»[13], – дип белдерә. Тиздән үзе дә «Сөембикә» журналына эшкә чакырыла, һәм журнал ябылганчы әлеге басманың сәркатибе булып хезмәт итә.

Сөләймания ханым үз хезмәтләрендә кызларны укыту һәм тәрбияләү, уку-укыту әсбаплары, мөгаллим һәм мөгаллимәләр, татар хатын-кызларының гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге хәле, аларның иҗтимагый роле турындагы мәсьәләләрне күтәреп чыга.

Аны мәктәпләрдә укыту ысулларының һәм уку китапларының төрлелеге борчый. «Милләтебезне алга җибәреп тәрәккый иттермәк өчен, әүвәл лязем булган нәрсә – мөгаллим-мөгаллимәләр, мөхәррирләр, газета мөхәррирләре, һәркаюыбыз бер иттифакта, бер сүздә булып, мәктәп ибтидаиләребезне һәркаюыбыз бертөрле ысул вә тәртипкә кую лязем», – ди һәм «мәктәпләребезне тәртипкә куяр өчен, әлбәттә, бер ысул берлә тәртип

---

[11] Рәддия – кире кагу, дөрес түгеллеген күрсәтү.

[12] Әхмәтҗанов М. Сайланма хезмәтләр. Казан: ТӘһСИ, 2019. Б. 69.

[13] Баттал Г. Фәхрелбәнат ханым Сөләймания хозурында // Йолдыз. 1914. 24 гыйнвар.

кылынган күп китапларга ихтыяҗыбыз бар»[14], – дип тә ассызыклый.

Аның кызлар мәктәпләре өчен уку китаплары буларак язылган «Гаилә тәрбиясе», «Мөгаллимәтел-бәнат», «Кызлар тәрбиясе» исемле хезмәтләре Казан, Уфа һәм Оренбург нәшриятларында берничә мәртәбә басылып чыга.

Фәхрелбәнат Сөләйманиянең «Кызлар тәрбиясе» исемле беренче хезмәте, инде кереш мәкаләдә сөйләнеп үткән кыенлыкларны узып, 1906 елда Оренбургта дөнья күрә. «Монда язылган шәйләр кечек булсын, олуг булсын, һәрбер хатын-кызлар өчен кирәкле, вә теле гаять дәрәҗәдә ачык вә җиңел булдыгыннан, бу рисалә кыз мәктәпләрендә дәрес буларак укытмак өчен мөнасиб[15] булдыгы кеби, өйләрдә һәрбер хатын вә кызларның алларында булынарак моталәга ителмәгә[16] һәм соң лаектыр. [...] Бу рисалә безнең татар телендә беренче вә әүвәленчә китаптыр. Бу илә мөһим бер рисалә вөҗүдкә китердеге өчен мөхтәрәмә мөхәррирәсе Фәхрелбәнат ханымны тәбрик», – дип котлый авторны Ф.Кәрими[17].

Фәхрелбәнат ханым хезмәтләрен кыз балаларның алдагы көннәрен күз алдында тотып, тормышта һәрбер кыз балага кирәк булачак шөгыльләргә әһәмият биреп яза. «Бүгенге көннең вак кыз балалары алдагы көндә ир вә кыз балаларны тәрбия кылып үстерүче аналар вә бер йортта булган бөтен нәрсәләрне барлап, яхшы караучы сакчылар, йортта булган бөтен җәмәгатькә тәгълим бирүче мөгаллимәләр, вә йорттагы дәрәҗәдә үзеннән артык вә олуг булган затларга хезмәт кылучы хәдимәләр, вә йортта булган авыруларны караучы табибәләр булачаклардыр. Шуның өчен кыз балаларыбызга лязем кадәр голүм диния вә голүм әхлак өйрәткәннән соңын, мәгыйшәт кылыр өчен йорт

[14] Сөләймания Ф. Бал, бал димәк берлә, авыз балланмас. Ибтидаи тәгълим // Казан мөхбире. 1906. 6 март.

[15] Мөнасиб – яраклы.

[16] Моталәга итү – уку, өйрәнү.

[17] Сөләйманова Ф. Кызлар тәрбиясе. Беренче җөзъә. Оренбург: Типо-литография М.-Ф. Каримова, 1906. Б.3.

эшләренә тәгаллекле булган нәрсәләрнең һәрберсен белдерү ляземдер»[18], – ди ул китабының сүз башында.

Укучыларга тәкъдим ителгән әлеге җыентыкта Фәхрелбәнат ханымның дүрт хезмәте урын алды. Алар барысы да кызлар мәктәпләре өчен уку әсбабы буларак төзелгән китаплар.

Оренбургта басылып чыккан «Кызлар тәрбиясе» китабында хатын-кызларга көндәлек тормыш итүдә кирәк булган хезмәтләр турында бик тәфсилләп сөйләнә[19].

Мөгаллимә кыз балаларга төпле тәрбия бирүнең кирәклегенә аеруча басым ясый. «Гыйлем – әхлакның җаны, нигезе – тәрбиядер»[20], – ди ул. Бала дөньяга килүе белән аның иң беренче тәрбия мәктәбе – анасының кочагы. Бу беренче тәрбия никадәр төпле булса, балаларның тәрбиясе дә шулкадәр камил булыр. Шуның өчен кыз балалар яхшы тәрбия күргән һәм якты фикерле булырга тиешләр, дигән фикерне алга сөрә.

1913 елда Казанда басылган «Гаилә дәресләре» хезмәтендә нәкъ менә тәрбия-тәртип, әдәп-әхлак, үз-үзеңне тиешле рәвештә тоту кагыйдәләренә – хатын-кызның гаиләдә үз-үзен тотышы, аның иренә, кайнана белән кайнатасына, ир ягы туганнарына, үз якыннарына, дусларына мөнәсәбәте, гаиләдәге вазыйфалары һ.б.га зур урын бирелгән. Шулай ук хатын-кызларның төп вазыйфаларыннан берсе булган – бала тәрбиясе киң яктыртылган. Баласы туганнан алып, аны олы тормыш юлына озатканчы, ана кеше алдында торган бурычлар күрсәтелгән; кул эшләре, музыка, дини йолалар, дөрес туклану, сәламәтлекне саклау, гигиена кагыйдәләре турында да файдалы мәгълүмат тупланган.

---

[18] Сөләйманова Ф. Кызлар тәрбиясе. Беренче җөзъә. Оренбург: Типо-литография М.-Ф. Каримова, 1906. Б.4.

[19] Сөләйманова Ф. Кызлар тәрбиясе. Икенче табгы. Оренбург: «Кәримов, Хөсәенов вә ширкәсе», [елы күрсәтелмәгән]. 32 б.

[20] Сөләймания Ф. Гаилә дәресләре. Кызлар мәктәбе өчен. Казан: Матбагаи Кәримия, 1913. Б. 16.

«Мөгаллимәтел-бәнат: Кызлар мәктәбенә махсус кыйраәт китабы»[21], «Мөгаллимәтел-бәнат: Кечкенә ханымнарга уку китабы» исемле хезмәтләрдә исә, хатын-кызларга белем һәм тәрбия бирүнең никадәр кирәкле һәм әһәмиятле икәнлеге азсызыкланып, кыз балаларны тырыш, уңган, яхшы холыклы, әдәпле булырга өндәгән хикәяләр тупланган.


Гомумән алганда, Фәхрелбәнат Сөләйманиянең мәктәп балалары өчен махсус язылган уку китаплары барлык хатын-кызлар өчен дә кирәкле һәм файдалы булганнар. Алар дин нигезләренә таянып, замана таләпләренә яраклаштырып төзелгәннәр. Билгеле, аларның кайсыбер өлешләре бүгенге көн күзлегеннән чыгып караганда актуаль түгел, әмма тарихи яктан якын килгәндә, алар, һичшиксез, әһәмияткә ия, чөнки шул заманның тормыш-көнкүрешен күз алдына китерү өчен мөһим чыганак булып торалар. Ә инде гаилә тәрбиясенә, әдәп-әхлакка, гигиенага һ.б. караган өлешләре хәзерге көндә дә үзләренең әһәмиятләрен югалтмаганнар.

*А.Ә. Зиннәтуллина*

---

[21] Әлеге хезмәтнең басылып чыгу елы күрсәтелмәгән. Ләкин китапта китерелгән мәгълүматларга караганда (автор төрек шагыйрәсе Нигяр ханымның вафат булуы турында искә ала) китап 1918 елда басылган булырга мөмкин.

## *ГАИЛӘ ДӘРЕСЛӘРЕ*[1]




[1] Сөләймания Ф. Гаилә дәресләре. Кызлар мәктәбе өчен. Казан: Матбагаи Кәримия, 1913. 106 б.

## Бисмилләһир-рахманир-рахим!

Бу рисалә гаиләнең нигезен тәшкил иткән хатыннар таифәсенә[2] йортта хатынлыкта булган вазыйфалары хакында төпле вә нигезле мәгълүмат бирмәк максуды илә язылмыштыр.

Гаилә дәресләре ханымнарга, бигрәк тә кызлар мәктәбе шәкертләренә, гаилә вазыйфалары тугрысында файдалы мәгълүмат бирдеге кеби, укуда тәмам җиңеллек вә бер тарафында әсасле[3] бер әхлак дәресе дә бирмәктәдер.

### *1 нче дәрес*
### *Хатыннарның гыйлем үгрәнүләре*

Хатыннарның гыйлем вә мәгърифәт үгрәнүләренең кирәклеге, кызларның, хатыннарның укырга вә язарга үгрәнүләре, вә хәтта аларның гыйлем вә мәгърифәт тәхсил итүләрен[4] бөтенләй зарарлы вә начар эшләрдән санаучылар әүвәл заманнарда бик күп иде. Ләкин заман бу фикернең яраксыз бер фикер икәнлеген исбат кылып, эшнең моның хилафына[5] идеген һәркемгә аңлатты. Хатыннарның белү нигъмәтеннән мәхрүм кылынуларын эстәүчеләр[6] бик хаксызлыкта булып, аларның фикерләрен тәрбияләмәк кеби бик зур бер шәрәфтән[7] ерак итмәкче булалар иде, хәлбуки эш алар аңлаганча түгел иде.

Һәмширәләрем[8]! Гыйлем вә һөнәр үгрәнмәк инсаниятә лязем булган эшләрдәндер. Пәйгамбәребез салләллааһү галәйһи вә сәлләм бу тугрыда күп хәдис шәрифләр[9] берлә гыйлем вә

---

[2] Таифә – җәмәгать, төркем.
[3] Әсасле – нигезле, төп.
[4] Тәхсил итү – белем алу.
[5] Хилаф – кире, тискәре.
[6] Эстәүче – теләүче.
[7] Шәрәф – кадер, хөрмәт, дан.
[8] Һәмширә – кыз туган, кыз кардәш.
[9] Шәриф – кадерле, кадерләүгә лаек.

һөнәрнең кадерен аңлатып, аны үгрәнмәк важиб[10] идеген адәмнәргә белдермеш вә үгрәнергә боермыштыр.

Безне юктан бар кылган Җәнаб Хакны белмәк, һәрбер эшнең хакыйкатен аңламак, адәмнәрнең һәрбер гамәл вә эшләрендә изгесен вә явызын аерып белмәк, адәмлекнең кадерен белмәк, дөнья вә ахирәт эшләренең яхшы эшләнүенә тырышмак, хаҗәт[11] нәрсәләрне җиңеләйтү берлә гүзәл тереклек кылмак, хасил һәрбер җәһәттән яхшы вә мөкәммәл булмак өчен, адәмнәрнең гыйлем вә һөнәр үгрәнергә бик каты ихтыяҗлары бардыр.

Инде шулай булгач, хатыннар да ирләр кеби адәмнәр. Һәм дә хөрмәтләргә тиешле булган адәмнәрдер, вә гаиләнең нигез ташларыдырлар. Алай булса, аларның да гыйлем вә һөнәр нигъмәтеннән үзләренә кирәк кадәрле өлеш алырга кирәклеге мәйдандадыр.

Аллаһ тарафыннан гыйлем үгрәнү тугрысында килгән әмерләрне, пәйгамбәребезнең хәдисләрен тикшереп карасак, аларда ирлек-хатынлык аслан[12] юктыр; ягъни кирәк ир, кирәк хатын булсын, һәрбер адәмгә гыйлем үгрәнү берлә әмер кылынмыштыр.

Хатыннар яратылышларыннан балалар тәрбия кылу вазыйфасы берлә тәклиф кылынмышлардыр[13]. Бер бала дөньяга килүе берлә, аның әүвәлге тәрбия мәктәбе – анасының кочагыдыр. Әүвәлге тәрбия никадәр төпле булса, шуңар карап башкаларының да камил дәрәҗәдә үгрәнүләре анык булганнан, балаларның тәрбиясе камил булсын өчен, кызларыбызның, хатыннарыбызның гүзәл тәрбия күргән булуы, хосусан тәрбияле фикерле булулары ляземдер.

Балалар тәрбиясе хатыннарга махсус бер вазыйфа булган өчен, бу тәрбиянең дәрәҗәсе тәрбия кылучыларның белекләре дәрәҗәсендә булуы лязем килер.

---

[10] Важиб – шиксез үтәлергә тиешле.
[11] Хаҗәт – кирәкле, кирәк.
[12] Аслан – һич, һичбер вакытта, беркайчан да.
[13] Тәклиф кылыну – боерылу, әмер ителү.

## *2 нче дәрес*
## *Белек*

Балалар тәрбиясе гомуми тәрбиянең нигезе булганнан, «Хатыннарының тәрбиясе камил булган кавемнәр алга китәр» дигән кагыйдәне һич тартышмый кабул итмәк һәрбер хаклыкны белүчеләрнең бурычлары җөмләсеннәндер.

Әгәр дә без шушы рәвештә кызларыбызга гыйлем вә һөнәр үгрәтүгә каршы торуыбызда дәвам итсәк, башка укымаган милләтләр кеби без дә тиздән бетәчәкләрбез.

Фикер белек нуры берлә нурланмаса, адәм наданлык караңгылыгында калыр. Тәрбия фикрияләре камил булмаганнарның тән вә дин тәрбияләре дә яхшы булмас. Чөнки гыйлем вә мәгърифәт тәрбия фикрия ияләрендә генә булып, тәрбияи фикрияләре булмаган адәмнәр үзләренең дөнья вә ахирәт эшләрен эшләүдә ялгышып, кимчелекләргә төшәрләр.

Рух гыйлем вә мәгърифәт берлә камилләнер. Хәтта гыйлем вә мәгърифәт үзе хәят дип әйтергә дә мөмкин. Инсаниятнең кадере мәгариф берләдер.

Белеклек латыйф хактыр безгә, ай җан,
Белү берлә бәхетле булды инсан.

Гыйлем вә мәгърифәттән һичбер зарар күренгәне юктыр. Аны яхшы үгрәнмәк һөнәрдер. Дөньяда никадәр явызлык булса, һәрбере наданлыктан торыр. Иң зур һәлаклек чокыры наданлык, вә адәмлекне бетерүче дә наданлыктыр.

Күркәм тәхсил күргән[14], холкын төзәткән бер хатын, әлбәттә, һәр җирдә хөрмәтләнергә тиештер. Матурлык узып китә торган бер зиннәттер. Мәгърифәт адәмнең үзе берлә бергә яшәр. Фикерен наданлык шомлыгыннан пакьләгәннәр намусын, гыйффәтен, хатынлыгының кадерен, шөбһәсез, бөтен мәгънәсе берлә белер. Бәлки адәм һич нәрсәдә алданмас. Надан хатыннарның балаларына бирәчәк тәрбияләре дә кимчелекле вә төпсез булыр.

---

[14] Тәхсил күрү – белем алу.

Адәмлек өчен кирәкле булган намус, гыйффәт, оят кеби фазыйләтләрне[15] иң башлап тудыручы – гыйлем вә мәгърифәттер. Бәхетнең дә, рәхәтлекнең дә, байлыкның да нигезе, төбе гыйлем вә мәгърифәттер. Галим вә камил булганнарның дәрәҗәләре бик зурдыр. «Гыйлем мәртәбәсе – мәртәбәләрнең иң олугысы» дигән сүз бик тугры бер сүздер. Кайсы җирдә гыйлем вә мәгърифәт булса, ул җир бер файдасыз коры ташлык җирдер. Күркәм халыклар берлә бергә булган гыйлем адәмнәрне бәхетле итәр, тергезер вә югары дәрәҗәгә күтәрер. Кабахәт эшләргә сәбәп булган белекләр һәр җирдә, һәр диндә гайбтер[16], гыйлемнән максуд – күркәм эшләр вә изге гамәлләрдер. Шуның өчен белгәннәр берлә гамәл кылмак тиешледер.

Һәр хатын үзенә кирәкле булган гыйлем вә һөнәрләр берлә бергә, кул эшләрен вә йорт эшләрен үгрәнергә вә белергә тырышмак ляземдер.

Хасил[17]: мөхтәрәмә туташлар! Ничек тә адәм булырга тырышыйк, укып, күркәм холыкларга, изге гамәлләргә якын булган мәгарифне үгрәнеп, ике дөньяда бәхетле булыйк.

## *3 нче дәрес*
## *Гыйффәт*

Гыйффәт – адәмнең нәфесе арзусына[18] ияреп, начар эшләргә катышудан үзен саклавыннан гыйбарәт булган бер гүзәл эштер. Намусын, кадерен вә бөтен мәртәбәсен саклап, начар вә кабахәт эшләрдән, гаеп булган эшләрнең һәрберсеннән качып, адәмлек өчен лязем булган тугры җәүһәрдер ки, адәмнәрнең төп кадер вә кыйммәте моның берлә үлчәнер. Хатыннарның үзләренә махсус булган иң гүзәл, иң кадерле зиннәтләре – гыйффәттер. Гыйффәтсез хатын нурсыз, пычрак, җирәнгеч бер гәүдәдер. Гыйффәтләрен сакларга тырышмаган хатыннар һичбер вакытта

---

[15] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш, яхшы сыйфат.
[16] Гайб – кимчелек, җитешсезлек, гаеп.
[17] Хасил – нәтиҗә.
[18] Арзу – теләк.

мәхәббәт вә илтифатка[19] лаек була алмаслар. Ханымлык мондый хатыннардан ерактыр. Гыйффәтсез хатыннар адәмнәр җәмгыятенең кадерсез, җирәнгеч, ким, хур булган берәр шайкасы булып, начарлык берлә хөкем ителмештер. Аларга вөҗдан ләгънәт, дөнья тарлык итәр, Җәнаб Хак та җәза бирер. Гыйффәтенә кимчелек китергән бер хатын үзендә бетерү мөмкин булмаган бер тап ясаган булып, гөнаһ вә кайгыга төшкән булыр.

Ханым, кызлар! Сезнең өчен иң зур байлык, иң зур мәртәбә, иң зур камил фазыйләт[20] – гыйффәттер. Гакыллы бер хатын, фәкыйрь дә булсын, мәгънәви кыйммәте бик югарыдыр. Гыйффәтсез булганнар, никадәр бай булсалар да, карамакта янә фәкыйрь вә кадерсезләрдер.

Муеннарыгызга таккан алтыннарыгыз, башларыгызга, күкрәкләрегезгә кадаган бриллиантларыгыз, хәтта касса тулы акчаларыгыз берлә дә гыйффәтне сатып алу мөмкин түгелдер. Гыйффәт бер зур байлыктыр ки, аның бәһасен чикләмәк һичбер мөмкин түгелдер. Хатыннар матурлык вә сылулыкларына, байлык вә малларына түгел, гыйффәтләренә куанырга тиештер.

Гыйффәтнең тәмам нәрсә икәнен аңлар өчен, аннан туган фазыйләтләрне белмәк ляземдер. Хәкимнәрнең[21] әйтүенә карагында, гыйффәттән унбер фазыйләт туар ки, алар да түбәндә күрсәтелмешләрдер.

1. Хәяэ[22].
2. Сабыр.
3. Дәгать[23].
4. Нәзаһәт[24].
5. Канәгать.
6. Вәкарь[25].

---

[19] Илтифит итү – хөрмәтләү, олылау, ярату.
[20] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш.
[21] Хәким – акыл иясе, галим.
[22] Хәяэ – оятлылык, тыйнаклык.
[23] Дәгать – догалылык, динилек.
[24] Нәзаһәт – гыйффәтлелек, намуслылык.
[25] Вәкарь – горурлык, үз-үзеңне олы тота белү.

7. Рәфыйкъ[26].
8. Хәсән сөлүк[27].
9. Вәрәгъ[28].
10. Интизам[29].
11. Сәхадер[30].

*Хәяэ*. Нәфеснең гакылда, шәригатьтә, гадәттә кабахәт вә гаеп булган эшләрне эшләүчеләргә, «фасыйк»[31] гакылда, кабахәт булган эшләрне кылучыларга «гакылсыз», гадәттә кабахәт булган эшләрне кылучыларга да «ахмак» диярләр. Оятлы булган бер өч төрле кабахәтнең өчесеннән дә сакланырлар. Оятның иманнан икәнлеген белмәк һәркемгә лаземдер. «Әл-хәяэ мин әл-иман»[32] димешләр.

## *4 нче дәрес*
## *Сабыр*

*Сабыр*. Бер теләгән нәрсәнең булмый калуына яки булдырасы килмәгән хилаф[33] эшнең булуына каршы торып түзүгә сабыр диярләр. Гыйффәттән туган сабыр «эстәнелгән[34] нәрсәнең булмый калуына түзмәк» кыйсеменнән[35] булып, икенче кыйсеме сәбат[36] мәгънәсендәдер. Болай булса, сабырны гомуми сурәттә «кайгы вә катылыкларга каршы чыдамлы вә түземле булмак нәфес арзуларына[37] иярүдән сакланмак» дип тә тәгъриф кылмак[38]

---

[26] Рәфыйкъ – иптәшлек, дуслык.
[27] Хәсән сөлүк – үз-үзеңне яхшы тоту.
[28] Вәрәгъ – харамнан саклану, тыелу.
[29] Интизам – тәртиплелек, кагыйдә буенча эш итү.
[30] Сәха – юмартлык.
[31] Фасыйк – начар юлда йөрүче, әхлагы бозык, имансыз.
[32] «Оятлылык – иманнан» мәгънәсендә.
[33] Хилаф – киресе, каршы.
[34] Эстәү – теләү.
[35] Кыйсем – өлеш, кисәк.
[36] Сәбат – фикердә, эштә нык торучанлык, чыдамлылык, даимилек.
[37] Арзу – теләк.
[38] Тәгъриф кылу – аңлату, билгеләү.

мөмкин. Сабыр бик мактаулы һәм күркәм холыкларның берседер. Сабыр – максудларның ачкычыдыр. Сабырлык берлә һәрбер морадларга[39] ирешү мөмкин булыр.

Коръән Кәримдә «Аллаһ Тәгалә сабыр итүче коллары берлә бергәдер» дия боерылмыштыр.

*Дәгать* – шәһвәтнең[40] кызган вакытында нәфесне басып, ихтыярны кулдан җибәрмәссезлектер. «Нәфескә көч җитү – өстенлекнең иң олугъсыдыр» дигәннәре никадәр тугры сүздер. Шәһвәткә ияреп эш кылганнар бөтен адәмлек фазыйләтләреннән[41] мәхрүм булырлар.

*Нәзаһәт* – адәмнең үзенә дә, башкаларга да залим[42] вә дошманлыкка сәбәп булмаслык рәвештә мал казанмагы вә аны тиешле вә мактаулы урыннарга сарыф кылмагыдыр[43] ки, моның да күркәмлеге сөйләп бетергесез дәрәҗәдә күптер.

*Канәгать*. Кулында кирәк-яракларына тотарга җитәрлек кадәр мал булып та, «Миңа фәләнчә кадәр кирәк, төгәнчә кадәр кирәк», – дия борчылмый, барына риза булуга канәгать диярләр. Комсызлык вә тамак һәрвакытта хурлыкка сәбәп булыр. Шулай да булса, гыйлем вә мәгърифәт үгрәнүдә җитәрлек кадәрле бергә канәгатьләнү яки эш вә кәсептә ялгыз көн күрә вә яши алырлык кадәр казанмак берлә канәгатьләнмәк кәсептән тыелмак муафикъ түгелдер. Эштә, мәгърифәттә, һөнәрдә, мәгыйшәттә[44] канәгать итәмен диеп алга китәргә тырышмаганлык – канәгатьнең мәгънәсен аңламаганлык димәктер. «Канәгать бетми-төкәнми торган бер хәзинәдер» мәалендәге[45] мәшһүр сүз фани булган ләззәтләрне хурлау тугрысында булган икътифа[46] мәгънәсендәге чын канәгатькә гаидтер.

---

[39] Морад – максат, ният, теләк.
[40] Шәһвәт – көчле дәрт, теләк.
[41] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш, яхшы сыйфат.
[42] Залим – мәрхәмәтсез.
[43] Сарыф кылу – тоту.
[44] Мәгыйшәт – тереклек итү, көнкүреш, тормыш.
[45] Мәаль – аңлашылган мәгънә.
[46] Икътифа – берәүнең артыннан китү, берәүгә иярү.

*Вәкарь* – максудларга керешкәндә акрынлык димәктер. Адәм бер эшне башлаганда, ашыкмый-кабаланмый акрынлык берлә эш кылмак тиештер. Чөнки ашыгычлык булачак эшнең булмый калуына сәбәп булыр. Шулай да бу акрынлык эстәнелгән[47] нәрсәнең вакытын үткәрмәслек дәрәҗәдә булуы да ляземдер.

*Хәсән сөлүк* – күркәм холыклар вә кирәкле һөнәрләрне тәхсил итү[48] берлә камил адәм булырга мәхәббәт итмәк мәгънәсендә булган бер фазыйләттер[49]. Инсаниятне камилләргә мәхәббәт берлә гыйлем вә мәгърифәт хасил итәргә тырышучылар һәркем тарафыннан сөелгән фазыйләт ияләредер.

## *5 нче дәрес*
## *Вәрәгъ*[50]

*Вәрәгъ* – шәригатькә, гакылга, мөрәүвәткә[51] муафикъ булган яхшы эшләргә даимчылыктыр ки, изге эшләрнең һәрберсенә мәхәббәт берлә керешмәк – бу фазыйләтнең җимешедер.

*Интизам* – эшләрнең кирәгенчә вә мәслихәткә[52] муафикъ рәвештә эшләнүенә көч җитмәктер. Ягъни бер эшнең ничек булуы лаек, вә ни рәвештә эшләнергә кирәк, вә мәслихәткә ничек муафикъ булса, шул рәвешчә эшләргә кулдан килеп, шулай эшләргә тырышмак интизамдыр. Ашауда-эчүдә, йокыда, эш вә кәсептә, әлхасыйль[53], һәрбер эштә интизамнан чыкмаган адәм бәхет вә сәгадәткә[54] ирешер.

---

[47] Эстәү – теләү.
[48] Тәхсил итү – белем алу.
[49] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш, яхшы сыйфат.
[50] Вәрәгъ – харамнан саклану, тыелу.
[51] Мөрәүвәт – кешелеклелек.
[52] Мәслихәт – тиеш, яраклы, киңәш ителгән.
[53] Әлхасыйль – җыеп әйткәндә.
[54] Сәгадәт – бәхет.

*Сәха*[55] – лаек булган нәрсәне лаек булган кешегә лаек булган кадәрле бирмәктән гыйбарәт булган инсаниятькә лязем бер фазыйләттер. Сәха алты төрледер:

1. керемдер ки, бер нәрсәне җиңеллек берлә, күңел хушлыгы берлә бирәсе килеп бирмәктер;

2. исардыр[56] ки, үз кирәгенә тотмыйча, үзенә кирәк була торып, кешегә бирмәктер;

3. нәбелдер[57] ки, бирә торган нәрсәсен сөенә-сөенә бирмәктер;

4. дус вә ишләр мөшарәкәте[58] берлә бергә малны өләшмәктер ки, моңа «муасат»[59] диярләр;

5. өләшү важиб[60] булмаган малны каршына бер нәрсә өмет итми бирүдер, моңа «сәмахәт»[61] диярләр;

6. кичү лязем булмаган нәрсәне шәфкатьтән кичмәк мәгънәсендә булган «мәсамәхәттер[62]». Мәсәлән, бер адәм икенче адәмдә булган алачагын бер мәкяфәт[63] өмете булмый кичмәк, я бер микъдарын һибә[64] кылмактыр. Юмартлык гадәтеннән артык булса, исраф булыр ки, диндә харам, гакылга салып караганда начардыр. Бик кимендә саранлыктыр ки, бу да бик гаептер. Юмарт адәмнәрне һәркем сөяр. Юмартлык әҗер вә савапка сәбәп булган мәкъбуль[65] эшләрдәндер. Садака бәлаләрне кайтара торган бер дәвадыр. Бер фәкыйрь үзе эшләп акча табарга көче җитмәсә, садака алырга мөстәхыйкътыр[66]. Вә аңа садака бирмәк важиб

[55] Сәха – юмартлык.
[56] Исар – олылау, малны бик юмарт тарату.
[57] Нәбел – вөҗданлылык.
[58] Мөшарәкәт – катнашу, уртаклык.
[59] Муасат – ярдәмләшү, булышлык.
[60] Важиб – тиешле, шиксез үтәлергә тиешле.
[61] Сәмахәт – юмартлык.
[62] Мәсамәхәт – кичерү.
[63] Мәкяфәт – яхшылыкка каршы эшләнгән яхшылык, бүләк.
[64] Һибә – бүләк итеп бирү.
[65] Мәкъбуль – кабул ителгән, яхшы дип табылган.
[66] Мөстәхыйкъ – хаклы, лаеклы.

булыр[67]. Ләкин тап-таза булып та, теләнчелекне һөнәр вә сату коралы итеп йөрүчеләргә акча бирмәк аларны хәйләкәрлеккә вә сорану хурлыгына кызыктыру булып, аслан[68] дөрес түгелдер.

## *6 нчы дәрес*
## *Хикмәт*

Хәкимнәр[69] хикмәтне киләчәктәге рәвешчә тәгъриф кылалар[70]. Хикмәт шундый бер хәлдә ки, рух ихтыярлы булган эшләренең һәрберсендә тугрыны хатадан аерыр. Яки хикмәт бер нәрсә хакында иң тугры хөкемне табып чыгармактыр. Алай булса, «табигать» дигән сүзгә ни мәгънә бирербез? Табигать – яратучы Аллаһы Тәгаләнең ярату кагыйдәсендәге хикмәттер. Мәсәлән, инжир агачының хөрмә бирмәгәнлеге ярату кагыйдәсенең лязем иткән хикмәтедер.

Хикмәтне бик ачык белер өчен, аннан туган берничә фазыйләтләрне[71] белмәк ляземдер ки, алар да шушылардыр:

1. сафвәти зиһни[72];
2. җәүдәти фәһми[73];
3. зәкяэ[74];
4. хөсни тасаввыр[75];
5. шәһвәләти тәгаллем[76];
6. хифыз[77];

---

[67] Важиб булу – тиешле, үтәлергә тиешле дини эш.
[68] Аслан – һич, һичбер вакытта, беркайчан да.
[69] Хәким – акыл иясе, галим.
[70] Тәгъриф кылу – аңлату, билгеләү.
[71] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш, яхшы сыйфат.
[72] Сафвәти зиһни – саф зиһен.
[73] Җәүдәти фәһми – аңның чисталыгы; бу төшенчәгә текстта аңлатма бирелмәгән.
[74] Зәкяэ – сафлык, чисталык, пакьлек.
[75] Хөсни тасаввыр – матур сурәтләүләр.
[76] Шәһвәләти тәгаллем – белем алу, өйрәнү.
[77] Хифыз – хәтердә тоту, күңелдән белү.

7. тәхаттыр[78].

Сафвәти зиһни – эстәнелгән[79] нәрсәне уйлап чыгаруда зиһен чуалып, нәфеснең мәшәкатькә төшми тиз уйлап чыгаруыдыр.

Зәкяә – зиһеннең, эшнең әүвәленнән ахырына бик тиз күчмәгедер ки, моны аңламак гакыл җитмәк дип тә әйтерләр.

Хөсни тасаввыр – бер нәрсәне аңлап чыгаруда аңар дәхели[80] булмаган башка нәрсәләрне катнаштырмый, яхшы аңламак куәтедер.

Шәһвәләти тәгаллем – артык мәшәкатьләнми, эстәнелгән нәрсәне үгрәнмәк куәтедер.

Хифыз – укып аңланган нәрсәне күңелгә бикләмәктер. Күңелгә беркетмәк куәте булмаса, дөнья бу көнге тәрәккыйларга[81] ирешмәс иде.

Тәхаттыр – күңелгә бикләнгән нәрсәне эстәнелгән вакытта мәшәкатьсез хәтергә китерә алудыр. Бу кеби адәмгә «җавабы кесәсендә» диярләр. Менә гыйлем әхлакча без аңлый ала торган хикмәт шул саналган холыклар вә фазыйләтләр берлә табылыр. Хикмәт иясе булганнарга хәким диярләр. Хикмәт гыйлем куәтенең уртача хәле булып, артыгына хәйләкәрлек диярләр, бик азына аңгыралык диярләр.

## *7 нче дәрес*
## *Галиҗәнаблык*

*Голү*[82] *җәнаб*[83] – бер куәттер ки, адәмнең байлыгына, фәкыйрьлеккә вә холыкның мактау вә хурлавына каршы хәбәрләнми, вә дөньяның алмашуларыннан кайгырмый, гайрәтенә вә гали һиммәтенә[84] кимчелек китермәведер. Ягъни бай булса,

---

[78] Тәхаттыр – хәтерләү, үткәнне искә төшерү.
[79] Эстәү – теләү.
[80] Дәхели – катнашкан, керешкән, караган.
[81] Тәрәккый – алга китү, прогресс.
[82] Голү – югарылык, биеклек.
[83] Җәнаб – берәүне олылау йөзеннән әйтелә торган сүз.
[84] Һиммәт – тырышлык.

зурланмый, фәкыйрь булса, хурланмый, мактавына куанмый, яманлавына кайгырмый, дөньяның алмашынуларына һич исе китми, һәрвакытта бертөрле булып, үзенең дәрәҗә вә һиммәтен саклый алуыдыр.

*Газыйм*[85] *һиммәт* – адәм һәрбер вакытта чын гүзәллекне вә адәмнең үзендә булган кәмаләтен[86] күзгә алып, дөньяның ни алга баруыннан артык шат, ни дә артка китүеннән кайгылы булмауларыннан гыйбарәт булган бер хасияттер[87].

*Сабыр* – кайгы вә катылыкларга каршы чыдамлы вә түзелме булудан гыйбарәт булган бер файдалы эштер ки, моңар тотынганнар, билгеле, артык кайгырып, үзләрен бетерүдән котылырлар. Бу урындагы сабыр батырлык кыйсеменнәндер[88].

*Нәҗдәт*[89] – хәтәрләргә очраганда, үзен куркудан саклаудан гыйбарәт булган батырлыктыр ки, бу фазыйләт[90] адәмне тәһлекәле[91] бер вакытта бер тиешсез эш эшләп ташлаудан саклар.

Яисә нәждәт адәм үзенең түзә алуына ышануыдыр ки, мөшкел эшләрне бетермәк моның берлә генә мөмкин булыр.

*Хилем*[92] – ачу-кочу вакытында юаш булмактыр ки, зур фазыйләтләрнең берсе дә будыр. Ачуның бик кызу вакытында күңелнең ашкынмый, тыныч тора алуы адәмне бик күп хәтәрләрдән вә начарлыклардан саклар. Йомшак күңелле кешеләрне һәркем сөяр.

*Сөкүн*[93] – тавыш-гауга вакытларында җиңеллек вә кызулык күрсәтми, акрынлык вә сабырлыкны сакламактыр. Кызулык сихәткә, хәтта тереклеккә дә зарар бирер. Бу кызулык вә җиңел ачулылык һәр заман иясен оятка калдырыр.

---

[85] Газыйм – бөек, чиксез зур, җитди.
[86] Кәмаләт – камиллек.
[87] Хасият – үзенчәлек.
[88] Кыйсем – өлеш, кисәк, рәт.
[89] Нәждәт – көч.
[90] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш, яхшы сыйфат.
[91] Тәһлекә – һәлакәт, куркыныч хәл.
[92] Хилем – йомшаклык, юашлык.
[93] Сөкүн – тынычлану, тынлык, тукталу.

«Ачу берлә саргайган, үкенеч берлә кызарыр» дигән сүз бик тугры сөйләнмештер.

*Тәвазыйгъ*[94] – адәмнәрнең үзләрендә бер артыклык бар дип уйлап, үзләрен халыктан зур дип белмәүләре, байлык, мәртәбә вә зурлык җәһәтеннән үзләреннән түбән дәрәҗәдә булганнарны үзләреннән кечкенә санамауларыннан гыйбарәт булган бер яхшы эштер. Үзен һәркемнән кечкенә күргән адәм олугдыр. Түбәнчелек инсаниятнең бик зур артыклыгыдыр. Алай да моны бик арттырып җибәреп, хурлыкка төшмәк яки рия[95] мәртәбәсенә төшермәк тә муафикъ булмас. Хасил[96]: һәрбер эшнең уртачасы гүзәлдер.

## *8 нче дәрес*
## *Шәһамәт*

*Шәһамәт*[97] – дәрәҗә артуга вә яхшы исемгә сәбәп булырлык зур вә күркәм эшләрне эшләргә нәфеснең кызыгуыдыр.

*Тәхәммел*[98] – күркәм сыйфатларны вә гали эшләрне кәсеп итү тугрысында иҗтиһадны[99] өскә алып, тәннең мәшәкатьләнүедер.

*Хәмиять*[100] – намус вә динне, вә инсаниятне саклау юлында иренми тырышмактыр.

*Рикъкать*[101] – бер адәмнең женестәшләрендә күренгән кайгы вә хәсрәтләре өчен үзендә дә кайгы хасил итүедер. Йомшак күңеллелек рәхимле булырга сәбәптер. Хисле күңел һәрвакыт йомшак булыр. Ләкин бу тугрыда коры кайгырудан гына бер файда да килмәс. Бәлки кайгылы кешедән кайгыны җибәрү сә-

---

[94] Тәвазыйгъ – түбәнчелек; тыйнаклык, әдәплелек.
[95] Рия – бер эшне кешегә күрсәтү өчен генә эшләү; икейөзлелек.
[96] Хасил – нәтиҗә.
[97] Шәһамәт – үткенлек, зирәклек.
[98] Тәхәммел – күтәрә алу, түзү, чыдау.
[99] Иҗтиһад – тырышлык.
[100] Хәмиять – башкаларның зарар китерүеннән саклау.
[101] Рикъкать – нечкәлек, күңел йомшаклыгы.

бәпләренә керешеп, анын котылуына чара эзләмәк кирәктер ки – йомшак күңеллелекнең тәмам мәгънәсе менә бу урындадыр.

Голү җәнабтән башлап сөйләнгән шул унбер фазыйләт[102] куәи газыбиянең[103] уртача дәрәҗәсе булган батырлыктан туган иң гүзәл холыклардан булып, бу холыкларның адәмдә җыелмагы дөнья вә ахирәттә бәхетлелеккә сәбәп булыр. Шуны да әйтеп китмәк ляземдер ки, һәрнәрсәнең бик артык вә бик кимендә зарар бардыр. Эшләрнең артыграгы вә гүзәлрәге уртача булганыдыр. Югарыда саналган гафләт[104], хикмәт вә шәҗагатьнең[105] җыелуыннан гаделлек дигән инсаниятнең күз нуры хасил булыр.

## *9 нчы дәрес*
## *Эш вә тырышмак*

Җәнаб Хак «Адәм үзе иҗтиһад итсә[106], тырышса гына таба» мәалендәге[107] аять Кәримәсе илә тырышмакның фарызлардан[108] булганын колларына белдермештер. Һәмширәләр! Адәмнең тәнен идарә кыла торган димагъ[109], ягъни ми фикер вә уй куәте өчен бер билгеле урындыр. Ми фикер вә мәгърифәт нуры берлә нурланмаса, тынык булып калыр. Үзенә тиешле вазыйфасын кирәгенчә кыла алмас. Ул вакытта ми дә тәнне яхшы идарә кылудан гаҗиз калыр. Фикернең нурлануы исә, эш вә тырышлык берлә хасил булыр. Бу эш ялгыз мигә генә махсус түгелдер. Адәмнең тәнендә булган әгъза эшләргә вә хәрәкәтләнергә мохтаҗдыр. Хәрәкәтләнмәсә, авыруга, кимчелеккә дучар булыр. Хәтта җан да тырышмак, эшләмәк берлә тәрбияләнер вә камилләнер. Алай булса, эш эшләмәк, тырышмак адәмнең тәненә матди вә мәгънәви сыр-

[102] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш, яхшы сыйфат.
[103] Куәи газыбия – ачулану көче.
[104] Гафләт – игътибарсызлык, гамьсезлек.
[105] Шәҗагать – батырлык, кыюлык, гайрәт.
[106] Иҗтиһад итү – тырышу.
[107] Мәаль – аңлашылган мәгънә.
[108] Фарыз – үтәлергә тиешле.
[109] Димагъ – ми.

хаулар килүгә каршы иң нык, иң камил булган бер калкандыр. Уйланылса, беленер ки: адәмнәр бер кабым икмәкне йотар өчен дә чәйнәмәк гайрәтенә мохтаҗлардыр. Адәмнәр туган вакытларындагы кеби калсалар, дүрт аяклы хайваннан нинди аермалары булыр иде? Димәк ки, безне адәм иткән нәрсә – тырышмактыр. Тырышмак булмаса, шул күрә торган тәрәккый[110] вә сәгадәтләребезне кайдан табар идек?

Сихәт, гыйлем, байлык, бәхет кеби адәмнәрне рәхәтлеккә ирештерә торган нәрсәләр күктән яулыкка төйнәлеп төшми. Болар бар да тырышу аркасында гына табыладыр. Хайваннарга кадәр яшәмәк өчен тырышырга, бер кабарлык ризык табар өчен йөгереп эзләргә үзлекләреннән мәҗбүрләрдер.

Эшләмәк, тырышмак – адәмнәрнең яратылыштан булган бер вазыйфаларыдыр. Тәкъдирдә булса, булмый калмас, диеп утырмыйк. «Алма пеш, авызга теш», дигәнчә көтеп тормак адәмнәрне бәхетле итмәс. Һәрнәрсәне тәкъдиргә сылтап, үзе булыр әле дип көтмәк наданнар эшедер.

Вакыйган, Аллаһы Тәгаләнең тәкъдирләренә ияреп, тәвәккәл кылмак та инсаниятә лязем булган галәмәттер. Алай да тәвәккәлнең мәгънәсендә сәбәпләренә керешүнең дә кергәнлеге онытылмасын.

Һәр эш тәкъдир иләдер, әмма
Тырышмак берлә бергәдер.
Тырышмаклык илә тәкъдир
Ике игез туганнардыр.

## *10нчы дәрес*
## *Янә тырышмак*

Бу дөньяда һәркемнең үзенә күрә күп вазыйфалары, ягъни кылуы лязем булган күп эшләре бардыр. Адәм бу эшләрне тырышып эшләмәсә, дөньяда яши алмас. Кеше ярдәме берлә яшәсә дә, бәхетле вә рәхәтле булмас. Хәтта теләнчеләр дә биш-ун тиен

[110] Тәрәккый – алга китеш, прогресс.

табар өчен йөрмәгә, теләнмәгә, мең төрле сүзләр берлә халыкның мәрхәмәтен тартырга тырышырлар.

Күренә ки, һәрбер нәрсә тырышу берлә генә хасил була икән. Тән симертеп тик утырудан һәрвакыт зарар гына торыр. Эшсезлек тереклеккә дә зарар китерер.

Тырышканнар мал табар, югары менәр, тырышмаганнар мәхрүм вә өметсез булыр, үкенер.

Ханымнар! Тырыш кеше эшлеклелек вә Аллаһның ярдәме берлә һәрбер мөшкилләрне[111] җиңел итәр. Мәңге торачак кеби тырышмак, таңга да чыкмый үләчәк кеби Аллаһы Тәгалә тыйган эшләрдән, явызлыклардан сакланып, гыйбадәт кылмак – иң мөкатдәс бурычлардандыр. Кяинатка[112] кадәр һичвакыт тик тормый, үзләренең хәрәкәтләрендә дәвам итәләр.

Шуны да белмәк тиештер ки, адәмнең эшлекле булуы өчен әүвәл эш сөюче булу ляземдер. Теләмичә, көчләнеп эшләүдән бер күркәм нәтиҗә хасил булмас. Адәм сөя-сөя тырышырга, башлаган эшеннән аерылмый, чын күңелдән эшләргә кирәк. Бу да эшләүнең файдаларын белү берлә булыр. Алга китүне теләп тырышканнар бәрәкәт вә олуглыкка ирешерләр. Тырышкан милләтләр һәрвакыт алга китәрләр, камил сәгадәткә ирешерләр.

Ханымнар! Без дә яхшы укырга тырышыйк, инсаният бурычларыбызны үтәр өчен тырышудан һич кире тормыйк. Заманны файдасыз эшләр берлә уздырганнар иң зур сәрмаядән[113] файдаланмаганнары өчен шелтәләнергә тиештерләр. Бушка узган заманнар озындыр, рәхәтсездер. Эшсезлек үкенечкә сәбәптер. Эшләмәк адәмнәрнең яктысы вә фәкыйрьлекнең иң файдалы даруыдыр.

[111] Мөшкил – читен, кыен, авыр; проблема.
[112] Кяинат – галәм, бөтен дөнья.
[113] Сәрмая – акча, капитал.

## *11нче дәрес*

Әхлакның тәгърифе[114] кирәкле вә үзгәрүе мөмкин булып булмавы – адәмнең төбе, нигезе, беренче матди, берсе мәгънәви булган ике нәрсәдән кушылгандыр ки, берсенә «гәүдә», икенчесенә «җан» диярләр. Гәүдә күз белән күренә вә сизелә торган нәрсәләрне белер.

Җан – күңел күзе, гакылга муафикъ булган нәрсәләрне аңлар. Җан берлә гәүдәнең берәр килеш вә сурәте бардыр ки, болардан җанның килеш вә сурәтенә «холык» диярләр. Болай булса, холык – адәмнең эчке сурәте, гәүдә – тышкы сурәтедер. Холык бер «мәләкә»[115] гадәтләнгән нәрсәдер ки, аның сәбәбе берлә җаннан җиңеллек берлә эшләр садир булыр[116].

Җанның тәнгә караганда кадере югары булганнан, эчке сурәт, ягъни холык гүзәллеге тышкы сурәтнең гүзәллегеннән артыграктыр. Адәм сурәте матурлыгы берлә түгел, холкы яхшылыгы берлә гүзәл була алыр.

Гыйлем, әхлак адәмнең чын мәсләген, бара торган юлын тәгаен кылган кагыйдәләрдән бәхәс кыла торган бер гыйлемдер ки, яратылуыбыздан максут ни идеген аңламак, көчне вә коралларны шул якка таба сөрмәк кеби нәрсәләрне үгрәткән гыйлем шулдыр.

Мәләкә нәфсани[117] сурәткә кайтса, аңа «хәл» диярләр, көлмәк кеби.

Җисмани[118] сурәткә кайтса, «гадәт» диярләр. Гадәт берлә әхлак икесе-ике нәрсәдер. Холыкларның бер-берсенә охшамаган вә бер кавем каршында күркәмгә саналып, икенче кавем каршында гаеп саналган хәлләре гадәттер.

Гыйльме әхлак бердер, ягъни кагыйдә вә кануннары бөтен адәм балаларына бер төсле булып, мәсхәб вә милләт башкалыгы

---

[114] Тәгъриф – аңлату, билгеләү.
[115] Мәләкә – өйрәнү, осталык, күнекмә.
[116] Садир булу – барлыкка килү.
[117] Нәфсани – хайвани, табигатькә караган.
[118] Җисмани – гәүдәгә, тәнгә бәйләнешле; физик; матди.

берлә үзгәрә торган түгелдер. «Иманның камиллеге күркәм холыктыр» вә «мин күркәм холыкларны тәмам кылыр өчен җибәрелдем» мәальләрендәге[119] хәдис шәрифләр берлә гыйльме әхлакның кадер вә хөрмәте күз алдында зураер.

## *12 нче дәрес*
## *Холык үзгәрәме, үзгәрмиме?*

Холыклар үзгәрәме, үзгәрмиме? Бу сөальгә хәкимнәр[120] төрлечә җавап бирмешләрдер. Кайсылары үзгәрә, кайсылары яратылыштан булган бер эш булганлыктан, үзгәрми димешләр.

Холык бөтенләй алышынмас; алай да мөмкин кадәрле төзәтелә алыр. Әгәр төзәтү мөмкин булмаса иде, «Холыкларыгызны гүзәлләштерегез» диеп әмер шәриф килмәс иде. Янә хайваннарның табигатьләрендә кылынган тәҗрибәләрдә холыкның төзәтелү мөмкинлеге күрсәтелмәктәдер. «Холык җанның астындадыр, җан чыкмыйча, холык чыкмас» дигән мәкальдә бер төпле фәнни кыйммәт юктыр. Холыкларның кешесенә, урынына, табигатькә күрә тәрбия аркасында төзәтелә алуы билгеледер.

Дөнья вә ахирәт бәхетле булуның нигезе – күркәм холыктыр. Күркәм холыкларга якын булмаган мәгърифәтләр дә мактаулы түгелдер. Адәмлек күркәм холыкларга җирандыр[121], аның берлә игездер.

Начар холыклы булганнар һәр никадәр матур да булсыннар, чын карамакта ямьсезләрдер. Мондый кешеләрдән һәркем нәфрәтләнер. Хәтта начар холыклы адәмнәр бу холыклары сәбәпле үзләрен һәрбер вакытта борчулый вә вөҗданын газап берлә һәр сулуда тынычсызлардыр.

Бер кавем, халкы күркәм холыклыдыр, бөтен мактаулы гүзәл эшләрне җыйган, бөтен бәхетлелекләргә хуҗа булганга саналыр, яхшы холыклы булганнарның гомерләре татлы үтәр. Тынычлык, рәхәтлек күркәм холык ияләренә махсус кебидер.

[119] Мәаль – аңлашылган мәгънә.
[120] Хәким – акыл иясе, галим.
[121] Җиран – күрше.

## *13 нче дәрес*
## *Тәрбиянең тәгърифе[122], кирәклеге вә кыйсемнәре[123]*

Гыйлем – әхлакның җаны, нигезе – тәрбиядер. Тәрбия «рбу» кәлимәсеннән[124] иштикакъ кылынган[125] булып, лөгать[126] мәгънәсе «үстермәк вә зурайтмактыр». Гавәм[127] телендә бертөрле нәзакәтле рәвешкә әйтерләр. Тәрбияле бер хатын дип әйтү берлә, аның ничек булганын хәзер белер вә аңларбыз. Ләкин хәкимнәр каршында тәрбиянең чын мәгънәсе бу түгелдер.

«Тәрбия» адәмдә үзе булдыра алырлык кадәрле кәмаләтне[128] хасил итмәктер. Бер баланы дөнья вә ахирәт өчен лязем булган вазыйфаларын тиешенчә үти алырлык хәлгә куймактыр. Тәрбиянең чиге тәнгә вә җанга мөмкин булган кадәрле камиллек бирмәктер. Шул сүзләрдән аңланыр ки, адәмнәрне адәм иткән нәрсә, аларны камилләндергән, бәхетле иткән – бар да яхшы тәрбиядер.

Бер агач яшь вакытта бөгелгән кеби, адәмнәр дә иң артык яшьлек заманнарында тәрбия алырга көчләре җитәр. Тәрбиянең, хосусан фикер тәрбиясенең, билгеле, әсәр кылуы бик куәтледер.

Тәрбиянең әүвәл алына торган урыны йортта, гаилә эчендә, тагы да киңрәк чишмәсе – мәктәпләрдер. Хәтта тәрбия иң артык ата-анага тиешледер.

Тәрбиянең яхшы булуы мөгаллим вә тәрбия кылучыларның камил булуларына, бу да аларның кирәк кадәрле тәрбия күргән булуларына баглангандыр. Шуның өчен дә ир вә кыз балаларыбызның күркәм тәрбия күрүләренә никадәр тырышсак, шул кадәрле кыйммәте вә кирәклеге бардыр. Хатынлык бик зур бер нәрсәдер. Балалар тәрбия кылу, бигрәк тә әүвәлге тәрбия, хатыннарга тапшырылгандыр. Шулай булгач, хатыннар таифәсенең

[122] Тәгъриф – таныштыру, белдерү, аңлату.
[123] Кыйсем – өлеш.
[124] Кәлимә – сүз.
[125] Иштикакъ кылыну – сүз ясалу.
[126] Лөгать – сүз.
[127] Гавәм – халык, масса.
[128] Кәмаләт – камиллек.

яхшы тәрбия кылулары киләчәктә бик зур сәгадәтләр тудырачактыр.

## *14 нче дәрес*
## *Тәрбия өч кыйсемгә аерылыр*

1 – тән тәрбиясе;
2 – фикер тәрбиясе;
3 – калеб, дин яки әхлак тәрбиясе.

Тән тәрбиясе – тәнгә генә махсус булып, тәннең сәламәтлеге, гәүдәнең куәтле булуының сәбәпләренә керешмәктер. Тәндә сәламәтлек булмаса, һичбер эш күреп булмас. Гәүдә авыру булса, тырышу, гайрәт, гыйбадәт вә рәхәтлек табылмас. Авыру булган гәүдәдә сәламәт вә тугры фикер дә булмас. Шуның өчен дөньяда иң олуг нигъмәт – сихәттер. Халкы куәтле тәнле, тырыш булган кавемнәрнең игендә, сатуда, гаскәрлектә, һөнәрдә, эштә мөкәммәл булачагын сөйләргә дә хаҗәт юктыр. Тән тәрбиясе булмаса, башка тәрбияләр дә хасил булмас. Алай булса, тән тәрбиясен ни рәвешле эшләрбез? Махсус урында моны да күрәчәкбез. Хифзыссыйхәт[129] кыйсеменә каралсын.

Фикер тәрбиясе. Фикернең гыйлем вә мәгърифәт нурлары берлә нурлануы өчен булган тәрбияи фикрия дә бик кирәкледер. Гыйлем вә мәгърифәт үгрәнмәк адәмнәр өчен бик ляземдер. Чөнки адәм адәмлеген, Аллаһны, динне, пәйгамбәрне вә инсаният вазыйфаларын мәгариф аркасында белер вә игътибар кылыр. Наданлык керләре берлә тутыккан гәүдәләрнең дүрт аяклы хайваннан аермалары юктыр. Бер галим берлә наданның кадер вә кыйммәтләре бер түгелдер. Бөтен дөнья вә ахирәт сәгадәтләренә ирешергә сәбәп булган нәрсә – гыйлем вә һөнәр өйрәнмәктер. Халкы гыйлем вә мәгърифәт берлә зиннәтләнеп, башкалардан аерым булган кавемнәр һәрвакыт алга китәрләр. Балаларыбызның яхшы укуларына, икенче тәгъбир[130] берлә әйтсәк, лаек кадәр тәр-

[129] Хифзыссыйхәт – гигиена, сәламәтлекне саклау һәм аның юллары.
[130] Тәгъбир – аңлату.

бия, фикрия кәсеп итүләренә чиксез тырышмагыбыз ляземдер. Бу да аларны укытмак, мәктәпкә җибәрмәк, дәрәҗәләренә күрә гыйлем вә гыйрфан[131] вә һөнәр иясе булуларына чын күңелдән тырышмак берлә генә буладыр.

## *15 нче дәрес*
## *Дин вә әхлак тәрбиясе*

Дин вә әхлак тәрбиясе. Дөньяда адәмнәрне иң артык бәхетле иткән нәрсә – диндер. Динсез адәм җансыз хайван кебидер. Динсезләрне яман гадәтләр, әхлак бозыклыгы, батыйль[132] игътикад[133] кеби тәмам һәлак кыла торган мәгънәви авырулар кимереп бетерер. Коллык вә адәмлек вазыйфаларын мәхлукларның[134] хөрмәтлесе булган адәмнәргә күрсәткән, хаклык вә тугрылыкны белдергән, аларны азгынлык чокырына төшүдән тыйган, хокукларын саклаган, мәдәнияткә ирештергән нәрсә – бары чын тугры булган диндер.

Дөньяда иң тугры дин – дин мөббәййин[135] ислам, вә иң зур вә чын хакыйкать булган китап – Коръән газыймдыр.

Сөекле пәйгамбәребез бөтен галәмнең яратылуына сәбәп булган фәхре кяйнәт[136] әфәндебез хәзрәтләре аркылы Җәнаб Хакның безгә җибәрдеге исламиятнең, аның хикмәтләрен күрсәткән шәригатьнең хөкемнәре кыяматкә кадәр бакый вә адәмнәрне һәр ике дөньяда бәхетле итәргә тәмам җитәрлектер.

Динсезләрнең бәгъзе бер начар гадәтләренә карап, аларның тышкы яктылыклар вә батыйль булган нәрсәләренә алданып, диянәт[137] Мөхәммәдиянең, ягъни мөселманлыкның хилафи[138]

---

[131] Гыйрфан – аң, белем, тәрбия.
[132] Батыйль – бозык, дөрес түгел, чын түгел.
[133] Игътикад – чын күңелдән ышану, инану.
[134] Мәхлук – җан иясе.
[135] Мөббәййин – бик ачык аңлатучы, белдерүче, бәян итүче.
[136] Фәхре кяйнәт – җиһанның горурлыгы мәгънәсендә.
[137] Диянәт – динилек.
[138] Хилаф – киресе, каршы.

эшләргә иярмәк, ятлар иярчене булмак бик зур гөнаһ, бик зур гакылсызлыктыр. Шәригать карамаклыгында яхшы булган нәрсәләргә ышанып, шуңа сарылмак ляземдер. Хак Тәгалә хәзрәтләренең боерган нәрсәләрен үтәмәк, Җәнаб пәйгамбәрнең сөннәт шәрифәсенә иярмәк берлә дин хөкемнәрен җиренә җиткермәк, аларның төбен, нигезен, кагыйдәләрен үгрәнмәк, Җәнаб Хакның тыйган нәрсәләреннән сакланмак берлә күркәм вә изге эшләрне кылмак тугрыларында булган тәрбияи диниянең никадәр кирәкле булдыгын югарыдагы сүзләрдән аңламак мөмкиндер.

## *16 нчы дәрес*
## *Намаз вә руза*[139]

Тәһарәтнең, намазның бер кыска вә җиңел генә булган дин эшенең үтәлүендә генә дә безнең өчен чиксез, сансыз файдалар барлыгына, бу дин эшләренең матди вә мәгънәви хәлләребезне зиннәтләвенә чын күңелебездән ышанырга тиештер. Намаз, руза, көче җиткәннәргә хаж вә зәкят[140] фарыз булып, һәрбер мөэмингә гүзәл холыклар берлә холыкланып, Аллаһы Тәгалә хәзрәтләренә каршы бурыч булган коллык вә тагать[141] гыйбадәтне үтәмәк тиешледер. Намазның, рузаның, Аллаһы Тәгалә тыйган нәрсәләрдән тыелуның, күңел сафлыгының безнең сихәтебез, бәхетлелегебез өчен никадәр гүзәл тәэсире барлыгын сөйләргә дә хаҗәт юктыр.

Ислам диненең хөкемнәрен тәмам ригая кылган[142] диндар адәмнәрдә, Коръән кәрим укылган йортларда бәрәкәт, бәхетлелек әллә ничә өлеш артык булыр. Аллаһка гыйбадәт кылмакның риясыз[143] булмагы ляземдер. Изге эшне бер максут өчен эшләми,

---

[139] Руза – ураза.

[140] Зәкят – ислам дине буенча хәлле кешеләр тарафыннан еллык керемнәренең кырыктан бере күләмендә түләнергә тиешле акча, мал.

[141] Тагать – дини, Аллаһка гыйбадәт кылу, буйсыну.

[142] Ригая кылу – кайгырту, олылау, хөрмәтләү.

[143] Рия – бер эшне кешегә күрсәтү өчен генә эшләү; икейөзлелек.

фәкать чын күңелдән Аллаһы Тәгаләнең ризасын эстәп[144] эшләмәк ляземдер. Һәмширәләр, чын мәдәниятнең башланган җире дә, нигезе дә, торган урыны да диндер. Шуның өчен дә дини тәрбия бик кирәк булып, тәрбиянең һәрбер тәгърифендә[145] бераз диянәт исе бардыр.

Балаларыбызны сау игътикадлы[146], изге гамәлләргә һәвәсле итеп тәрбия кылмак дин тотучы вә тәкъва[147] юлыдыр.

## *17 нче дәрес*
## *Кыз вә хатыннарның ата-анага, якын карендәшләргә вә дусларга каршы вазыйфалары вә гомуми эшләре*

Гәүдәбезнең хасил булуына сәбәп булган ата-аналарыбызны никадәр артык сөймәк вә аларны никадәр күп кадер вә хөрмәт кылмак лязем булачагын һәрбер вөҗданлы адәмнең белүе шөбһәсездер.

Бер ана баласын дөньяга китерер, тереклегенең куәтеннән бер кисәк булган сөте берлә аны туйдырыр, кочагында үстерер, сөекле йөрәк җимешенең рәхәте өчен татлы йокыларын, бөтен рәхәтлеген куяр. Аның тәрбиясе вә бәхетле булуы өчен җан вә йөрәгеннән тырышыр. Аның өчен чикмәгән җәфасы, итмәгән фидакарьлеге калмас. Тереклегенең соң сулуына кадәр аны сөяр. Баласының бераз башы авыртса, аның сәламәтлеген кайтарыр өчен бер тоташтан чапаланыр. Аңа һәр заманда «җаным» диеп дәшәр. Моның бу сүзе бик тугрыдыр. Чөнки балалар ананың тәннән, җаннан бер кисәктерләр. «Җәннәт аналарның аяк астындадыр» хәдис шәрифе аналарның никадәр артык хөрмәт вә мәхәббәткә лаек икәнен күрсәтер өчен җитәрлектер.

Ана кадерен кирәгенчә белер өчен ана булмак ляземдер. Ханым-кызлар, аналарыгызны сөегез, аларга хөрмәт, хезмәт кылыгыз ки, алдагы көндә үзегез ана булган заманыгызда

[144] Эстәү – теләү.
[145] Тәгъриф – аңлату, белдерү.
[146] Игътикад – чын күңелдән.
[147] Тәкъва – дин кушканны гына эшләү, диндар булу.

балаларыгыздан кадер-хөрмәт күрерсез. Аналары балаларының башында мактаулы таждыр, аларның хәер-догалары балаларның бәхетле булуына сәбәп булыр. Аллаһның хикмәте берлә тәне-безнең әүвәлге тамчысын мәйданга китергән атадыр. Ялгыз бу кадәр генәме? Юк, ул гына түгел. Анабызның безгә имезгән сөтен хасил иткән азыкка кадәр, вә камил адәм булып җиткәнче ашаган, эчкән вә кигән нәрсәләребез бар да аталарыбызның тырышуы вә мәгыйшәт[148] эшләрендә һиммәтләре[149] аркасында бар булгандыр. Безне аталар тәрбияли, үстерә, һәртөрле хаҗәт нәрсәләребезне хәзерли, безнең өчен эшли, арый-тирли, үстереп мәктәпкә бирә, безнең рәхәт вә сәгадәтебез өчен җаны-тәне берлә тырыша. Болай булганда, аталарыбыз да хөрмәт, хезмәт кылынырга лаек, ита-гать[150] вә ригаять кылынырга[151] тиешледер.

### *18 нче дәрес*
### *Янә ата-ана*

Инде дөньяга килгән бер баланың никадәр зәхмәт вә мәшәкатьләр берлә, ни дәрәҗәләрдә фидакарьлекләр берлә үсеп адәм булганы уйланса, ата вә ананың матди вә мәгънәви кыйм-мәтләре хисапка алынса, ата вә ананың һич үтәп бетерү мөмкин булмаган хаклары, аларга каршы хөрмәт вә мәхәббәт күрсәтүнең тиешлеге хәзер кабул кылыныр.

Җәнаб Хак ата вә аналарына вә карендәшләренә итагатьле вә мәхәббәтле булганнарны сөяр. Ата-ананы олуглап буйсынмак, хөрмәт вә хезмәт итмәккә дин вә инсаният йөзеннән мәҗбүр-ләрбез. Вөҗданлы, тугрылыклы балалар һәр заман ата-анасын сөймәк, аларга һәрвакыт ригаять итмәк[152], һичбер вакытта рән-

[148] Мәгыйшәт – тереклек итү, көнкүреш, тормыш.
[149] Һиммәт – тырышлык.
[150] Итагать кылу – күндәм булу, сүз тыңлау.
[151] Ригаять кылу – кайгырту, карау, хөрмәтләү.
[152] Ригаять итү – кайгырту, аңлау.

җитергә ярамаганлык вазыйфалары берлә мөкалләф[153] булганнарын бик ачык белерләр.

Бу мәхәббәт вә хөрмәтнең дәрәҗәләре һичбер вакыт ата-ананың һөнәрләренә яки табигатьләренә карап артык вә ким булмас. Ата-ана, кирәк бер түбән дәрәҗәле, яисә начар холыклы булса да, камил ихлас берлә сөймәк, олугламак, буйсынмак ляземдер. Мәсәлән, күмерчелек берлә мәшһүр булган бер атаны яки чая вә холыксыз булган бер ананы начар һөнәр иясе яки холыксыз диеп сөймәгәнлек, тиешле булган хөрмәтне кылмаганлык тәрбиягә, әдәп вә инсафка хилафтыр[154].

Алар, никадәр түбән дәрәҗәдә булсалар да, янә ата-аналардыр. Намуска хилаф булмаган, тереклек өчен файдасы булган һөнәр вә эшләр һичбер вакытта гаепләнә торган эшләрдән саналмас. Тугрысы язучылык, кибетчелек, гаскәрлек ничек кирәк булса, икмәкчелек, күмерчелек, мал ташучылык та халык өчен шулай ук кирәкледер. Атагыз урам төзәтүче дә булсын, анагыз су ташучы да булсын, вә һәркөн сезне холыксызлык, вак сүзлелек берлә газап та кылсын, янә аларга хөрмәт вә ригаять берлә кулларын үбәргә бурычлысыз. Алар яшьли сырхау вә фәкыйрь булсалар, актык сулуларына кадәр бакмак, мал вә тән берлә ярдәмдә булмак бурычыгыздыр. Ата-ананың йөзенә ачуланып карамак, алар янында каты вә зур тавыш берлә сүз сөйләмәк, Аллаһ сакласын, алардан көлмәк, мыскыл итмәк, үчекләмәк, тәрбиягә артык хилаф вә Аллаһ каршында ачуга сәбәп булган эшләрдәндер. Аларның сүзләренә карышмак аслан[155] җаиз[156] түгелдер. Һичбер вөҗданлы ата яки ана баласын шәригать вә гадәткә хилаф булган бер начар эшне эшләргә кушмас. Мөхальне[157] фарыз кылу кабиленнән буларак кушса да, моңар итагать кылмау[158] зарурәттер[159].

[153] Мөкалләф – өстенә йөкләнгән; җаваплы.
[154] Хилаф – киресе, каршы.
[155] Аслан – һич, һичбер вакытта, беркайчан да.
[156] Җаиз – дөрес, яраклы.
[157] Мөхаль – булмый торган, мөмкин булмаган.
[158] Итагать кылу – күндәм булу, сүз тыңлау.
[159] Зарурәт – үтә кирәклелек, мохтаҗлык.

## *19 нчы дәрес*
## *Карендәшләргә ничек булырга кирәк*

Карендәш ыругларга килсәк, ничек ата-анагызны сөяргә вә хөрмәт итәргә тиеш булса, аларның якыннары булган кардәш кабиләләре дә хөрмәт вә мәхәббәт, хезмәт вә итагатькә лаек булачаклары билгеледер. Болар арасында олуг булганнарының кулларын үпмәк, хәлләрен белергә вә күрешергә бармак, авыру булсалар, кулдан килгән кадәр карамак, хезмәтләрендә булмак, аларны юатмак, күңелләрен табарга тырышмак, мохтаҗ булсалар, ярдәм итмәк, ничек кенә булса да аларга яхшылык кылмак, карендәшлекне күрсәтмәк ляземдер. Кечкенәләрен дә сөймәк, аларга шәфкать вә мәхәббәт күрсәтеп, домшанлыкка сәбәп булырлык вә хәтер калдырырлык эшләрдән сакланмак вазыйфасы берлә бурычлы булганыгызны онытмагыз. Карендәш вә якыннарыгыз сезгә ят булып тоелсалар да, сезне хурласалар вә орышсалар да, сез янә аларны сөегез, аларны хөрмәтләгез. […] Начар эшкә начарлык берлә каршы тору начарлыктан башка бер нәрсә дә чыгармас. Бер күңелне сындырмак бик ансаттыр. Ләкин төзәтүе бик кыендыр. Һөнәр: шелтәгә тиеш булган күңелләрне сындырмый, яхшылык берлә әсәрләндереп, күркәм хисләргә өндәмәктер.

## *20 нче дәрес*
## *Якыннар*

Абзаларыгыз, туталарыгыз, килен вә җиңгәләрегез, ир кардәшләрегез, кыз кардәшләрегез, туганнарыгызның балалары, ирегез, кайната вә аналарыгыз, кайнага вә энеләрегез, килендәшләрегез, кайнигәч вә каен сеңелләрегез, хасил үзегезнең бөтен якыннарыгыз вә кардәшләрегез, ирегезнең якыннары күзләрегездә сөекле вә хөрмәтле булырга кирәк. Аларга салкын чырайлар, кызган фигыльләр күрсәтми, һәрвакыт махсус ригая[160] вә

[160] Ригая – кайгырту, аңлау.

ыспайлыклар берлә эш кылмак, йомшак вә ягымлылык берлә сөйләшмәк, аларны аслан[161] рәнҗетмәслек ляземдер.

Бу саналганнардан кайсы гына булса да булсын, хаҗәте булганнарына көчегез җиткән кадәр ярдәм кылмак, көчегез җитмәсә, тел берлә булса да аларны юатмак, мал берлә ярдәм итә алмасагыз, гәүдә берлә эшли алырлык эшләрен эшләп, күңелләрен табарга тырышмак бурычларыгыз җөмләсеннәндер.

Әби вә бабагыз булса, бу да сезнең өчен үз алдына бер зур бәхетлелектер. Болар картайганлыклары сәбәпле сезне борчысалар да, сабыр вә түземлек берлә вак сүзләренә түзеп, һәрвакыт рәхимлелек, йомшаклык берлә хөрмәт вә хезмәт итегез. Яшьли адәмнәр сүзне аз ишеткән өчен, күп сораучан булалар. Бу хәлләренә ачуланмый, сораган сүзләренә ягымлылык берлә тәрбия даирәсендә җавап бирмәгә, аңламаган сүзләрен яхшылап аңлатып, хәер догаларын алмага тырышыгыз. Бергә йөргәндә зурларның бераз артыннан йөрмәк, бер җиргә утырылганда алардан түбәнрәк урында утырмак, алар килеп кергәндә аякка басып, хуш күреп кабул итү әсәре күрсәтмәк, табында олуглардан әүвәл ашарга башламассызлык, хасил һәрбер эштә көләч йөз берлә олугларның хезмәтчесе, кечкенәләрнең дә шулай ук бер шәфкатьле юлдашы булмак инсаниятькә лязем.

## *21 нче дәрес*
## *Дусларга ничек булырга кирәк*

Ханым, кызлар! Сезнең дә үзегезгә күрә иптәшләрегез вә дусларыгыз бардыр. Дусларыгызны күркәм холык вә күркәм эш ияләреннән сайлагыз. Чөнки юньсез иптәштән адәмгә юньсезлек килер. Яхшылар берлә бергә булмак – изгелекләрне тартучыдыр. Адәмнең үлчәве билгесе – йөрешә торган кешеләредер.

Дусларыгызга каршы кылыначак эшләр һәр заман тәрбия вә нәзакәт даирәсендә булырга тиеш. Эшне бөтенләй пәрвайсыз-

[161] Аслан – һич, һичбер вакыт.

лыкка[162] әйләндерергә ярамас. Фәкать салкынлык берлә дә булмый, уртачалык вә ыспайлык берлә генә муафикъ сүзләр сөйләү берлә утырышмак, аларның ачуларын китерә вә кәефләрен җибәрә торган урынсыз уен-көлкеләр дә булмассызлык, аларны рәнҗетмәссезлек тиештер.

Аларны башкаларга хурламаслык яисә алар берлә бергәләшеп башкаларны гаепләп вә хурлап сөйләшмәслек, аларның күңелегезгә охшамаган бәгъзе кимчелекләрен йөзләренә ормассызлык ляземдер. Ара-тирә дусларыгыз берлә күрешә бармак, аларны һәрвакыт яхшы эшләргә кызыктырмак, ярдәмгә мохтаҗ булганнарының ярдәменә җитешмәк, халык арасында төрле начар сүзләргә сәбәп булырлык эшләрдән сакланмак, оятсыз вә әдәпсез кызлар берлә катнашмаслык инсаниятькә лязем булган гадәтләрдәндер.

Дусларыгызның шатлыгына шатланмак, кайгы вә хәсрәтләре булганда кайгыларын уртаклашмак, һәрвакыт аларга яхшы нияттә булмак ляземдер. «Үзегезгә эшләнүне эстәмәгән[163] нәрсәне башкаларга да эшләмәгез» дигән сүз бу тугрыда сезгә кыска, ләкин төпле нигезле бер юл күрсәтә алыр.

Дусларыгызга каршы ачу, үпкә, көнчелек кеби начар хәлләргә керешә күрмәгез. Хәтта һичбер кешегә дә мондый эшләр вә тәкәбберлек әсәрләре күрсәтмәгез. Аның өчен барыбыз да адәмнәр без, адәмнәр һәрбере бер нәселдән килмештер. Һәркем берберсенә адәмлекнең, инсаниятнең лязем иттергән даирәсендә күркәм эшләр берлә инсаният кадерен сакларга тырышмак ляземдер.

[162] Пәрвайсызлык – тәрбиясезлек, җавапсызлык.
[163] Эстәү – теләү.

## *22 нче дәрес*
## *Сәламәтлек вә гаилә сихәтен саклау хосусында кыска гына мәгълүмат*

Дөньяда адәм өчен иң зур нигъмәт – сәламәтлек вә вөждан рәхәтлегедер. Тәннең сихәте – тәннең һәрбер әгъзаларын вакыт вә заманында хәрәкәтләндереп, һәрбер эшне һәрвакытта бертигез эшләтеп, хасил тәннең терек вә сәламәт булуы димәктер.

Авыру гәүдәдән файдаланмак мөмкин түгелдер. Чөнки тәннең сәламәтлеге бозылса, һәр эш кимчелеккә йөз тотар. Хәлсез вә авырулы тәннәр дөнья вә ахирәт өчен лязем булган эшләрен дә бик читенлек берлә үтәрләр.

Авыру адәмнәрнең фикерләре дә сәламәт булмас. Әлхасыйль[164], тугры вә сәламәт фикергә, яхшы хезмәткә вә бөтенләй бәхетлелеккә ирешер өчен, тәннең сау вә куәтле булуы, авырулардан сәламәт булуы шарттыр ки, бу да тәнне яхшы карамак, ягъни хифзыссыйхәтнең[165] хөкемнәренә ригая кылмак[166] берлә булыр.

Хифзыссыйхәт – сихәт вә сәламәтлекне сакларга ярдәм бирә торган сәбәпләрдән бәхәс иткән бер гали вә киң гыйлемдер. Табиб бер авыруны килгәннән соң дәва кылу берлә шөгыльләнә; ләкин хифзыссыйхәт авыруларны рәнҗү килмәстән әүвәл китермәскә хезмәт итә.

Дөньяда үлем һәркем өчен килүе билгеле булган бер эш булып, әҗәл дә бердер. Хәтта кеше үтергән кеше дә әҗәле берлә үләдер. «Әҗәл каза» дигән сүз бер казага очрап үлмәк, «әҗәл мөсәмми»[167] Аллаһ тарафыннан билгеләнгән әҗәл җитеп үлмәк дигән сүз булып, үлемнең сәбәпләренә күрә билгеләнгән бер исемдер. Казага очраган адәм дә кайвакытта үләр, кайвакытта үлмәс. Табибларга караттырылган авырулар да шуның кебидер. Табиблар яхшы булачак бер авыруны яхшыландыра алырлар.

---

[164] Әлхасыйль – җыеп әйткәндә.
[165] Хифзыссыйхәт – гигиена, сәламәтлекне саклау һәм аның юллары.
[166] Ригая кылу – кайгырту, аңлау.
[167] Мөсәмми – аталган, исемләнгән.

Шуның өчен бер адәм берәр каза ирешеп үлсә, аның Аллаһ каршында шул казадан үләсе билгеләнгән булып, әҗәле шул сәбәптәндер. Алай да булса, хасталанган бер адәмне тәвәккәл итәм[168] диеп табибка күрсәтмәгәнлек һич җаиз[169] түгелдер. Гәрчә әҗәл билгеле булса да, вакыт ирешкәнгә кадәр авыруны газапландырып асрамас өчен, дару берлә булса да, бераз рәхәтләндерүнең сәбәбенә керешмәк ляземдер. Бердән, әҗәле җитеп җитмәгәне билгеле бер эш булмаганнан, дару иттерергә ашыгу бигрәк ляземдер. Хәтәрдән саклану мәшругъ[170] эштер.

Чахотка, тамыр чире, ваба[171], сифилис вә башка йогышлы вә куркынычлы авырулардан сакланырга тырышмак инсаният вазыйфаларыбыздан булып, шул Аллаһның нигъмәте булган җан вә тәннәребезне авыру вә зыяннардан сакларга тырышу да шулай ук бурычыбыздыр. Хасил, һәркем сырхау булмаска тырышмак, сырхауга эләккәннәр дә тизрәк бер оста табибка күренмәк ляземдер. Тәвәккәл сәбәпләренә керешмәк берлә Аллаһы Тәгаләгә тапшырмактыр. Юкса коры «Иншә Аллаһ» дип кенә сәбәпләренә керешмәсә, бу эш Җәнаб Хакның да ризасына хилафтыр[172].

## *23 нче дәрес*
## *Ашамак, эчмәк, йокламак вә башкалар*

Адәм ашауда, эчүдә, йоклауда вә һәрбер эшендә вә тәненең хәрәкәтләрендә ифрат[173] вә тәфрыйтьтан[174] сакланмак тиештер. Чөнки бу ике афәт, ягъни ифрат берлә тәфрыйть тәннең сәламәтлеген җибәрер. Ахырында һәлак итәр. Ифрат берлә тәфрыйть диндә дә гаеп вә харамдыр. «Ифрат» артык, «тәфрыйть» кирәк кадәрледән ким, димәктер.

---

[168] Тәвәккәл итү – тапшыру.
[169] Җаиз – дөрес, ярый торган, яраклы.
[170] Мәшругъ – шәригать кушкан, шәригать каршында дөрес булган эш.
[171] Ваба – чума.
[172] Хилаф – киресе, каршы.
[173] Ифрат – чамадан тыш, арттырып.
[174] Тәфрыйть – чиктән тыш түбәнәйтү, киметү.

Тыйбның[175], хифзыссыйхәтнең[176] дә нигезе, табиблар әйткәнчә, уртачалыктан гыйбарәттер. Адәмнәр һәрбер эшләрендә уртачалыкны вә тәртипне сакласалар, сәламәтлекләрен дәвам иттерер өчен иң кирәкле ике төп юл башлаучыны кулга төшергән булырлар.

Тәннең сихәт вә сәламәтлеген сакларга сәбәп булган нәрсәләрнең иң башлычалары – ашамлыклар, эчемлекләр, һава, якты, җылы, йокы, тәннең хәрәкәтләрендә уртача вә тәртиплелеккә ригая кылмак[177], ягъни хифзыссыйхәт кагыйдәләре буенча эш кылмактыр. Шуның өчен сәламәтлекне саклый торган нәрсәләрне кыскартып бәян итик:

1. Куәт бирә торган ашлардан лязем булганнарын билгеле вакытларда гадәтчә ашамак.

2. Кирәк вакытта саф вә тонык су эчмәк.

3. Саф һава алу берлә бергә, яктылык вә эсселектән дә мәхрүм булмаслык.

4. Яшькә вә табигатькә күрә кирәк кадәрле рәхәт йокы йокламак.

5. Тора торган мәмләкәт вә вакытына күрә кием кимәк.

6. Тәнне һәртөрле һава сугулардан сакламак.

7. Пакьлек берлә бергә, һәрбер эшләр вә тән хәрәкәтләрен билгеле вакытларында тәртип берлә эшләмәк.

8. Тәнне һәрвакыт ялкаулыкка, тик торырга бирми, истирахәткә[178] махсус булмаган вакытларда, тәнне хәрәкәтләндермәк вә эш эшләмәк.

9. Тирән уйлардан вә начар гадәтләрдән, батыйль[179] фикерләргә сарылудан вә боларга ышану вә игътикад кылудан[180] сакланмак.

---

[175] Тыйб – медицина.
[176] Хифзыссыйхәт – гигиена, сәламәтлекне саклау һәм аның юллары.
[177] Ригая кылу – кайгырту, олылау, хөрмәтләү.
[178] Истирахәт – ял, ял итү.
[179] Батыйль – бозык, дөрес түгел, буш, файдасыз.
[180] Игътикад кылу – ышану, инану.

Мәсәлән, надан карчыклар сүзенә ышанып, өйдә яки тышка чыкканда, пәри-җен бар, күзгә әлләниләр күренер дип, үз-үзеңне куркытудан, күз алдына әллә нинди хыяллар китерүдән, «фәлән үлек кабереннән чыгып йөри имеш» дигән батыйль сүзләргә ышанып куркынудан гаять сакланмак ляземдер.

## *24 нче дәрес*
## *Ризык*

Дөньяда торыр өчен ашамак шарттыр. Адәмнең тәне һич туктамый бер тоташтан эштә вә хәрәкәттәдер. Тереклек туктаусыз эшләргә мохтаҗдыр. Тәннең эшләве исә тәндә җыелган нәрсәләрне сарыф кылу берләдер. Чөнки тән үзенең машинасында яндырырлык, сарыф кылырлык нәрсәләр тапмаса, ахырында югалыр, һәлак булыр. Лампада май булмаса, пилтәсе[181] янып беткән кеби, ашлыклы ашлар ашалмаса, тән дә коры калып һәлак булыр. Адәмнең тәне бер туктамый эшләп торганга күрә, көн дә бик күп нәрсә заегъ[182] итәр. Бу заегъ булганнарны тутырыр өчен, ашлыклы ашларга бик каты мохтаҗлык бардыр. Болай булса, дөньяда торыр өчен иң әүвәл ашауга ихтыяҗ бар димәктер.

Тереклек матди вә мәгънәви ике куәтнең тәэсире астында йөрергә, матди тереклек куәтенең төбе каннан вә мәгънәви тереклек куәте дә күзгә күренми торган Аллаһ тарафыннан җибәрелгән җан дигән бер нәрсәдәндер, вә тәннең эчтәге вә тыштагы һәрбер әгъзалары канның тәэсире вә йөрүе берлә «кызыл вә кара кан тамырлары аркылы», ягъни кан тамырының башы булган йөрәкнең хәрәкәтләнүе берлә генә эшләрен эшләргә көчләре җиткәнлектән, тереклек өчен тәндә кан булуга мохтаҗлык билгеле вә тәннең тазалыгы өчен дә бу канның булуы ляземдер. Канның куәтле булуы, эчендәге кызыл йомрыларның ак йомрылардан артык булуы димәктер.

---

[181] Пилтә – филтә, ягулык матдәсе сеңдерелеп, ут кабызып яктырту өчен кулланыла торган киндер тасма (лампада, керосинкада), фитиль.

[182] Заегъ – әрәм, файдасыз.

Иң әүвәл кан булдыра торган нәрсә дә азыктыр. Шуның өчен ашый торган ашлар никадәр куәтле булса, билгеле, аннан хасил булган кан да шулкадәр куәтле булыр. Төрле авыруларга каршы тәнне куәтле итәр, вә тән куәте берлә гәүдәнең тазалыгын арттырыр өчен яхшы вә муафикъ ашлар ашамак ляземдер. Кансызлык тәннең төрле авыруларга тотылуына сәбәп булган кеби, бик артык күп булса да, әҗәлгә сәбәп булыр. Канның кирәк кадәрледән артык булуы да зарардыр.

## *25 нче дәрес*
## *Ашлар*

Ашлыклы вә куәтле хәлләр йомырка, сөт, ит, куй, сарык вә сыер итләре, кош итләре, сыр вә икмәктән башлап, бәрәңге, фасулия[183], икра, тавык итләре вә моңар охшаган нәрсәләрдер. Азотлы булсалар да, тән өчен майлы вә шикәрле нәрсәләр дә ляземдер. Канны куәтләндерер өчен ит үзе генә ашалса, артыкка кителгән булып, башка кан менү вә һәлак итә торган чуаннар чыгу кеби авырулар хасил булыр. Тәндәге итләр вә сөякләр фосфорлы нәрсәләргә дә мохтаҗ булганлыкларыннан, тереклекне саклар өчен ит берлә бергә җиңел вә яхшы нәрсәләр дә – кәбестә, кыяр, салат кебиләрне ашамак та ляземдер. Хәзерге табиблар итнең ашлыклы булуы берлә бергә, тәнгә бирә торган зарарларын да санап, ит урынына үләннәр, яшел нәрсәләр вә моңар охшаган ашлар ашауны бик каты тәүсыя кылалар[184]. Итнең ашлыклы булу җәһәтеннән иң артык файдасы шурпасында, һәм дә чапкан иттән пешерелгән котлетта яки төелгән вә кыздырылган итнең яхшы чәйнәп ашалуындадыр. Суда пешерелгән вә кыздырылган итләрнең һазыйме[185] авырдыр. Тавык, балык итләре боларга караганда җиңелдер.

[183] Фасулия – фасоль.
[184] Тәүсыя кылу – киңәш бирү.
[185] Һазыйм – аш сеңдерү.

Сөт вә йомырка берлә сырның яңа вә тәза[186] булу шарты берлә тәнгә куәт бирүдәге хезмәте билгеле булып, сөтнең бераз кайнаган, йомырканың чиле-пешле булуы, сырның да икмәк берлә ашалуы муафикъτыр. Бер йомырка ун грамм (кадакның эчтән бере) сыер сөте урынына тора.

Ашказаны (мәгъдә) – тән машинасының нигезе, учагы булган өчен, моңар бер кечкенә ярамаган эш булса, бөтен тәнгә зарары тиеп, сырхау итәчәк булганнан, ашказанын һәрвакыт эшләтеп ардырмак, ягъни вакытлы-вакытсыз һаман ашап, аш сеңдерә торган әгъзаларыбызның җаны урынында булган шул кечкенә капчыкны борчымак һичбер җаиз[187] түгелдер.

Мәгъдә вә аның ярдәмчеләре булган эчәгеләр нәкъ бер тегермән шикелле, төрле-төрле хәрәкәтләр берлә ашаган нәрсәләрне эретеп сеңдерәләр. Ләкин болар да вакытында ял итәргә мохтаҗлардыр. Убырлык, ягъни кирәк кадәрледән артык ашамак вә ашаган өстенә ашамак, бара-бара үлем берлә чикләнерлек кадәр куркынычлы бер эштер. Мәгъдәсе сау булган тәннәр бик таза булырлар.

## *26 нчы дәрес*
## *Симезлек*

Симезлек майдан гыйбарәт булып, күп хәтәрләргә сәбәп булганнан, бик яхшы түгелдер. Мәсьәләнең төбе тәннең таза вә көчле булуыннандыр. Симезлек сырхаудыр. Сеңдерү җиңел булсын өчен, тиз сеңә торган ашларны ашамак, кечкенә кабып, озак чәйнәмәк кирәк. Чәйнәлеп җитмәгән аш тиз сеңмәс, аш сеңмәгәнлектән булган мәгъдә авырулары бик озын, үшәндерүче[188] вә ахырында һәлак итүчедер. Күп ашау мәгъдәне киңәйткән өчен, аш сеңдерә торган куәте дә азаер. Әйтергә мөмкин ки, авыруларның күбрәге бугаздан вә мәгъдәдән килер. Шуның өчен вакытлы гына вә файдалы нәрсәләрне генә ашарга тиеш. Һәр

[186] Тәза – яңа, яңа әзерләнгән, яңа өзелгән; свежий.
[187] Җаиз – дөрес, яраклы.
[188] Үшәндерү – ялкауландыру, хәлсезләндерү.

күргән нәрсәне ашарга һәвәсләнмәктән сакланып, мәгъдәне сәламәт тотарга тырышмалыдыр.

Көндә ничә мәртәбә ашарга кирәк? Тәнгә тәүлек эчендә кирәк булган кадәрле ашны мәгъдә берьюлы эченә сыйдыра алмаган кеби, табиб карамаклыгында да билгеле вакытларда ял итәргә мохтаҗ булган өчен, ашның билгеле вакытларда берничә мәртәбә ашалуы ляземдер. Хифзыссыйхәт[189] кагыйдәсенчә, һәркем өчен ашау вакыты көндә өч булып, иртә берлә, өйлә, кичке аш вакытларына хәзерләнмештер.

Иртәге аш гаять җиңел булырга кирәк. Ягъни я бераз сөт, я бер-ике чиле-пешле яңа йомырка, яисә бераз атланмай берлә икмәк, яки һәркем каршында тәнгә күп файдасы барлыгы тасдыйкъ кылынган[190] сөт берлә бераз икмәк яки бисквит кеби нәрсәләр ашап, чәй вә кофе янында шулардан артык нәрсә кирәк түгел.

Иртә берлә майга пешкән сумса, коймак, пәрәмәч кеби нәрсәләр, ит, пылау кебиләр берлә корсакны тутырмак сәламәтлек өчен бик зарарлыдыр. Чөнки иртә берлә мәгъдәнең эчендә аш сеңдерү эшен эшләр өчен берничә сәбәп булган «гыйсарәи мәгъдәвия»[191] дип әйтелә торган сыек нәрсәсе аз булган өчен, мул вә сеңүе авыр ашларны сеңдерергә көче җитмидер.

## *27 нче дәрес*
## *Көндәге аш*

Көндәге аш. Гыйсарәи мәгъдәвиянең иң күп вакыты өйлә вакытында булган өчен, ашның иң күбе көндез ашалуы ляземдер. Бу да игенлекләрдә вә фабрикаларда эшләүчеләргә махсус булып, фикер эшләре берлә чуалганнарның тулы корсак берлә кирәгенчә эшли алулары мөмкин булмаганнан, вә көндезге аштан соң ике

---

[189] Хифзыссыйхәт – гигиена, сәламәтлекне саклау һәм аның юллары.
[190] Тасдыйкъ кылу – расланган, дөрес дип табылган.
[191] Гыйсарәи мәгъдәвия – ашказанында ашны сеңдерә торган бертөрле маегъ (сыеклык); ашказаны согы.

сәгать кадәр истирахәткә[192] ихтыяҗлары булганнан, шәһәрдә торучыларның көндезге ашлары кичке ашларыннан җиңелрәк булуы мәслихәт[193]. Көндезге аш өстенә, бераз җиләк-җимеш кеби нәрсә ашамак файдалыдыр.

Кичке аш. Йөрәк, мәгъдә, баш вә моңар охшашлы авырулары булган адәмнәр кич берлә артык ашасалар, бик рәхәтсез булачакларыннан, болар кичке ашны җиңелчәрәк вә көндезге ашны моңар караганда артыграк алырга кирәк.

Хифзыссыйхәт гыйлеменең әйтүенә караганда, ашауның йөз өлешеннән унысын иртә берлә, йөздән кырыгын көндез, йөздән иллесен кич ашамак муафикътыр.

## *Аш вакытлары*

Иртәнге ашау һәркемгә йокыдан торып хаҗәтен үтәгәннән соң, бит-кулларны сабынлап юып, тәһарәт алып, намаз укыганнан соң ашалыр. Көндезге аш вакытына күрә алышыныр. Шулай да, иртәнге чәй берлә көндезге ашның арасында биш сәгать вакыт үтәргә кирәк. Болай булганда:

Җәй иртәнге чәй – сәгать 8 дә,
Көндезге аш – 1 дә,
Кичке аш – 8 дә.

12–18 яшьләрендәге балалар вә бәгъзе төрле мәгъдә[194] авырулылар өчен көндезге аш берлә кичке аш арасында сөт, сохари берлә чәй кеби җиңел генә бер нәрсә ашамак мәслихәт. Аштан бик туеп җитмәс борын торып китмәк – ашауның билгеле чигедер. Ошбу билгеле вакытлар арасында мәгъдәгә башка бер нәрсәләр коймаска кирәк. Чөнки мәгъдә арып, ашның сеңүе авыраер. Җимешләр вә татлы нәрсәләр һәрберсе ач карынга ашалмый, аш өстенә ашалырга тиеш, җимешләрнең, карбыз, кавын кебиләрнең пешеп җиткән вә тәзаларын[195] вә сеңешлеләрен

---

[192] Истирахәт – ял, ял итү.
[193] Мәслихәт – тиеш, яраклы, киңәш ителгән.
[194] Мәгъдә – ашказаны.
[195] Тәза – яңа, яңа әзерләнгән, яңа өзелгән; свежий.

сайларга кирәк. Виноград, алма, инжир, карбыз кеби җимешләр һәм тәнгә файдалы, һәм дә башкаларга караганда сеңешледер.

## *28 нче дәрес*
## *Никадәр ашарга кирәк*

Ашауга кирәк кадәрледән аз вә бик артык ашаудан сакланмак ляземдер. Һәр ашаганда биш-алты тарелка аш ашаганнарның аш сеңдерә торган әгъзалары арып, үзләренә лязем булган эшләрен эшли алмас булырлар. […] шикәр, экзема, раматиз[196], йөрәк вә бөерәк[197] авырулары кеби авырулар күп ашаудан килүендә табиблар бар да бер сүздәләрдер.

Көндезге вә кичке ашларда шурпа вә яшел нәрсәләр – кәбестә, кыяр кеби, вә өстенә дә булса җимеш сулары яки кызыл кесәл я бераз җимеш – алма, виноград кебиләрне ашамак кирәк.

Шурпа һәр ашта шарт булмаган кеби, хәлләре алдыра алмаган адәмнәрнең бераз гына ит берлә катыш үләннәр берлә кәефләнергә муафикътыр. Хәтта кайвакытта коры икмәк берлә катык, сөт кеби нәрсәләр дә адәмне тиешенчә сәламәт саклый алыр.

Шуның өчен ашларның дәрәҗәсе җиренә, кешесенә, гәүдә вә гадәтләренә күрә төрлечә булып, адәмнең тәне үзенең яраткан ашлары берлә бәйләнә алыр.

## *29 нчы дәрес*
## *Сулар вә һәрбер эчемлекләр*

Су асылда мәвалиделхәмузә[198] вә мәвалиделмаэ[199] газлары берлә бәгъзе нәрсәләрдән кушылган бер сыек нәрсә ки, тән машинасын хәрәкәтләндермәгә ярар. Кирәк вакытта гадәтчә эчмәк шарты берлә саф су тән машинасының яхшы әйләнүенә,

[196] Раматиз – ревматизм.
[197] Бөерәк – бөер.
[198] Мәвалиделхәмузә – кислород.
[199] Мәвалиделмаэ – водород.

тереклегенә вә бөтен тәннең сәламәтлегенә беренче сәбәптер. Суның фазыйләте[200] Коръән кәримдә дә боерылмыштыр. Хәзерге заманыбызда табиблар авыруларны бары су берлә генә дә дәвалыйлар. Суның эчелүендә артык вә кименнән саклану шарты берлә су икмәктән дә кирәклерәк булып, яхшысын эчмәгә күп тырышмак ляземдер.

Адәмнең тәне урта хисап берлә көнендә өч бутылка кадәр су заегъ иткәнлектән[201], көнендә башка эчемлек вә ашлар берлә бергә моның кадәр суга ихтыяҗ бардыр. Шунысы да бар ки, эчүнең микъдары бер кешенең гадәт вә гәүдәсенә күрә төрлечә булыр.

Әгәр су кирәктән артык вә еш-еш эчелсә, сеңүе читен вә ахырында мәгъдәне[202] киңәйтеп, бу йөрәкләрне дә кирәгеннән артык эшләтеп, зарар бирер. Балчыклы су берлә кое вә күл сулары бар да зарарлы булып, әүвәл чишмә сулары, икенче дәрәҗәдә агым сулар файдалыдыр. Бер суның яхшы вә файдалы булуы саф вә үтә күренә торган, тозсыз вә яхшы һаваландырган булуыдыр. Суның аш арасында эчелүе файдалыдыр. Аштан соң азында ике сәгать үтми су эчмәскә кирәк. Чөнки аш артыннан ук эчелгән сулар мәгъдә вә эчәгенең эсселеген киметеп, аш сеңү эшен читенләндерерләр. Эче кибә торган кешегә иртә берлә ач карынга бер стакан су эчмәк бик яхшы дәвадыр. Боз эрегәннән хасил булган сулар да тәнгә зарарлыдыр. Өсте ачык, я пычрак җирләрдән килгән яисә шакшы сулар агыза торган ләгымнәргә тоташып үткән суларның тиф кеби һәлак итә торган авыруларны тудырганы билгеледер. Суның салкын булуы лязем булса да, гомумән унбиш дәрәҗәдән[203] ким вә егерме дәрәҗәдән артык булмагы җаиз[204] түгелдер.

[…] Халыкта йогышлы авырулар булган вакытта һәркемгә суларны кайнатып эчмәк яхшыдыр.

---

[200] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш.
[201] Заегъ итү – тоту, югалту.
[202] Мәгъдә – ашказаны.
[203] Дәрәҗә – монда: градус мәгнәсендә.
[204] Җаиз – дөрес, яраклы.

## *30 нчы дәрес*
## *Юыну вә эчемлекләр*

Бит, кул юганда һәрвакыт салкын су тотылып, кайвакытта җылы, вә кайвакытта суык су берлә юынмак, бит-кулны ярганлыгы өчен, зарарлыдыр. Бер табибтан рөхсәт алып, тәнне суык су ваннасына өйрәтелсә, бик файдалыдыр; канны куәтләндерергә ярдәме бик күп булыр. Биш вакытта тәһарәт алмак бер мөкатдәс дин эшен үтәмәк булдыгы кеби, үзебез өчен дә бер яртылаш ванна булып, тәнебезгә зур файдасы барлыгын инкяр кылмак мөмкин түгелдер. Мәгъдән сулары[205], «Боржом» кебиләр мәгъдә, бавыр, бөерәк[206] вә ком авыруларына, я эче киткән адәмнәргә эчәргә кушылса да, боларның яхшы вә яңасын сайламак шарт, вә мәгъдәне боларга өйрәтмәскә тиешледер. Башка эчемлекләргә килсәк, чәй вә кофе кеби нәрсәләр бик артык эчмәү шарты берлә. Бәгъзе файдалары булса да, коньяк, аракы, шәраб вә боларга охшаган көлли[207] эчемлекләр канны вә тамырларны бозган кеби, үпкә, бавыр, баш авыруларын, […] мәгъдә киңәю кеби адәмне һәлак итә торган бик күп авыруларга сәбәп булыр. Чахотка булдыра торган нәрсәләрнең дә иң башлысы менә бу эчемлекләрдер. Боларның намуска вә кесәгә китерә торган зарарлары тагын үзе башкадыр. Тугрысы эчкелек[208] дигән нәрсә динемездә дә харам, гакылга салып караганда да начар эштер. Эчкелек[209] эчмәк вә аңа даимчелек итмәк акрынлап үзеңне үзең үтерүдән башка һич нәрсә түгелдер.

Яхшы, тәза[210] йомырка, саф сөт, чапкан иттән пешерелгән кәтлит кеби куәтле ашлар, әйрән кеби куәт бирә торган нәрсәләр була торып, куәт бирер өчен дигән булып төрле эчемлекләр тотмак бик файдасыз, буш эштер. Эчкелектә бер адәмне, бәгъзе

[205] Мәгъдән суы – минераль су.
[206] Бөерәк – бөер.
[207] Көлли – барлык, бөтен.
[208] Эчкелек – монда: эчкечелек.
[209] Эчкелек – монда: хәмер, спиртлы эчемлек.
[210] Тәза – монда: яңа салынган, диетик.

вакытта тәмам бер өй җәмәгатен бәхетсез итәрлек шомлык бардыр.

Балаларыгызны бу эчке кеби начар нәрсәләргә аслан иялән-дерә күрмәгез. Эчкәннәре беленсә, бик тизлек берлә кулдан кил-гән кадәр тыярга тырышыгыз. Аштан соң җиңел генә бер кофе вә кыш көннәрендә иртә вә кич шикәрле чәй файдалыдыр. Ләкин артыкка китсә, боларның да зарары билгеледер.

## *31 нче дәрес*
## *Кипкән кура җиләге вә җимешләр*

Кипкән кура җиләге яки мәтрүшкә тәнне тирләтмәгә вә лимон кабыгы берлә дарчин һәм тирләтергә, һәм дә ашказанын төзәтергә, бигрәк тә һәр икесе суык тигәндә бик файдалыдыр.

[...] Саф вә файдалы сулар һәртөрле эсселекне китәрер. Бозлы эчемлекләр файда урынына зарар бирер.

Тәмәке дә сыек булмаган зарарлы эчемлекләр җөмләсеннән санала. Тәмәкенең эчендә никотин дигән бер агу, адәмнең вөҗүден[211] харап итәргә хезмәт итәр. Тәмәке тартучыларның сулу юллары бозылыр. Күкрәкләре тыгылыр, ютәл, какырык ясар. Ашарга иштиһаны[212] кисәр, йөрәк авыруы вә башка авыруларга сәбәп булыр, тешләрне дә саргайтыр.

Адәм бер мәртәбә моңар мөбтәля булса[213], ташлый алуы бик мөшкел булыр. Ләкин төрле зарарлары уйланса, ничек кенә булса да, ташлау лязем булган бер хәл икәне бик тиз аңланыр.

Тоташ моның төтененнән сакланмак бик тиештер. Кисәктән моны ташлау вә бик читен күк күренсә дә, өч-дүрт көн тартмаска тырышмак бу начар гадәтне бетерә алыр.

Ханымнар балаларының бу начар гадәткә өйрәнә башла-ганын сизү берлә моннан ваз кичермәкнең чарасына бакмаклары ляземдер. Төтеннең зарары күбрәк картайганда вә зәгыйфь тәнле адәмнәрдә күренер. Гакылы бар адәм, «Әйдә, бер нәрсә дә булмас

[211] Вөҗүд – гәүдә.
[212] Иштиһа – теләк, ашыйсы килү.
[213] Мөбтәля булу – дучар булу.

әле, тартканнарга нәрсә була соң», дип әйтми, ахырын уйлап, бу начар гадәткә үгрәнмәскә кирәк.

## *32 нче дәрес*
## *Тешләр*

Тешләр тән машинасының беренче тегермәне булганнан, боларны яхшы сакламак, чиста тотмак бик ляземдер. Бик җылы вә салкын нәрсәләрнең берсе артыннан икенчесен авызга алмак, күп шикәр ашамак, авызны чистартмый йөрмәк тешнең ялтыравын бетерер, тешләрне черетер, теш итләрен бозар. Кар кеби ак тешләр ханымнарның табигый зиннәтләреннән берседер. Тешләре керле вә кара булганнардан һәркем җирәнер. Мондыйлар һәрвакыт каты теш сызлауларыннан да котыла алмаслар. Тешләрне пакь тотар өчен һәркөн мисвак[214] яки порошок вә щетка берлә юарга кирәк. Аштан соң ничек кенә булса да авызны чайкарга, тешләр арасында һич нәрсә калдырмаска тиеш, тешләрне энә берлә казымак яхшы түгелдер. Үзенә махсус юнып ясалган каурый тотарга кирәк.

Һәркем тешләренең кадерен белергә тиеш. Тешләрен яхшы караган адәмнәр теш сызлау вә теш янмак кеби кешене гаҗиз итә торган нәрсәләрне күрмәсләр.

## *33 нче дәрес*
## *Һава вә яктылык*

Һава тереклекнең иң кыйммәтле бер нәрсәседер. Адәмнәр вә башка хайваннар, хәтта үләннәргә кадәр һавасыз яши алмыйлар. Һава көррәи әрызны[215] һәр яктан чорнап алган, күз берлә күренми торган, тоссыз вә илле чакрым калынлыгында бер газ катлавыдыр

[214] Мисвак – арак агачының ботакларыннан һәм тамырларыннан ясалган махсус теш чистарту җайланмасы, щетка.

[215] Көррәи әрыз – җир шары, глобус.

ки, эчендә мәвалиделхәмузә[216], карбон, азот вә су пары вә башкалар кеби нәрсәләр бардыр. Адәмнәр һаваның башка нәрсәләреннән артыграк мәвалиделхәмузәсеннән файдаланалар. Эссе вә салкынлыгының да һавага әсәрләре бик күптер. Эсселек һаваны кабартып, гәүдәсен зурайтып киңәйтер, суыклыкта гәүдәсен кечерәйтер. Эчендә утырыла вә ятыла торган урыннарның һәр заман сулау берлә һавасы бозылган булып, бу бозылган һава сулау җиһазларыннан булган үпкәгә, бигрәк тә канга вә тәнгә зарарлыдыр. Сулуыбызны эчкә тарткан вакытыбызда саф һаваны алып, тышка таба сулаганда эчебездәге бозылган һаваны чыгарабыз. Ягъни мәвалиделхәмузәне эчкә алып, карбонны[217] тышка чыгарабыз. Адәмнәр һәрвакытта яңа вә чиста һавага мохтаҗлардыр, шуның өчен бүлмәләрнең вә мәктәпләрнең һәркөн иртә берлә тәрәзәләрен ачып, һаваларын яңартырга кирәк.

Сазлык вә карьерларның һавасы бизгәк вә башка төрле авыруларга сәбәп булачагыннан зарарлыдыр.

Көррәи әрыз хар[218], могътәдил[219], барид[220] дия өч кыйсемгә аерылып, хар дигәне артык эссе булган җирләрдер, Гарәбстан кеби. Могътәдил урыннарының һавасы яхшыдыр, Кавказия вә Одесса кеби.

Бар мәмләкәтләр, бик салкын булып, бу җирләрдә бөтен кыш буе кар була, Сибирия кеби.

## *Юеш вә суык һава*

Юеш һава тәнгә зарар бирдеге кеби, суык һаваның да зарары бик күптер. Тирләгән көенчә җилгә вә суык һавага чыкканнар сырхауланыр, тиф, броншит[221] вә башка берничә төрле авырулар

[216] Мәвалиделхәмузә – кислород.
[217] Карбон – монда: углерод.
[218] Хар – эссе.
[219] Могътәдил – уртача.
[220] Барид – суык.
[221] Бронхит турында сүз бара.

һәм дә җиңел нәзләләр[222] күбрәк һава сукканнан хасил булыр. Каты суыкның тәнгә зарар бирүе эссегә караганда да артыграктыр. Иртә берлә урыннан торган вакытта беразга гына булса да аркага бер кием яки шәл салырга кирәк. Тирләгән көенчә су эчмәскә, җилгә каршы күкрәк ачмаска тиеш.

Иң кечкенә бер саксызлык, искә дә алынмаган бер салкын тию, вакытында каралмаса, куркынычлы авыруларга әйләнү ихтималы бардыр.

Кешесе күп булган шәһәрләрнең һавасы, тыгызлык сәбәпле, бозык булыр. Шуның өчен шәһәрдә торучыларның бигрәк артык саф һава иснәргә тырышулары ляземдер. Сулу юллары никадәр ару вә таза булса, тән дә шуның кадәр таза булыр.

Яктылык – бу да тереклек өчен бик әсәрле вә кирәкле бер нәрсәдер. Кояш яктысы тереклегебезнең иң кыйммәтле сәбәбедер. Якты ала алмаса, тән зәгыйфьләнер, кан суланыр, авырулыкка хәзерлек артыр. Яктыдан мәхрүмлек ахырында үлмәгә дә сәбәп була алыр. Артык яктылыкның да күзләр берлә мигә зарары бардыр.

Өй эченә һәркөн кирәк кадәрле якты керергә тиешледер ки, тереклекне харап итүче сыростьларны бетерә алсын. Төрле лампа яктыларының да күзгә зарарлары күп булып, бу зарарларны җиңеләйтүнең чараларына керешмәк ляземдер.

## *35 нче дәрес*
## *Хәрарәт*[223]

Хәрарәт – яшәр өчен иң кирәкле бер нәрсәдер. Хәрарәт булмаса, тән машинасы да эшли алмас. Тәндәге хәрарәтне иң артык булдыра торган нәрсә – мәвалиделхәмузә газыдыр. Таза вә авырусыз адәмнең тәнендә 37 дәрәҗә кадәр эсселек булыр ки, моңар «хәрарәт гаризия[224]» диярләр. Эсселек дәрәҗәсенең моннан артык я ким булуы тәндә бер авыруның барлыгын белдерә.

[222] Нәзлә – томау, суык тию.
[223] Хәрарәт – эсселек, кызулык, җылылык.
[224] Гаризи – табигый.

Эсселекне үлчи торган температур берлә табибларның тәндәге эсселекне үлчәп караулары шуның өчендер. Тәннең эсселеге 39 яки 42 дәрәҗәгә җитүе ул тән өчен дә хәтәрле булганга күрә, бик тиз ул эсселекне кайтарырга тырышмак ляземдер.

Эсселекнең иң табигый булганы кояш булып, «Кояш кермәгән өйгә табиблар күп керер» дигән зарбе мәсәл[225] мәшһүрдер. Тора торган өйләрнең җылылыгы 16 яки 20 градус тирәләрендә булса, тыйб[226] карамаклыгында уртача вә муафикъка хисапланыр. Артык эссе вә артык салкын да зарарлыдыр.

## *36 нчы дәрес*
## *Йокы*

Ми вә бөтен тәндә булган әгъзаларның камил рәхәтләнүенә иң беренче сәбәп булган нәрсә – йокыдыр. Гакыл куәте берлә тән вазыйфалары арасында бозылган тигезлекне хасил итәр өчен, адәмнең йокламаклыгы бер табигый эштер. Чөнки арыган, йөдәгән әгъзалар ял итмәсәләр, ахырында хәрәкәтләре читенләнер, хәтта хәрәкәтләнмәс тә булырлар. Йокыда уйлау куәте уяу вә эшендә булыр. Тугрысы йокы ярты үлем кебидер.

Йокының бик азы да, артык күбе дә яхшы түгелдер. Иң файдалы йокы – төнге йокыдыр. Йокы яшькә, гадәтләнүгә вә табигатькә карап төрлечә була. Алай да табибларча гомуми сурәттә кабул кылынган йокының чиге ошбу рәвешчәдер:

Бала туганнан 4 яшенә кадәр азында тәүлеккә 12 сәгать йокы ляземдер.

4 тән 7 яшенә кадәр – тәүлеккә 11 сәгать;

7–12 – 10 сәгать;

12–14 – 9 сәгать;

14–20 – 8 сәгать;

20–40 – 7–8 сәгать.

40 яшеннән югары булганнар өчен тәүлектә 6–7 сәгать йокы тамандыр. Йокы бүлмәләренең көндезләрдә һавасын яңартып,

---

[225] Зарбе мәсәл – мәкаль әйтү.

[226] Тыйб – медицина.

пәрдәләрне күтәреп якты кертергә вә яткан вакытта җәен-кышын һава йөри торган форточкаларны ачык калдырырга кирәк. Йомшак түшәкләр тәнгә сүлпәнлек биргән өчен, катырак йон урыннар вә матраслар хифзыссыйхәткә[227] муафикътыр.

Җәй көне берничә покрывал, яз көне бер юрган яки одеал, кыш бик салкын булса, бер юрган, бер одеал ябынмак җитәр. Моннан артыгы авырлыктыр. Баш астының биеклеге һәркем өчен уртача булганы яхшыдыр. Итле вә каны күп булган кешеләр өчен баш асты тәбәнәк булмак яхшы түгелдер.

Яткан вакытта әүвәл уң якка, соңыннан сул якка ятып йокламак мәслихәт[228] булып, чалкан ятмак муафикъ түгелдер.

Ята торган бүлмәдә яктылык лязем булса, иң яхшысы шәм яндырып, анда-монда ут төшмәслек рәвештә калдырмак тиештер. Лампа вә һава газларының зарары күп булганнан, якынга шәм вә шырпы куеп, утны сүндереп ятмак бигрәк тынычтыр.

## *37 нче дәрес*
## *Киемнәр*

Өскә киелгән нәрсәләр тәнне өретмәк вә салкыннан, эсседән сакланмак өчен киенгәнлектән, киенүдә ошбу нәрсәләр игътибарга алынмак тиешледер. Киемнәр муеннан башлап тубыкларга кадәр тәнне өретерлек вә сакларлык вә һава йөрерлек булып, канның йөрүенә манигъ[229] булмаслык рәвештә булмак ляземдер. Тыгыз вә кирәк кадәрледән артык биек якалар, әнә ул адәмне харап итә торган корсетлар сихәткә чиксез зарарлыдыр. Гакыллы ханымнар мода вә купшылык юлына үзләренең сихәтләрен вә газиз гомерләрен фида итмәсләр[230].

Бик нәзек күренсен өчен мәгъдәне[231], эчәкләрне, кабыргаларны кысып, төрле сырхауларга сәбәп була торган корсетларны,

---

[227] Хифзыссыйхәт – гигиена, сәламәтлекне саклау һәм аның юллары.
[228] Мәслихәт – тиеш, яраклы, киңәш ителгән.
[229] Манигъ – каршылык, киртә.
[230] Фида итү – корбан итү.
[231] Мәгъдә – ашказаны.

тар киемнәрне, янә аякны кечкенә күрсәтү фикере берлә тар вә борыннары очлы вә тугрысы ямьсез штиблетларны киючеләрнең һичвакытта рәхәтсезлекләре бетмәс.

Киемнең һәрнәрсәдән әүвәл чисталыгы вә бер дәрәҗә тәнгә ягымлы булуы шарттыр. Иске кием гаеп булмый, асыл гаепләнергә тиеш булган нәрсә дә киемнең ертык, сүтек вә керле булуыдыр. Эчке вә тышкы кием булып, икегә аерылган киемнәрне өйдә киелә торганы вә кешелеге дә булып, ике төрле киелүе вә торыла торган җиргә вә вакытына, вә кешесенә карап киелүе ляземдер.

Кыш көнендә тәнне җылы тотар өчен тәннең җылысын тартмый торган материалларны сайламак ляземдер. Моның өчен дә беренче дәрәҗәдә йон, икенче дәрәҗәдә мамыклы киемнәр кимәк кирәк.

Оеклар. Җәй көне җеп, кыш – йоннан тыгыз итеп бәйләнгән оеклар яхшыдыр. Мәмләкәтенә күрә көннәр салкын була башлагач та, кышкы киемнәр киелеп, яз көне көннәр тәмам җылынып җиткәнгә кадәр салынмаска кирәк. Җәй көне атнада ике, кыш бер мәртәбә эчке киемнәрне алыштырмак лязем. Кием тугрысында исрафтан сакланып, тәннең сихәтен сакларлык булуын күзәтмәк шарттыр.

[...]

### *40 нче дәрес*
### *Бозык фикерләр, тирән уйлар*

Тирән уйлардан, начар гадәтләрдән вә бозык фикерләрдән ерак булмак кирәк. Тирән уйлар мигә вә йөрәккә бик зарарлыдыр. Бер нәрсәгә бик каты һәвәсләнеп, булдырмый калмаска тырышмак, бер теләгән нәрсәгә ирешми калганлыктан, бик каты борчылмак кеби нәрсәләр тереклекне харап итүчеләрдер.

Начар гадәтләргә, кабахәт эшләргә өйрәнмәк вә бер такым[232] юк хыялларга, ялган хикәятләргә ышанып куркуларга төшмәк фикернең сәламәтлеген, тәннең рәхәтен җибәрер. Вә төрле-төрле матди вә мәгънәви сырхаулар тудырыр. Комсызлык һәр заман

[232] Такым – төркем.

кайгылы булыр. Булмаслык нәрсәләрне өмет вә арзу итмәк[233] күп борчу китерер. Күп уйланмак зур зарар бирер.

Һәр заман яхшы эшләргә, гүзәл гадәтләргә иярмәк, дин җәлил исламның боерганынча хәрәкәт итәргә тырышмак яхшыдыр. «Һай, Аллаһ, авырыйм микән әллә?» – дип, юк хыялларга тотылуның да бертөрле авыру икәнен онытмаска кирәк. Мәсәлән, бүлмәдә ялгыз ятырга курыкмак, җен, шайтан килер дип вәсвәсәләнмәк, күңелнең һәр теләгән нәрсәсен булдырырга тырышмак тәкъдиргә каршы килгән кеби, һәрнәрсәне үзе теләгәнчә булдырырга тамыгъ итмәк[234], билгеле, тәннең сихәтен бозар. Ихлас берлә бер мәсьәлә шәрифә яки Аятел көрси укымак адәмне һәртөрле шайтан афәтләреннән саклар дип чын күңелдән игътикад итмәк[235] күңел тынычлыгына беренче сәбәптер.

Әлхасыйль[236], адәмнәр Җәнаб Хакның нигъмәте булган тәннәрен һәртөрле авырулардан сакларга, сырхау булмаска тырышмак кирәк. Авырган адәмнәр бик тиз бер оста табибка мөрәҗәгать кылу берлә яхшы дәваланырга карамак ляземдер.

[…]

## *44нче дәрес*
## *Авыру хәлен белмәк*

Карендәшләрегездән, дусларыгыздан яки күршеләрегездән берсенең авырганын ишеткән вакытыгызда, мөмкин булганда, үзегез барып булмаса, кеше җибәреп хәлен белдермәк инсанияткә лязем булган бурычтыр.

Бу хәл сорамак алар өчен бик юаныч булган кеби, хәл сораучылар өчен дә бер инсаният бурычы үтәгән булыр. Дуслык ялгыз рәхәтлек вакытларда гына түгел, мәшәкать вә сырхау вакытында күренмәк тиештер.

---

[233] Арзу итү – теләү.
[234] Тамыгъ итмәк – зур теләк, бик каты теләү.
[235] Игътикад итү – ышану, инану.
[236] Әлхасыйль – җыеп әйткәндә.

Авыруларның хәлен белергә барганда, яннарында күп утырмак, тоташ сөйләмәк яки авыруны шикләнерлек рәвештә кайгы вә курку әсәре күрсәтмәк аслан[237] җаиз[238] түгелдер. Чөнки мондый эшләр авыруны бик борчып, сырхавының артуына сәбәп булыр. Авыру янында әүвәл хәлен сорамак, икенче авыруның үзендә билгеле башлы зәгыйфьлек-фәлән булмаганын яки кичәгедән бүген артыграк яхшы күренгәнен белдермәк, куркырлык һичбер нәрсә булмаганын аңлатмак, иншаллаһ, тиздән сәламәтләнмәк өмете барлыгын сөйләмәк ляземдер. Юату авыруның иң файдалы мәгънәви дәвасыдыр. Авыруның йөзенә озак карап тормак вә авыруы өметсез булса, йөзенә сөйләмәк һичбер җаиз түгелдер.

[…]

## *52 нче дәрес*
## *Пакьлек*

«Пакьлек – иманнандыр» дигәннәре нинди тугры сүздер. Өсте-башы пычрак, куллары, йөзе, аяклары, өе, хасил һәр нәрсәсе керле булганнардан һәркем җирәнгән кеби, чисталык юклыгы тәннең сихәтен дә боза. Тәннәрен, урын-җирләрен вә нәрсәләрен кара вә керле тотканнар һәрвакыт авыруга тотылырга хәзер булалар.

Иске кием кимәк һәрбер вакытта гаеп түгелдер. Ләкин керле киемнәр кимәк гаеп ителә торган эшләрдән вә гафу кылынмый торган хаталардандыр. Никадәр чиста вә зиннәтле киемнәр киелсен, тән, бит вә куллар чиста булмаса, ул зиннәтле киемнәрнең кадер вә кыйммәте булмый.

Бер ханым-кыз иртә берлә йокысыннан торуга, кулларын, йөзен яхшылап сабын берлә юмак, тешләрен порошок илә юып, намаз укыр өчен тәһарәтен алып, аякларын чисталап юмак ляземдер. Тәнне һәркөн салкын су ваннасына үгрәтелсә, пакьлек

[237] Аслан – һич, һичбер кайчан.
[238] Җаиз – дөрес, яраклы.

вә сихәткә сәбәптер. Һәркөн чәчләрне тарамак, атнада яки ун көнгә бер мунчага кереп, тәннең керен вә артык төкләрне китәрмәк вә лязем булганда башкача да госел кылмак[239] тиештер. Тәннең кере тиреләренең сулу алуына манигъ[240] булыр.

## *53 нче дәрес*
## *Янә пакьлек*

Җәй көне тәнне бигрәк еш пакьләмәк ляземдер. Керләнгән күлмәкләрне бик тиз алмаштырмак, ара-тирә хуш исләр сөртенмәк, кул вә аяк тырнаклары җитсә, хәзер кисмәк кирәк булдыгы кеби, эш вакытында киемнәр керләнмәс өчен башка кием кимәк, алъяпкыч япмак кирәк. Оек, чолгау кебиләрне бик еш алыштырмак ляземдер. Өйдәге бүлмәләр, тәрәзә төпләре, пыялалары, пәрдә вә көзгеләр, аш өе, савыт-сабалары, лампа вә шешәләр һәркөн иртә берлә себерелеп, чистартылырга яки хезмәтчегә күздән чистарттырырга кирәк. Бәдрәфләрне гаять чиста вә бераз карбол сибелеп сихәткә муафикъ бер хәлдә булдырмак ляземдер. Өйне себергән вакытта тәрәзә вә ишекләр ачылып, тузанны йотмаска тырышмалыдыр.

Куллар вә авызлар аштан соң мотлакан[241] юылырга кирәк. Борын вә аяк казымак бик артык җирәнгеч, шакшылыктандыр.

Сөлге, эскәтерләр, аяк киемнәре, аш өе нәрсәләре, стеналар, түшәмнәр – хасил өйнең һәрбер җире, хосусан, балалар берлә хезмәтчеләрнең соң дәрәҗәдә пакь вә тәмиз[242] булуларына дикъкать кылып карамак ханымнарның иң әсаси[243] вазыйфаларыннандыр.

---

[239] Госел кылу – ислам динендә билгеле бер тәртип буенча бөтен тәнне юып коену.
[240] Манигъ – каршылык, киртә.
[241] Мотлакан – һичшиксез.
[242] Тәмиз – чиста, пакь.
[243] Әсас – нигез, төп.

Чиста кызларны ата-аналары, ире, карендәшләре, дуслары вә һәркем сөяр. Керле вә пычрак булганнардан да, билгеле, һәркем нәфрәтләнер.

Пакь бер өй, тәмиз бер адәм, чиста нәрсәләр җанга җиңеллек, күңелгә шатлык, тәнгә сихәт бирер.

## *54 нче дәрес*
## *Кул эшләре*

Кисмәк, текмәк вә рәсем илә музыка кеби матур нәрсәләрнең һәркем тарафыннан сөелүе бик билгеле бер эштер. Хатыннар, тәннәре нәзек булганга күрә, нәфис эшләрне ирләрдән артык гүзәл итеп эшли беләләр. Болай булса, хатыннарның сәнаигъ нәфисәгә[244] мәел[245] вә истигъдадлары[246] артыграк димәктер. Ханымнар өчен кул һөнәрләренең иң башлысы тегү, бәйләү, кружево, челтәр, чигү, канва вә моңа охшаган нәрсәләр булып, моның һәртөрлесе саналса, бик озын булыр. Эшләрнең уңайлык берлә вә монтазам[247] бер хәлдә эшләнүе эшләсе эшенең рәсемен алмак берлә булыр. Бер ханым-кыз күргән нәрсәсенең карандашкаләм берлә үрнәген сызып ала алса, нинди нәкышь[248] булса да эшли алыр.

Бер кием киселәчәк булса, аның өлгесен бер кәгазьгә сызып кискәннән соң, шул өлге берлә кисмәк күп яхшыдыр. Рәсем – сәнаигъ нәфисәдер. Гүзәл чигү чиккән, яхшы кием тегә белгән ханым тегүчеләргә бирәсе акчаларны янына калдырган өчен, һәртөрле киемнәрне кисеп-текмәк сәнәгатен белгән мәгърифәтле ханымнар чын күңелдән макталырга лаектырлар.

Кул һөнәрләре ханымнарның иң зур зиннәтләреннән берседер. Һөнәрле кызларны һәркем сөяр. Кирәк рәсем, вә кирәк тегү вә башка кул эшләрен монда язмакта максуд хасил булмас. Чөнки

[244] Сәнаигъ нәфисә – нәфис кул эшләре.
[245] Мәел – кызыксыну, мәхәббәт.
[246] Истигъдад – сәләтлелек, булдыклылык.
[247] Монтазам – тәртипле, билгеле бер тәртип белән.
[248] Нәкышь – бизәк.

болар нәзарият[249] берлә генә аңланмас. Кул һөнәрләре мәктәпләрдә вә өйләрдә аерым мөгаллимәләр тотылып, эшләп күрсәтеп үгрәтелергә тиештер. Һәр ана үзе белгән кул эшләрен кызына үгрәтергә, кызының һөнәрле булуына тырышырга кирәк.

Һәр өйдә бер тегү машинасы, киерге, тегәргә, чигәргә вә бәйләргә кирәкле энәләр, кәтүкләр, йомгаклар, ефәкләр, гәресләр[250] булырга тиеш. Бөтен көн урам себеркесе кеби йөрүдән исә, ханымнарның буш вакытларда моның кеби эшләр илә шөгыльләнүләре бик яхшыдыр. Кул эшләре иң каты эч пошуларны, борчуларны таратырга хезмәт итәр.

## *55 нче дәрес*
## *Музыка*

Музыка да сәнаигъ нәфисәдәндер. Бер ханым укып язуны, дин хөкемнәрен, кул эшләрен, хосусан, тегү эшләрен, аш пешерүне вә моның кеби бөтен кирәк эшләрне үгрәнгәннән соң, мөмкин булса, музыка үгрәнергә дә тырышмак кирәк.

Музыка җанның хисләрен зиннәтләр. Тугрысы музыка җанга сафа вә азыктыр. Эш булмаган заманда кызларның намуслы вә әдәпле музыка белә торган хатыннан гитара, рояль вә башкалар кеби уеннардан берәрсен үгрәнүе мәслихәттер[251]. Яисә үзе көйләп җибәрсә, бөтен уйларны, кайгыларны таратырга, бөтен өй халкына бер шатлык вә күңеллелек бирергә ярдәме бардыр. Ләкин туйларда яки кеше җыелган җирләрдә уен уйнау вә җырлауны һөнәр итеп тотмак бик зур гаеп, шәрәф[252] вә хөсенгә[253] хилафтыр[254]. Димәк ки, бер ханым кыз-ханымнарга тиешле бөтен һөнәрләрне үгрәнгәннән соң, иркен вакытларда музыка берлә дә шөгыльләнмәктер.


---

[249] Нәзарият – теория, теоретик мәгълүмат.
[250] Гәрес – җептән сугылган бизәк.
[251] Мәслихәт – тиеш, яраклы, киңәш ителгән.
[252] Шәрәф – кадер, хөрмәт, затлылык.
[253] Хөсен – күркәмлек, матурлык.
[254] Хилаф – киресе, каршы.

## *56 нчы дәрес*
## *Табын кормак*

Чиста вә яхшы төзелгән табын иштиһаны[255] арттырыр. «Аш пешермәк бер һөнәрдер, табын кормак та бер белектер», диярләр ки – бик тугры сүздер. Иң яхшы пешкән нәфис ашлар да асты-өстенә килеп чуалып беткән табыннарда тәмсез күренер.

[…]



٦٢

خانملرنڭ كوركام خلقلى بولوب بولماغانلرى ويورتلرنەغى اشلرنى اشلەب اشلەمەگانلرى شوندى يورت اشلرينڭ حالندن بيلگلى بولا.

٥٩ نچى درس

عائلە، ئويلەنمك

آتا، آنا، ايـر، خاتون وبالالرنڭ ياكە شول نسلدن بولغانلرنڭ بتونسينە «عائلە» دييلور. بتون عائلەلرنڭ بربيرگە جييلووى هيئت اجتماعية انسانيەنى وجودكە كيترە. عائلەلر نى قدر بختلى بولسەآلاردن جييولغان جماعتلرنڭ بتونيسىدە شول درجەدە بختلى بولا.

شونڭ اوچون عائلە قدرينى يخشى بلمك وعائلە خلقينڭ هر برسينڭ گوزەل تربيە قيلنولرينە كوب طرشمق لازمدر.

«ئويلەنمك» آدملرنڭ طبعا محتاج بولغان بر حاللريدر. دنيادەغى مخلوقلرغە كوز سالساق بتون مخلوقاتنڭ برجفتگە محتاج بولغانينى كوررمز. آدملردەشولايدر. ئويلەنو بولماسە، نە بو كورنگان آدملر ونەدە باشقە حيوانلر بولماس ايدى. بولاى بولغاچ ئويلەنو الله طرفندن قويلغان برطبيعى قانون بولوب بزگەايەرو لازم بولغان بر دينى اشدر.

ئويلەنمك، بر اير برلە برخاتوننڭ هر برجهتدن جييلووى ديمكدر. يعنى اير برلە خاتوننڭ شريعت بيورغان رەوشدە بر تەن، بـر جان كبى اولارەق برلەشوب تورولريدر، كە بولارنڭ برسينە كيلگان قايغو ومشقت ايكنچيسنيدە قايغرتور. ديمك، كە اير برلە خاتون بربرسينڭ رفيق حياتى، هر وقت برگە بولاتورغان يولداشى، وفالى ياريدر. ئويلەنودن مقصود، بالالار يتشدرمك، الله تعالى قارشندە تقدير قيلنغان بر زمان اچندە دنيادە نسل قالدروغە خدمت ايتمك، عائلەنڭ بختلى بولووينەسبب بولغان نرسەلرنى تامالەمكدر. ئويلەنمك بر نيچە كيچەلك قوناق بولو توگل، معيشت عالمندە يولداشلق وهر وقت برگە تركلك ايتمكدر.

*«Гаилә дәресләре» китабының бер бите*

[255] Иштиһа – теләк, ашыйсы килү, аппетит.

## *59 нчы дәрес*
## *Гаилә, өйләнмәк*

Ата-ана, ир, хатын вә балаларның яки шул нәселдән булганнарның бөтенесенә «гаилә» диелер. Бөтен гаиләләрнең бер җиргә җыелуы һәят иҗтимагыя инсанияне[256] вөҗүдкә китерә[257]. Гаиләләр никадәр бәхетле булса, алардан җыелган җәмәгатьләрнең бөтенесе дә шул дәрәҗәдә бәхетле була.

Шуның өчен гаилә кадерен яхшы белмәк вә гаилә халкының һәрберсенең гүзәл тәрбия кылынуларына күп тырышмак лязем.

Өйләнмәк – адәмнәрнең табган[258] мохтаҗ булган бер хәлләредер. Дөньядагы мәхлукларга[259] күз салсак, бөтен мәхлукатның бер җефеткә[260] мохтаҗ булганын күрербез. Адәмнәр дә шулайдыр. Өйләнү булмаса, ни бу күренгән адәмнәр, вә ни дә башка хайваннар булмас иде. Болай булгач, өйләнү Аллаһ тарафыннан куелган бер табигый канун булып, безгә иярү лязем булган бер дини эштер.

Өйләнмәк – бер ир берлә бер хатынның һәрбер җәһәттән җыелуы димәктер. Ягъни ир берлә хатынның шәригать боерган рәвештә бер тән, бер җан кеби буларак берләшеп торуларыдыр ки, боларның берсенә килгән кайгы вә мәшәкать икенчесен дә кайгыртыр.

Димәк ки, ир берлә хатын – бер-берсенә рәфикъ хәяте[261], һәрвакыт бергә була торган юлдашы, вафалы ярыдыр. Өйләнүдән максуд – балалар җитештермәк, Аллаһы Тәгалә каршында тәкъдир кылынган бер заман эчендә дөньяда нәсел калдыруга хезмәт итмәк, гаиләнең бәхетле булуына сәбәп булган нәрсәләрне тәмамламактыр. Өйләнмәк берничә кичәлек кунак булу түгел, мәгый-

---

256 Һәят иҗтимагыя инсания – кешелек җәмгыяте.
257 Вөҗүдкә китерү – барлыкка китерү.
258 Табган – табигый.
259 Мәхлук, мәхлукат – җан иясе, җан ияләре.
260 Җефет – пар, ирнең хатыны.
261 Рәфикъ хәяте – тормыш иптәше.

шәт[262] галәмендә юлдашлык вә һәрвакыт бергә тереклек итмәктер.

Бер ирнең дүрткә кадәр хатын алуына шәригъ шәриф рөхсәт бирсә дә, боларның һәрберсен яхшы тәрбия кыла алмак, болар хакында барыбер тигезлек кылмак, тигез сөймәк вә тигез ашатмак, тигез киендермәк шарттыр ки, бу аслан[263] мөмкин түгелдер. Хатынсыз, ягъни бәкярлектә[264] тереклек кылучыларның һичбер вакытта бәхетле булганнары күренгәне юктыр. Никадәр дәүләтле вә ихтыяҗсыз булса да булсын, бер ир һәрничек тә мәхрүм тугры гакыллы бер хатынга, бер хатын да шундый бер иргә мохтаҗдыр. Бәкярләр никадәр булсалар да, һаман үксездерләр.

Бәкярләрнең ялгызлыклары җәһәтеннән очраган бәлаләре, чиккән җәфалары чиксездер. Бәкяр бер хатын күләгәсез агачка охшый.

Бала таба торган хатыннарны Аллаһы Тәгалә дә сөяр. Җимешле агач һәрбер җирдә кадерледер. Халыкның күплеге гаиләләрнең вә аларның җыелган һәят иҗтимагыянең куәтен арттырыр. Әмма балаларның яхшы тәрбияләренә тырышмак иң лязем булган шартлардандыр.

[…]

## *62 нче дәрес*
## *Кыз бирү*

Кыз бирүдә иң артык күзәтелә торган нәрсәләр: намус, тәннең тазалыгы, күркәм холык вә нәсел булып, матурлык иң соңыннан уйлана торган бер эштер. Бер ир матур булыр да, холкы яхшы булмас. Алай булганда, гаилә өчен ул ирдән бәхетлелек көтмәк мөмкин түгелдер.

Җиһаз. Кыз бирер өчен бөтен байлыкны бетермәк, яки нәрсәләр сатмак, бурычка батмак кеби эшләр зур гакылсызлыктыр. Бер кызның җиһазын ата-анасы ун яшеннән башлап, яки тагы да

---

[262] Мәгыйшәт – тереклек итү, көнкүреш, тормыш.
[263] Аслан – һич, һичбер кайчан.
[264] Бәкярлек – парсыз, ялгыз; гыйффәтлелек.

иртәрәк акрынлап хәзерли башласалар, кияүгә биргәнгә кадәр бер дә сизелми кулда кирәк кадәрле җиһаз хәзерләнгән булыр. Бу кыз бирү тугрысында һәркем юрганына күрә аягын сузарга тиеш. Артык акчалар бетереп, кирәк булмаган вә тотарга ярамаган артык зиннәтле нәрсәләр лязем түгелдер. Җиһаз бер өйгә, бер гаиләгә җитәрлек иң кирәкле нәрсәләр булмак кирәк. Һәркем өйләнүнең сәгадәтен[265] җиһазда эстәми[266], кияү берлә кыз арасындагы мәхәббәттә вә бер-берсенә килешүләрендә булуына канәгать кылырга тиештер.

Бу тугрыда күчергечкә каплаганнар, кеше күрсен дия, һич кирәкмәс нәрсәләрне җиһаз арасына тыкканнар, ахырында кулларында һич нәрсәләре калмый алданган булырлар. Бер мәртәбә кияр өчен эллә ничә йөз тәңкәләргә төшкән килен киемнәре, тарлыкка төшерерлек кадәр уздырышка эшләнгән кыйммәтле нәрсәләр начар эшләрдер.

Кызларны кечкенә вакытларында вәгъдәләшеп яки никахлап куймак яхшы түгелдер. Шуның өчен өйләнмәк, һәрбер җәһәттән Мөхәммәд галәйһи вә сәлләмнең шәригате даирәсендә булмак ляземдер. Ир берлә хатын бер-берсенең кадерен белеп, хатын иренә чын мәхәббәт берлә хезмәт итеп, ир дә хатынына чын күңелдән мәхәббәт итмәк кирәктер ки, бөтен гаиләнең бәхетлелегенә сәбәп булыр.

## *63 нче дәрес*
## *Ир берлә хатын*

Ир берлә хатын арасындагы гомуми эшләр вә боларның бер-берсенә каршы гомуми сурәттә булган вазыйфалары.

Өйләнүдән максуд булган нәрсә – нәселне арттыру берлә бергә, тереклек кылмак вә гаиләнең сәгадәте булганга күрә, ир берлә хатын бу хосусны күзгә алып, һәрвакытта яхшы киченергә тырышмактыр. Моның өчен дә бер-берсенә каршы һәрбер вакыт-

---

[265] Сәгадәт – бәхет.
[266] Эстәү – теләү.

та яхшы эш вә гүзәл хәлдә булулары ляземдер. Бу тугрыда ир берлә хатын арасында иң әүвәл эзләнә торган нәрсә – мәхәббәт вә чын ихластыр. Бер-берсеннән нәфрәт берлә киченмәк һәрвакыт тавыш-гаугага вә гаилә арасында тынычсызлыкка сәбәптер. Һәр ханым рәфикъ хәятен камил ихлас берлә сөймәк вә аңа итагать[267] вә хөрмәт кылмак, һәрзаман махсус ригаядә[268] булып, аның өчен кайгырып, ихласлы юлдаш булмак тиештер.

Һәрбер ир дә рәфикасын шул хисе берлә сөеп, ирлеккә муафикъ, инсаниятькә лаек сурәттә аңа күркәм мөгамәлә күрсәтмәк тиештер. Кайсы өйләрдә күренгән кеби, хатыннарның ирләренә баш булып, хаким итәргә керешүләре, аларны бер хезмәтче кеби хезмәт иттерергә тырышулары һәм гөнаһ, һәм дә гаептер.

Ир хатынның вәлие[269], махсус әмередер[270]. Хатын да әфәндесенең рәфикаи хәяте, җан юлдашыдыр. Бер хатынның иренә каршы, зурайган төсле булып, бер кырын каравы да ул хатынны бик каты шелтәләргә тиешле булган хәлләрдәндер.

Ханымнар үз әфәнделәренә каршы һәрбер вакытта тәгъзыйм[271] вә хөрмәт итеп, аларга каршы синле-минле сүзләр әйтүдән сакланып, «син» урынына «сез» диеп сөйләшмәк, ә ире чакырган вакытта, «Әфәндем!» диеп йөгермәк, бер нәрсә эшләргә кушкан вакытында, «Баш өстенә, әфәндем», кеби татлы сүз вә ыспайлык берлә кушкан йомышын үтәмәк ляземдер.

Бер хатын иренең сөюенә мәгърур булып, кирәк холкы да булсын, иренә каршы төсен бозса, иренең мәхәббәтен киметүдән вә бара-бара араларында салкынлык хасил булудан башка бер файдасы да юктыр.

Ир берлә хатын арасында төпле бер ышаныч хисе урнашырга вә болар һичбер вакытта бер-берсен алдамаска тиештер. Иренә килә торган кайгыдан хатын да чын күңелдән кайгырып,

---

[267] Итагать – күндәм булу, сүз тыңлау.
[268] Ригая – кайгырту, аңлау.
[269] Вәли – яклаучысы.
[270] Әмер – эш.
[271] Тәгъзыйм – олылау, хөрмәт итү.

бер пар күгәрчен кеби бер-берсенә күркәм мөгамәлә вә ярдәмдә булмак тиештер.

[…]

## *63 нче дәрес*[272]
## *Кайнана вә килен*

Кайнана дип әйтелгәндә киленнәрнең, киленнәрдән сүз чыкканда, кайнаналарның йөзләрендә бер салкынлык әсәре, мәгаттәассеф[273], һәр өйдә күренмәктәдер. Кайнанасыннан мәмнүн[274] килен яки киленнән разый булган кайнаналар тугрысы бик сирәктер. Бу ярамаган хәлләр, һич шөбһәсез, тәрбия кимлегеннәндер, наданлыктан туган бер нәрсәдер. Тәрбиядә үскән бер ханым-кыз кайнанасын олуглап, аңа хөрмәт берлә эш кылуны, үзен белгән бер кайнана да киленен сөюне вә яхшы тотуны белер. «Килен берлә кайнана бер казанда кайнамас» дигән сүзләр бер такым[275] каршы вә тәрбиясез хатыннарның дошманлыклары берлә сөйләгән буш сүзләрдән башка бер нәрсә дә түгелдер.

Кияүгә барган кызлар бер мәртәбә уйлап караргә тиешледер ки, кайнана дигән кеше – рәфикъ хәятенең[276] анасыдыр. Ире әфәндесе – аның тәненнән аерылган бер кисәктер.

Бу хатын ул ирне дөньяга китермәгән булса иде, бу яхшы ирне таба алмас иде. Ул хатын аны эстәмәгән[277] булса иде, аны углына алмас иде.

Хатыннар өчен иргә хөрмәт кылмак ничек бер дини эш булса, ирнең анасына вә якыннарына тәгъзыйм[278] вә ригаять

[272] Текстта 63 нче дәрес дип күрсәтелгән, тәртип буенча караганда 68 нче дәрес булырга тиеш.
[273] Мәгаттәассеф – үкенечкә каршы.
[274] Мәмнүн – риза.
[275] Такым – төркем.
[276] Рәфикъ хәяте – тормыш иптәше.
[277] Эстәү – теләү.
[278] Тәгъзыйм – олылау, хөрмәт итү.

кылмак[279] шулай ук бер бурычтыр. Кайнаналы ханымнар белергә тиештер ки, өйнең иң зур ханымы – кайнанасыдыр.

Килennәр ирләреннән никадәр мәхәббәт әсәре күрсәләр дә, бу тугрыда азгынлык күрсәтеп, үзләрен бик зурга санап, өйгә үзләре хуҗа булып, хаким[280] кылмакчы булмасыннар. Чөнки килен берлә кайнана арасындагы тавышлар моның кеби эшләрдән башланыр. Яшь зурлыгына ялгыз гаилә арасында гына түгел, һәр җирдә ригаять кылмак важибтер[281]. Килен дә ханымдыр, ләкин ханымлыгын кайнанасына вә аның якыннарына хөрмәт кылмак берлә күрсәтмәге ляземдер. Кайнана өйнең эшләрен идарә кылучының иң зурыдыр.

[…]

## *73 нче дәрес*
## *Бала*

Бала берсе ир, берсе хатын – ике рәфикъның бергә кушылуы сәбәбеннән дөньяга килгән бер адәм мәхсуледер[282] ки, дөньяга килүе берлә фани дөньяны бакый дөньядан аерыр. Яисә дөньядан үткәннәр урынына адәмнәрнең санын тутырыр.

Бала – өйләнүнең ядкаре, ир берлә хатын арасындагы мәхәббәтнең бер җанлы дәлиледер.

Бала – адәмнәр җәмгыятендә гаилә хөсәене[283], бергәләшеп вазыйфаны әда кылмак[284] фикерен уяндырып нигезләндергән, җәмгыяте мәдәниянең киләчәктәге бәхетле булуына хезмәт итүче булган бер җанлы мәхсулдыр.

Бала – тән вә гәүдә җәһәтеннән бик кечкенә, мәгънә, кыйммәт җәһәтеннән бик олуг бер нәрсәдер. Баланың тәрбиясе гаиләнең сәгадәтенә, адәмнәрдән җыелган мәдәни җәмгыятьнең

[279] Ригая итү – кайгырту, аңлау.
[280] Хаким – хуҗа.
[281] Важиб – тиешле, шиксез үтәлергә тиешле.
[282] Мәхсул – барлыкка килгән әйбер, продукт.
[283] Хөсәен – гүзәл, яхшы.
[284] Әда кылу – үтәү.

бәхетлелегенә дә сәбәп булачагына, балаларга никадәр күп әһәмият бирелмәк лязем идеген бу да белдерер. Балаларын ляземчә тәрбия кылганнар вазыйфаларын тәмам әда кылган булырлар. Бәгъзе вәхши вә хайван аналарның карынындагы балаларын төшереп, тәләф кылганнары[285] да бардыр. Бу хәл: Аллаһның бүләге булган бер вөҗүднең[286], бер гөнаһсыз баланың бетерелүе булганнан зур бер гөнаһтыр. Зур бер җанилек[287] булып, низам берлә каты җәза кылынырга тиеш булган бер эштер.

Карындагы баласын гозер[288] шәргысез төшергән бер ана җанидыр, кеше үтерүчедер. Аллаһ каршында да газапка лаектыр. Менә бала төшерү өчен эшләнгән берничә зарарлы эшләр берлә аналарның үзләрен-үзләре зәгыйфьләндерүләре бөтенләй юләрлектер, гәүдәләрендә бала китерү мөмкин булмаслык бер гозерләре булмаганда, бала тудырасылары килмәгән, балалардан туйган аналар нәфрәт кылынырга лаектырлар. Дөрес, бала тудырмак вә үстермәк читен вә мәшәкатьле бер эштер, ләкин инсаният галәменә бер вөҗүд кушмак зур бер һөнәр вә шәрәфтер[289].

Баланың бер мәгъсуманә[290] көлүе, бер ананың бөтен кайгыларын, мәшәкатьләрен оныттырырлык кадәр әсәрледер. Балалар – гаиләнең зиннәте, ана вә аталарның зур күңел юанычыдыр. Хәкимнәр[291] балалыкны биш вакытка бүлмешләрдер ки, алардан беренчесе – баланың туган сәгатеннән дүрт тулганга кадәр булган вакыттыр, моңар «сабавәт әүвәли»[292] диярләр.

Икенчесе – биштән сигез яшенә кадәр булган «сабавәт сания»[293] заманыдыр.

---

[285] Тәләф кылу – әрәм-шәрәм итү, бетерү, бозу.
[286] Вөҗүд – гәүдә, кеше.
[287] Җанилек – хыянәт, җинаять.
[288] Гозер – сәбәп, сылтау.
[289] Шәрәф – дан, дәрәҗә.
[290] Мәгъсуманә – гөнаһсызларча, саф, керсез күңел белән.
[291] Хәким – акыл иясе, галим.
[292] Сабавәт әүвәли – беренче сабыйлык чоры.
[293] Сабавәт сания – икенче сабыйлык чоры.

Өченче – тугыздан унике яшенә кадәр булган «тофулият әүвәли»[294] заманыдыр.

Дүртенчесе – уникедән униҗе яшенә кадәр булган «тофулият сания»[295] вакытыдыр.

Бишенчесе – унҗидедән егерме яшенә кадәр дәвере «шабабтыр»[296].

Балалар бик сөйкемле, бик файдалы бер вөҗүдтерләр. Җәнаб Хакның аналарга багышланган хас шәфкате баланы имезмәк, үстермәк өчен беренче сәбәптер. Балалыгына махсус бер тавыш берлә «әннә» дигән бер баланың шул фәрештә шикелле хитабыннан[297] әсәрләнмәячәк һичбер күңел булу мөмкин түгелдер. Шуның өчен балалар бик кыйммәтле җимештерләр. Ләкин аларга зиннәт бирер өчен гүзәл тәрбия кылынулары шарттыр.

[…]

## *77 нче дәрес*
## *Бала тәрбиясе, моның кирәклеге вә бала тәрбия кылмак хакында беленергә кирәк булган эшләр тугрысында гомуми фикер*

Балаларның яхшы тәрбия кылынуы – гаилә тәрбиясенең нигезедер. Гаилә тәрбиясе дә гомуми тәрбиянең җаны, беренче сәбәпчеседер. Болай булгач, балаларның тәрбиясе никадәр камил булса, гомуми тәрбия дә шулкадәр камилләнер. Адәмнәр яхшы сыйфатларны вә гүзәл хасиятләрен[298] кәсеп итү берлә камил булырлар. Адәмлек, мәхлукларның[299] хөрмәтлесе булу гакыл вә фикер һәм дә фазыйләтләрне[300] кәсеп итү берләдер. Фикернең

[294] Тофулият әүвәли – беренче балалык чоры.
[295] Тофулият сания – икенче балалык чоры.
[296] Шаб – егетлек (үсмерлек) чоры.
[297] Хитаб – эндәшү, мөрәҗәгать.
[298] Хасият – үзенчәлек.
[299] Мәхлук – җан иясе.
[300] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш.

нуры вә инсаниятнең фазыйләте тәрбия аркасында заһир булыр[301].

Дөньяга килгән көненнән бирле һичбер тәрбия күрмәгән бер адәмнең адәмлеге ялгыз исемендә генә калыр ки, моның кебиләр ни дөньяда, вә ни ахирәттә һичбер сәгадәткә ирешми, мәхрүм булып, үкенечтә калырлар.

Бала – Аллаһы Тәгаләнең ата-анага тапшырган бер әманәте булганнан, аны тәрбия кылмак ата-анага тиешле булган бер бурычтыр. Дөньяга килгән бер баланың күңеле, имам Газали әйткәнчә: «Һәртөрле нәкышьләрдән[302] буш булган бер нәфис җәүһәрдер ки, аңар ни генә нәкышь кылынса да, мөмкин вә кайсы гына якка тартсаң, анда тартылыр».

Болай булганда, ата вә аналар балаларын яхшы тәрбия кылырга дин вә инсаният җәһәтеннән мәҗбүр булып, аларның бирәчәк тәрбияләреннән балалар бәхетле булган кеби, үзләре дә әзер вә савапка ирешерләр. Балаларга яхшы холыкларны өйрәтмәк, аларны начар юлдашлардан сакламак, назлылыкка, артык зиннәтләргә вә рәхәтләнеп тик ятарга күңел куйдырмаслык, укыган вакытта гомерне буш үткәрергә өйрәтмәслек, һәртөрле хәлгә каршы торырлык сурәттә үстермәк, диндар, тугры, раст сүзле, кешегә изгелек теләүче, тырыш вә көчле ясамак, хасил баланы бөтен мәгънәсе берлә инсан итмәк, әүвәл башта ата-анага лязем булган иң кирәкле бурычларыдыр.

Бер адәм җаны вә тәне, игътибары берлә, ягъни мәгънәви вә матди эшләре берлә ике кыйсем булганга күрә, бер баланың тәрбиядән тәмам өлеш алуы да фикер вә җанының да, тәненең дә төзеклеге берлә мөмкиндер. Димәк ки, тәрбия – җан вә тән тәрбиясе буларак, ике кыйсемгә бүленүе лязем килер. Тән тәрбиясеннән максуд – сихәт, җан тәрбиясеннән максуд – фазыйләт[303] берлә сыйфатланудыр. Адәмлекнең фазыйләте, дөнья вә ахирәттә

---

[301] Заһир булу – ачык булу, күренеп тору.
[302] Нәкышь – бизәк.
[303] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш.

бәхетле булырга сәбәп булган шәригать мотаһһәр[304] боерганча, хәрәкәт кылу берлә хасил булыр.

Мәгънәви тәрбия – инсаният, инсаф вә гаделлек, гыйффәт, яхшы эшләргә мәхәббәт, начар эшләрдән сакланмак кеби хисләрне балаларның күңелләрендә тудырачак рәвештә булырга кирәк. Ата-анага хезмәт, карендәшләргә хөрмәт, дус-ишкә күркәм мөнәсәбәт күрсәтмәк, милләткә хезмәт, хезмәтчеләргә, хәтта хайваннарга каршы да яхшылык берлә хәрәкәтне инсаният кагыйдәләреннән дип белмәк, менә болар барысы да мәгънәви тәрбиянең кирәкле кыйсемнәредер. Бу юлда тәрбия күргәннәрдән бөтен адәмнәр вә инсаният галәме файда күрерләр.

[…]

## *79 нчы дәрес*
## *Янә тәрбия*

Тәрбиянең ике кыйсемендә тоташ булган тагы бер тәрбия бардыр ки, моңа «тәрбияи мәдәния» исеме бирелер. Бу да мәдәни эшләрдә иң артык тәхсин кылынырга[305] ярарлык бер хәрәкәтнең рәвешен күрсәтер.

Ләкин мәдәни тәрбия икенче мәгънәсе берлә аңлашмасын. Ягъни пакьлелекка, гыйффәткә хилаф[306] булып, мәдәният йөзеннән лязем кеби күрсәтелмәк эстәнелгән[307] бәгъзе начар эшләрдән сакланмак тиештер. Чын мәдәниятне, мәдәни тәрбияне ислам хәкимнәре[308] тәмам берлә җыйгандыр. Исламият берлә мәдәният икесе игез туганнар булып, Аллаһ каршында дин исламияттер.

Тәндә сәламәтлек булмаса, гыйбадәт кылмак вә хезмәт мөмкин булмадыгы кеби, сихәте бозылган бер адәмнең җаны вә бөтен мәгънәвияте мөшкеллек вә газап эчендәдер. Болай булганда мәгънәви тәрбия таза, төпле бер матди тәрбиядән соң гына

---

[304] Мотаһһәр – изге.
[305] Тәхсин кылу – мактау.
[306] Хилаф – киресе, каршы.
[307] Эстәү – теләү.
[308] Хәким – акыл иясе, галим.

вөҗүдкә чыга[309] алачагыннан, әүвәлдә баланың тәнен, икенче җанын тәрбия кылмак лязем килер. Ягъни әүвәл тән тәрбиясен тәмам кылып, бу таза нигез өстенә инсаниятнең нык бинасы булган мәгънәви тәрбияне салырга кирәк. Тәрбия бишектән башлар, кабердә тәмамланыр. Ләкин бик нык тәрбиянең әүвәлге вакыты балаларга оят әсәрләре күренә башлаган вакыттыр ки, бу яхшыны яманнан аера башлауларының галәмәте булган оят күренә башлагач та, ата-анада булган кадер-тәрбиягә бик чыннан керешелер. Бер балада оялу әсәренең күренүе – гакылының нуры әүвәлге шәүләсен күрсәтә башлавы димәктер. Мәсәлән, алты айлык бер бала бер дә курыкмый кулын утка тыга алыр, чөнки анда һәнүз[310] аеру хисе уянмагандыр. Шундый баланың үз-үзеннән бәгъзе начар эшләргә оялып, аннан саклана башлавы, үзенең кечкенә гакылынча, яхшы-яманны аера башлавы булып, тәрбиянең иң артык әсир итә торган вакыты да бу вакыттыр. Бу вакытта гадәтләнгән эшләр һич үзгәрми торган бер гадәт булып калыр.

Ислам галимнәре вә хәкимнәренең васыятьләренчә, тәрбиядән соң алган янә эш бардыр ки, ул да баланы имезеп үстерә торган ананың яки тәрбиячесенең хәләл ашаучы вә изге хатын булуыдыр. Харамнан хасил булган сөттә бәрәкәт булмаган кеби, тәненең камыры мондый харам нәрсә берлә әчетелгән балаларның бозыклыкларга мәел кылучан[311] булуы билгеле вә тәҗрибәләр берлә заһирдыр.

Тән тәрбиясе хакында лязем булган тәдбирләр[312] хифзыссыйхәт[313] өчен тырышмактыр. Ләкин шуны да онытмаска тиештер ки, баланың тән тәрбиясе берлә бергә әхлак тәрбиясе дә акрынлап иҗраэ кылына[314] бармак ляземдер. Баланың дөньяга килгән көненнән әүвәлге тәрбиягә керә торган заманына кадәр гүзәл инсаният хисләре ата-ана тарафыннан киңәйтелергә тиештер.

---

[309] Вөҗүдкә чыгу – бар булу, барлыкка килү.
[310] Һәнүз – һаман, һаман да.
[311] Мәел кылу – күңел кую, кызыксыну, теләк.
[312] Тәдбир – тиешле чара, алдан күрү.
[313] Хифзыссыйхәт – гигиена, сәламәтлекне саклау һәм аның юллары.
[314] Иҗраэ кылу – үтәү, җиренә җиткерү.

## *80 нче дәрес*
## *Матди тәрбия*

Матди тәрбия кыйсеменнән шуны да күзгә алмак ляземдер ки, балалар ашарга бик хирыс булалар. Ни тапсалар, шуны ашамакчы булып, ашалмый торган нәрсәләргә кадәр авызларына кертәләр. Баланың бу комсызлыгын бетерер өчен, уртача ашауга өйрәтеп, хәтта соңга табарак кайсы вакытта коры икмәк ашарга да гадәтләндермәк берлә уртача бер тереклеккә ияләндермәк лязем булып, кием-салым тугрысында да уртача тормышка гадәтләндермәк ата-ана берлә тәрбиячеләрнең бурычыдыр. Балам ашасын, тизрәк үссен диеп вакытлы-вакытсыз ашатмак, кулына төрле-төрле зарарлы нәрсәләр бирмәк, аны комсызлыкка өйрәтмәк балага мәрхәмәт түгел, зарардыр. Аналарның бу тугрыда артык шәфкатьтән саклануллары бик ляземдер. Чөнки бу рәвештә үстерелгән балалар зәгыйфь, сырхау булып, аяклары җеп, корсаклары гөп, башлары тубал кеби булып, биш-алты яшькә кадәр аякларына йөри алмый утыралар. Ахырында зәгыйфь вә начар булып, бил сөякләре имгәнгән, бөкреләре чыккан булырлар. Боларның ни үзләреннән, вә ни дә мәйданга китерәчәк балаларыннан файда көтелмәс.

Балаларга өсте-өстенә киемнәр кидертмәк тә зарарлыдыр. Баланы суыкка, эссегә һәм михнәт вә мәшәкатьләргә алдан яхшы гына ияләндермәк ляземдер. Буыннарының хәрәкәтен җиңеләйтер вә тәннәренең куәтен арттырыр өчен йөгермәк, сикермәк вә уйнамак кеби хәрәкәтләрдән тыймый, мондый файдалы хәрәкәтләрдән тәрбия даирәсендә файдалануларына тырышмак тиештер.

Тик утырырга өйрәнгән балалар эшлексез вә ялкау булып үсәләр. Тәннең яхшы, таза булып үсүе өчен тар киемнәрдән, кысып бәйләүләрдән сакланмак ляземдер. Балаларның тән тәрбияләре тугрысында иң артык кирәк нәрсә – саф һава, яхшы су, вакытлы вә уртача ашау, хифзыссыйхәткә муафикъ[315] уен, киң

[315] Муафикъ – туры килгән.

кием берлә, һәр эшне тәртип берлә вакытында кылырга соң дәрәҗә тырышмактыр ки, милләт вә мәмләкәтебезгә яхшы вә гүзәл хезмәт итә алырлык вә үзләре дә бәхетле була алырлык сурәттә, куәтле гәүдәле балалар мәйданга чыга алсын.

## *81 нче дәрес*
## *Гомуми сурәттә балалар тәрбия кылмак ысулы*

Бер бала кечкенәдән ни рәвешле тәрбия кылынган булса, зурайгач та шул рәвешле тәрбиягә гадәтләнер. Шуның өчен тәрбиянең нигезе булган әүвәлге тәрбия бигрәк кирәкле вә бик артык дикъкать ителергә тиешле булган эшләрдәндер. Тәрбиясе өскә алынган бер баланың табигать вә гәүдәсе берлә истигъдад[316] вә зирәклеге гүзәл алынмак вә бер тәрбия кылучыга тапшырырга мәҗбүр булынса, тәрбия кылучының бала берлә бер мәзһәбтә, сау вә куәтле вә һәрбер җәһәттән гүзәл вә мәгълүматлы булуын күсәтмәк зур шарттыр.

Мәсәлән, ачучан бер баланы башкаларга караганда артыграк йомшаклык берлә тәрбия кылып, ачучанлыгын арттырмаска, аңгыра сыман балага көче җитмәслек нәрсәләрне өйрәтәм дип кысмаска кирәк. Хасил, истигъдад вә кабилиятенә карап, баланың җанын вә вөҗданын нурландырмага, фикерен зиннәтләмәгә хезмәт итмәкнең кирәклеген ата-ана вә бөтен тәрбиячеләр һәр нәрсәдән әүвәл күзгә алмаклары ляземдер.

Тәрбия кылучылар баладагы әхлакның көзгесе булдыкларыннан, боларның күркәм холыклы вә инсаниятлеләрен сайламак ляземдер. Хәлфә никадәр мәгълүматлы булса да, холкы начар булса, баланың холкын бозудан башка һичнәрсәгә ярамас. Христиан мөрәббияләр[317], билгеле, балаларны үзләренең дини хисләренә күрә тәрбия кылачакларыннан, баланың дине булган гүзәл хисе бозылмасын өчен, ислам мөрәббияләренә тапшырмак мәслихәттер[318]. Ана телен вә диннең хөкемнәрен өйрәнмәс борын

---
[316] Истигъдад – сәләтлелек, булдыклылык.
[317] Мөрәббия – тәрбияче.
[318] Мәслихәт – тиеш, яраклы, киңәш ителгән.

балаларга ят телләрне өйрәтмәк вә укытмак бер гүзәл нәтиҗә чыгара алмас. Аларның кечкенә вә һәнүз[319] үсеп җитмәгән миләре мондый артык нәрсәләрне сыйдыра алмаганга күрә, вакытыннан әүвәл авырыр. Баштарак бераз тәрәккый[320] әсәре күренсә дә, бара-бара зирәклекләре сүнгән кеби бер хәлгә килер. Шуның өчен балалар әүвәл үз телләрен вә дини телен белмәк, башка телләрне аннан соң өйрәнмәк ляземдер. Ислам дине ят телләрне өйрәнүдән манигъ[321] кылмыйдыр.

## *82 нче дәрес*
## *Балаларга мәгънәви вә әхлакый тәрбияне ничек бирергә кирәк?*

1. Баланы ярамаган эшләрдән сакландырып, яхшы эшләргә кызыктырмак, аның янында ямьсез вә йогышсыз кыланышлар, гаеп булырлык сүзләр, ачулар, катылыклар күрсәтмәскә тиештер.

2. Адәмнәргә яманлык кылмаска, кулдан килгән кадәр яхшылык кылырга, зәгыйфьләргә мәрхәмәт вә адәмнәргә каршы күңелендә бер шәфкать вә ярдәм әсәре уяндырмага тырышмак кирәк. Ярдәм вә шәфкать кылышу бөтен җәмгыятьнең бәхетлелек нигезедер.

3. Балалар кешегә ияргә бик артык мәел[322] кылынганнарыннан, һәр күргән нәрсәләрен күчерергә, хосусан зурларның кылган эшләрен эшләп карарга тырышачакларыннан, ата-ана вә тәрбияче баланы һәрвакыт яхшы юлга күндереп, үзләре дә шул юл берлә китмәк тиештер.

Күркәм холык иясе булганнары һәрбер хәлләреннән күренеп торып, балаларга үрнәк булырлык булсын.

Балаларга коры нәсыйхәт кенә әсәр кылмый[323]: яхшы дигән бер нәрсәне эшләп күрсәтмәк вә ул эшнең яхшылыгына бала-

[319] Һәнүз – һаман, һаман да.
[320] Тәрәккый – алга китү, прогресс.
[321] Манигъ – каршылык, киртә
[322] Мәел – кызыксыну, мәхәббәт.
[323] Әсәр кылу – тәэсир итү.

ларны ышандырмак ляземдер. Юкса шул начардыр, аны эшләмә дигән кешеләр үзләре шул начар эшне эшләсәләр, ул тәрбиядән һичбер файда күренмәс, юк җиргә сулу төкәтелгән булыр. Болай булгач, балалар гүзәл тәрбияне, инсаният фазыйләтләрен[324] ялгыз телдән ишетү берлә генә түгел, эшләгәнне күреп кәсеп итүләре ляземдер. Бер бала тәрбия кыла торган адәм, балага тугры эшнең яки тугры сүзнең яхшы булганын сөйләп тә, үзе аның хилафынча[325] ялган сүз сөйләсә, бала аның яхшылыгына һич тә ышанмас. Балага катылыктан артыграк йомшаклык күрсәтмәк, шелтәләүне сирәк вә кирәк булганда вә вакытта, вә урынында эшләмәк һәрвакыт тугрылыкны сакламак, аңар каршы лаегынча бер мәхәббәт әсәре күрсәтеп, һәрвакыт аңа хәер хаһ[326] булганын белдермәк лязем булыр.

Бер начар эшне күрү берлә тизрәк йөзенә ормак, ахырында аны шомарткан кеби тоташ орышулар, шелтәләр берлә дә кысмак каршылыкны арттыруга вә гарьсезләнүенә сәбәп булыр. Таяк бигрәк зарарлы вә мәмнугъдыр[327]. Кыйнау ерткыч хайваннарга махсустыр. Тугрысы таяк берлә бала тәрбияле булмас. Булса да куркудан гына булып, вакытлыдыр. Таякка ияләнгән балалар йөзсез булырлар. Әүвәлдән тугрылык вә йомшаклык берлә тәрбия кылынганнарга таяк хаҗәт түгелдер. Таяк төшмичә белми, дигәннәр әүвәлдән эшне бу дәрәҗәгә китергән өчен үзләре гаепледер.

[324] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш.
[325] Хилаф – киресе, каршы.
[326] Хәер хаһ – теләктәш, яхшы теләктә булу.
[327] Мәмнугъ – тыелган.

## *83 нче дәрес*
## *Мәкяфәт*[328]

5[329]. Тәрбиясе яхшы барган балага үз дәрәҗәсенә мәкяфәт кылмак вә моның хилафынча[330] булганнарга ислах кылырлык рәвештә җәза бирмәк тәрбиянең нигезедер.

Мәкяфәт өчен аларны татлы сүз берлә тәхсин итмәк[331], кирәк нәрсәләрдән берәр нәрсә алып бирмәк, артык сөйгән нәрсәләренә ирештермәк, бергә утырып бик чыннан сөйләшмәк кеби хәлләр берлә мәкяфәт кылмак кирәк. Җәза биргәндә артык сөйгән нәрсәләреннән мәхрүм итмәк, аңа каршы ачулы күренмәк, яки бер бүлмәгә ябып куймак, җомга көннәрдә киемнәрен кидертмәү, бер вакытка уеннан тыймак – шулар җитәр. Бала бер кырын караудан куркып, аның җәза икәнен белсен. Җәза вә мәкяфәт аларның белемнәре дәрәҗәсендә булмак ләземдер.

6. Һәр бала балалыгын итәр, зур вә кечкенә ничек тә бер кабахәт эш эшләр. Бу кимчелекләрен билгеле бер юлы вә бөтенләй бетерү мөмкин түгелдер. Вакыты берлә вә акрынлап төзәтү мөмкин булыр.

7. Балаларга якты йөзле булып, шаяртмаслык дәрәҗәдә мәхәббәт әсәре күрсәтеп, һәр эштә сәбатлы[332] булуны белдермәк ләземдер. Балага эшләнмәслек нәрсәләр берлә вәгъдә кылмак, вә булдырмаслык нәрсәләр берлә куркытмак тиеш түгелдер. Чөнки ул вәгъдә кылынган нәрсәнең яки җәзаның кылынмаганын күреп, соңыннан чыннарын да эшләми башлар. Баланың фикеренә ялганчылык орлыгы игелгән булыр.

8. Ачу-кычу вакытында балага җәза бирмәк зарарлыдыр. Чөнки бу хәл әдәп бирүдән дә бигрәк үч алу булып, баланы карыштырудан, күңелендә ышанычсызлык хисе арттырудан башка һичнәрсәгә ярамас.

---

[328] Мәкяфәт – яхшылыкка каршы эшләнгән яхшылык, бүләк.
[329] Текстта 4 нче пункт бирелмәгән.
[330] Хилаф – киресе, каршы.
[331] Тәхсин итү – мактау.
[332] Сәбат – фикердә, эштә нык торучанлык, чыдамлылык, даимилек.

9. Бала янында һәрвакыт тугрылык берлә булмак, чын сүзләр сөйләмәк лязем булса да, акыллы торган вакытында аны куркытырлык караңгы чырай, бер хакимлек сурәте күрсәтмәк тә яхшы түгелдер. Бу хәл аның куркуына сәбәп булып, үзенә хаксызлык ителдегенә вә яхшылыгының кадере беленмәгәненә күңеле йөгереп, ачуы килер. Гаре вә ояты ертылып, төрле-төрле оятсызлыкларга батырчылык кыла башлар. Шуның өчен һәрвакыт балага гаделлек вә йомшаклык берлә остазларча эш кылмак тәрбиянең иң мөхкәм[333] нигезедер.

## *84 нче дәрес*
## *Каршылыкны бетерү*

10. Һәрнәрсәдән әүвәл балаларның каршылыкларын бетерергә тырышып, һәр эстәгән[334] нәрсәләрен булдырырга өйрәтмәү тиештер. Ата-аналар тәмам еламасын, өзелеп авыру булмасын дия, һәр теләгән нәрсәләрен эшләтсәләр, соңыннан аларны гарьсез иткән вә үзләрен дә аңа кол иткән булырлар.

Балаларны итагатьле[335] вә канәгатьле булырга өйрәтмәк тугрылары ата-ана вә тәрбиячеләрнең иң артык күзәтә торган эшләредер. Балаларның күз яше әүвәл башта берәр эстәгән нәрсәләре өчен үтенүләре урынында булса да, ахырында әмер хөкемне алачагыннан балаларның һәрвакыт теләгәннәрен эшләр өчен булган елауларына каршы кызганамын диеп тә аларның әйткәннәрен эшләргә тырышканнар балаларны гарьсез итмәгә, һәр күңелләренә килгәнне эшләргә үгрәнеп, каршы булуларына сәбәп булырлар. Бер бала тиешсез бер нәрсәне сорап, я бер эшне эшләмәкче булып, эшләтмәгән өчен елый башласа, бирмәгез, эшләмәгез, куегыз, еласын, ул елаудан бер файда булмаячагын үзе дә белеп, тиешсез нәрсәләр сораудан, карышудан ваз кичсен.

Бала бер нәрсәне сорап еласа, сораган нәрсәсенең бирелмәячәген белдерергә, гарьсезлекнең начар эш булганын аңла-

---

[333] Мөхкәм – нык, төгәл, анык.
[334] Эстәү – теләү.
[335] Итагатьле – күндәм, сүз тыңлаучан.

тырга кирәк. Бирерлек бер нәрсә булса, елап туктаганнан соң бирергә вә моны да елаганы өчен түгел, туктап акыллы торганы өчен бирелгәнне сөйләргә тиештер.

11. Баланың ашый-эчә торган нәрсәләре вакытында тәртип берлә бирелсә, яңадан башка нәрсә сорарга хаҗәт калмас. Баланы сатучылардан конфет, прәннек, чикләвек кеби нәрсәләр алыр өчен акча сорарга өйрәтмәскә кирәк. Ләкин андый нәрсәләрне өйдә булдырып, аларны бөтенләй мондый нәрсәләрдән мәхрүм итмәскә дә тиеш.

12. Балаларны назлы үстермәк, һәр теләгәннәрен эшләтмәк аларны хараплыкка төшермәктер.

Балалар яхшы бер тәрбия кылынудан авыру да булмаслар, үлмәсләр дә, назлы үгрәтелгән һәр теләгәннәрен эшләтелгән балалар, ахырында теләгәннәрен тапмасалар, менә шул вакытта буылырлар, ачуларыннан үләрләр, яисә әйткәннәрен эшләтергә өйрәнгәнлекләреннән морадларын булдырыр өчен һәртөрле начар эшләрне кылудан чирканмаслар. Балаларын сөйгән ата-аналар, үзләренең мәхәббәт вә хәер хаһлыкларын[336] аларны яхшы тәрбия кылу берлә күрсәткән булырлар.

## *85 нче дәрес*
## *Баланың начар эше*

13. Бер бала бер начар эш эшләдеме, әүвәл үк ул аны белеп эшләгәнме, яисә ялгышлык берлә эшләгәнме – шуны белергә кирәк. Белми эшләгән булса, аны йөзенә ормый гафу кылмага, кылган эше зур эш булса, тиешле сүзләр берлә яңадан ул эшне кылдырмаска тырышылсын. Белеп эшләгән булса, андый нәрсәләрнең начарлыкларын акыл җитәрлек сурәттә аңлатмак, әгәр яңадан ул эш булса, җәза бирмәк кирәк. Баланы начар сүзләр берлә сүкмәк аны начар сүзләргә өйрәтүдән башка бер файда бирмәс.

14. Бер кабахәт эшләгән баланы, кабахәтне әйттермәкче булып, «Тугры сөйлә, ант ит», дия өстенә төшеп, «Әйтмәсәң

[336] Хәер хаһ – теләктәш, яхшы теләктә булу.

фәлән итәрмен, төгән итәрмен», дип куркытмак аслан[337] җаиз[338] түгелдер. Чөнки, алай булганда, бала куркуыннан ялганга ант итәргә, кабахәтен яшерер өчен тану юлына сабышып, ялганчылыкны гадәтләнергә сәбәп булыр.

15. Баланың бер хатасыннан тыяр өчен, орышкан вакытта: «Бу эшне куймасаң, сине фәлән итәрмен», – димәк яхшы түгелдер. Бәлки бу эшне эшләмәсә, үзенә никадәр яхшылыклар булачагын вә файдалар киләчәген сөйләп аңлату ляземдер.

16. Бала бер җире авыртканнан, я бер хозурсызлыктан еласа, бик тиз ярдәменә җитешмәк, вә мөмкин булса, уңайсызлыгын елый башлаганчы ук бетерергә тырышмак кирәк. Бу вакытта сөеп назландырмак файдасыздыр, чөнки ул моннан хозурланып һичбер нәрсә булмаганда да еларга гадәтләнер. Бала акыллы утырган вакытта сөелмәк һәм дә акыллы утырган өчен сөелгәнен үзенә белдермәк ляземдер.

17. Янә балаларны иң артык өйдә вә ишек алдында булган хезмәтчеләр берлә урам балалары гарьсез итәчәк булганнан, боларның бала янында кирәкмәгән нәрсәләр сөйләүләреннән вә яхшы холыклары күренмәгән балалар берлә уйнатудан сакланып, урамнарда уйнатмый, өйдә я бакчада уйнаган вакытларында да әдәп вә тәрбия даирәсендә йөрүләрен күзәтмәк аналарга лязем бурычтыр.

## *86 нчы дәрес*
## *Балаларга шул нәрсәләрне аңлатмак кирәк*

18. Балаларга иң зур мәкяфәтнең[339] зурлар тарафыннан сөйләмәк, илтифат итмәкнең гарьле вә оятлы булмак, каршылыктан, наданлыктан, кимчелекле булудан, кешене хурлаудан, көнчелектән сакланмак, сабакларына тырышмак вә башка мактаныла торган эшләре булганда гына булачагын аңлатмак кирәк. Намус вә гыйффәтнең, изге эшләрнең яхшылыгыннан, малга,

[337] Аслан – һич, һич тә.
[338] Җаиз – дөрес, яраклы.
[339] Мәкяфәт – яхшылыкка каршы эшләнгән яхшылык, бүләк.

намуска вә хокукка вә хәяткә тию кеби начар эшләрнең шәригать вә низам буенча бик каты җәзаларга мөстәхыйкъ кылып[340], вөжданның да каты газаплануына сәбәп булганын аңлатмак ляземдер. Һәркемгә яхшылык кылган адәм һәркемнән яхшылык күрер.

19. Балалар гыйлем вә мәгърифәт хасил кылулары өчен иң яхшы вә тыныч юл – уку арзусын[341] аларның йөрәкләрендә уяндыра торган ысулдыр. Адәмнең тырыш булуы өчен иң әүвәл тырышлыкны сөюе лязем булганнан әүвәл, элек үк балага укуны мәхәббәтле күрсәтергә, аннан соң укыта башларга кирәк. Гыйлем вә мәгърифәт хасил итәр өчен, башта күп мәшәкатьләр чигелсә, соңыннан үзе өчен бик күп файдалар булачагын, гыйлем вә мәгърифәт ияләренең бәхетле булып, тынычлык, рәхәтлек вә дәүләт берлә гомер иткәннәрен, аларның дәрәҗәләрен балага сөйләп күрсәтмәк тиештер.

20. Бала әлифба укый башламастан әүвәл үк, тәрбияи фикриянең гамәли кыйсеменнән дәресләр бирмәк ляземдер. Мәсәлән, бала бераз акылы җитә башлаган вакытта һәр күргән нәрсәсен беләсе килгәннән, диңгез күрсә, мотлак[342] аның нәрсә икәнен сорамый калмас. Менә шул вакытта көррәи әрыз[343] дүрт өлешеннән өч өлешен бу тозлы суның каплаганын, вә атына диңгез диелгәнен, эчендә пароходларның, каекларның ничек йөргәнен ул аңларлык ачык бер тел берлә сөйләмәк кирәк. Яңгырга, һавага, җилгә, суыкка, эссегә, хасил һәрбер нәрсәгә очраганда, баланы ялыктырмаслык бер гүзәл рәвештә кыска вә файдалы мәгълүмат бирергә, баланың фикер куәтен киңәйтергә вә зиннәтләргә тырышылсын. Балаларга уен вә йөрү арасында да шундый гыйльми дәресләр бирергә тиеш[344].

---

[340] Мөстәхыйкъ кылу – хаклы, лаеклы булу; мохтаҗ булу.

[341] Арзу – теләк.

[342] Мотлак – ничек кенә булмасын.

[343] Көррәи әрыз – җир шары; глобус.

[344] Балаларга гамәли дәресләрне үгрәтү тарикын (юлын – ред.) белер өчен «Табигать эчендә» исемле китапка мөрәҗәгать итегез (искәрмә китап авторыныкы – ред.).

21. Чисталык, сабыр вә чыдамлык, түбәнчелек вә хөрмәтнең, кунак хөрмәтләүне кирәкле вә яхшы эш икәненнән бәхәс итмәк, байлык вә мәртәбәгә, нәсел-нәсәпкә, мәгълүматка вә зурлыкка мактанып тәкәбберләнергә вә зурланырга ярамаганлыкны сөйләп мисаллар китерергә, байлык китә торган бер хәл булып, моның берлә мактанмак акыллы кешенең эше булмаган кеби, нәсел-нәсәпкә, мәгълүмат вә шөһрәткә дә мәел[345] багламак лязем булмаганын белдермәк тиештер.

Төп байлык күркәм холыклар вә фазыйләтләр[346] булып, төп зурлык та үзегездәге артыклык булганын онытмаска тиеш идеген, зураю ахмакларга махсус булган бер аерым галәмәт булганнан, түбәнчелек берлә үзегезне вә сыйфатыгызны зиннәтләмәк лязем идеген аңлату ляземдер.

22. Байлыкны тота белмәгәннәрнең зәвык сафага, исраф вә начарлыкларга талганнарның ахырында буш кул булып, фәкыйрь вә мохтаҗ калачакларын белдермәк, ике казанып бер ашамакны балаларга бик төпле бер сурәттә аңлатмак ляземдер.

23. Яңа сөйләшә башлаган балалар һәрнәрсәгә берәр исем куячаклары, мәсәлән, суны «ау», юкны «әә-әә» диячәкләре өчен, сүзләрен дөрес итеп сөйләргә, төзек вә ыспай сөйләшергә өйрәтеп, яшьләре арткан саен ялгышсыз сөйләтергә тырышмак кирәк.

[...]

## *88 нче дәрес*
## *Балага акча бирмәк*

26. Балага акча биргәндә исраф кылырлык кадәр күп, кешедән тамыгъ кылырлык[347] аз бирмәскә кирәк. Бәлки үз кирәгенә җитәрлек кадәр бирелеп, файдасыз вә кирәкмәс урыннарга тотмаска, шулай итеп аларны тамгылы булудан яки

---

[345] Мәел – кызыксыну, мәхәббәт.
[346] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш.
[347] Тамыгъ кылу – ач күзлелек, кешедә булган әйберне үзенә алырга теләү.

исраф итеп буш урыннарга тотудан тыю берлә яхшы тота белергә өйрәтмәледер.

27. Тугрылык, юмартлык, гаделлек кеби инсаният фазыйләтләренең кадер вә кыйммәтен белдертерлек изге эшләр хисен балаларда уяндырмак, фәхеш вә башка явызлыклар берлә гадәтләнгән адәмнәр берлә, вә ул тугрыда начар нәрсәләр сөйләшкәннәр берлә һичбер катнаштырмаска кирәк.

28. Ата-ана вә карендәшләренә, мөгаллим вә хәлфәсенә хөрмәт вә итагать кылмак[348], үзеннән яшьтә я гыйлемдә алда булганнарга хөрмәт кылуда кимчелек кылмаска, кечкенәләргә илтифат вә шәфкать кылмак вә һәр җирдә күркәм гадәт күрсәтмәк, ялган вә хәйлә, угрылык, гайбәт вә җүләрсемәклек вә башкалар кеби начар холыклардан сакланмак кебиләрне белдермәледер.

29. Бер бала, кирәк ир, кирәк кыз булсын, алты яки җиде яшенә җиттеме, мәктәпкә бирмәгә, анда тәрбиясенең камил булуына вә өйдә ата-ана тарафында һәртөрле хәленә күз салып, үзенең җенесенә күрә, тәрбиясенә, әлхасыйль[349] баланы камил адәм дип әйтерлек бер яхшы хәлгә китермәгә тырышмак иң кирәкле бурычтыр.

30. Балалар акны карадан аерырлык яшькә килгәч тә, һәртөрле фарызларны вә дин хөкемнәрен иҗраэ кылырга[350] кушарга кирәк. Үсүе арткан саен тәрбиясен дә арттырып, вә бу тугрыда тырышуын куәтләмәк ляземдер. Мәгыйшәт[351] өчен лязем булган нәрсәләрне мөкәммәл сурәттә хәзерләмәк, юлны белдермәк тиештер.

Балада кайсы сәнәгать яки мәсләккә[352] мәел[353] вә истигъдад[354] күренсә, аңа керештермәк кирәк. Мәсәлән, риязия-

---

[348] Итагать кылу – күндәм булу, сүз тыңлау.
[349] Әлхасыйль – җыеп әйткәндә.
[350] Иҗраэ кылу – үтәү, җиренә җиткерү.
[351] Мәгыйшәт – тереклек итү, көнкүреш, тормыш.
[352] Мәсләк – дөньяга караш, принцип.
[353] Мәел – күңел кую, мәхәббәт, кызыксыну.
[354] Истигъдад – сәләт.


дан[355] хушланган баланы язучы түгел, мөһәндис[356] ясамак, сату-алуга һәвәсле булганны тиҗарәт[357] мәктәбенә куймак ляземдер.

Һөнәрләрдән берсенә һәвәсе булса, шул юлга керештермәк, һәр яхшы мәсләктә, һәр файдалы һөнәрдә адәм җитештермәк лязем икәнен аталар, аналар, тәрбиячеләр күзәтмәк ляземдер.

Язучы кирәк булган кеби, доктор, сатучы һөнәрлеләр дә кирәкледер. Хөласа[358] уларак әйтергә мөмкиндер ки, балаларыгызны куәтле тән иясе, яхшы күңелле, яхшы холыклы, сәламәт вөҗданлы, гайрәтле, кулыннан эш килә торган, мал таба торган итәргә тырышыгыз. Шул сүзләрдән аңланыр ки, бер баланы тәрбия кылмак уйланган кадәр җиңел эш түгелдер. Бу тугрыдагы кагыйдәләрне дә сөйләп бетермәк мөмкин түгелдер. Безнең дә бу тугрыда сөйләгәннәребез бер кыска вә гомуми фикердән гыйбарәт булып калыр. Шуның өчен бала тәрбиясенең никадәр кирәклеген вә инсаният вазыйфаларының кадерен яхшы белгәннәр мөшкел булганына карамый тырышырлар. Бу тугрыда лаек булган бер белү, яхшы бер тәрбия, төпле бер сәбат[359] вә гайрәт иң куәтле бер муаффәкыять[360] коралы булыр. Яхшы ният берлә көчләрен сарыф итүчеләр, әлбәттә, ахырда Аллаһның киң рәхмәтенә муафикъ булырлар.

[355] Риязия (риязият) – математика.
[356] Мөһәндис – инженер.
[357] Тиҗарәт – сәүдә.
[358] Хөласа – кыскача әйткәндә.
[359] Сәбат – фикердә, эштә нык торучанлык, чыдамлылык, даимилек.
[360] Муаффәккыять – булганлык.

# МӨГАЛИММӘТЕЛ-БӘНАТ.
# КЫЗЛАР МӘКТӘБЕНӘ МАХСУС КЫЙРАӘТ КИТАБЫ[1]




[1] Сөләйманова Ф. Мөгаллимәтел-бәнат: Кызлар мәктәбенә махсус кыйраәт китабы. Уфа: Кәримов, Хөсәеновның матбугат ширкәте, [елы күрсәтелмәгән]. 36 б.

## Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!

### *Тәрбия вә тәгълим*

Мәгънәви тәрбия – адәмнәрнең асыл тереклегедер. Адәм балаларының үткәндәге, хәзердәге вә киләчәктәге бөтен эшләре хатыннар тарафыннан идарә ителгәнгә күрә, аларның гакыл вә фикерләре гыйлем нуры илә нурландырмага бик зур ихтыяҗ бардыр.

Хатыннар бу кеби иң бөек хезмәтләрне өсләренә йөкләдекләреннән, аларга Аллаһы Тәгалә тарафыннан йомшак күңеллелек, шәфкатьлелек кеби иң мөкатдәс сыйфатлар ихсан ителмештер[2]. Заһирдан[3] хатыннар ирләргә караганда никадәр зәгыйфь, көчсез булсалар да, мәгънәви җәһәттән булган куәт вә хезмәтләренең күп булдыгы сәбәпле, аларны хөрмәтләмәк вә олугъламак бик тиештер.

Бер милләтнең хатыннары, ул милләтнең мәгънәви тереклеген күрсәтә торган бик ачык вә гаять якты бер көзге хөкемендәдерләр. Чөнки һәрбер кавем төп тәрбияне ана кочагында алганы кеби, мәдәниятнең иң әүвәлге дәресләрен дә күркәм сыйфатлар, гүзәл тәрбия вә әхлак үгрәтүче шул ук анадан үгрәнерләр.

Яңа дөньяга килгән бер бала үзенең тереклегенә сәбәп булган шәфкатьле анасына ни дәрәҗәдә багланган вә мәел[4], мәхәббәт иткән булса, бөтен дөнья ирләре дә хатыннарга шул нисбәттә багланырга, мәел вә мәхәббәт итәргә тиешле вә бурычлыдырлар. Чөнки ана яңа дөньяга килгән баласының тереклеген, сау-сәламәт булучылыгын һәрвакыт сакларга, хезмәт вә иҗтиһад иткәне[5] кебек үк, мәгънәви тәрбиясе мөкәммәл булган бер хатын да үзенең гомерлек иптәше булган иренең сау-сәламәт вә бәхетсәгадәтле булып яшәвенә шул нисбәттә иҗтиһад итәр, вә үзенең

---

[2] Ихсан итү – ярдәм, булышлык, изгелек итү.
[3] Заһир – ачык, билгеле, күренеп торган.
[4] Мәел – күңел кую, мәхәббәт.
[5] Иҗтиһад итү – тырышу.

иренә әдасе[6] тиешле булган эшләрне әда итүдән һич баш тартмас, косурлык итмәс[7].

Гыйлем вә фазыйләтнең[8] васитәсе[9] илә ирләр никадәр зур нигъмәтләргә вә бөек дәрәҗәләргә ирешсәләр, хатыннар да бу кыймматле мәртәбә вә хәзинәдән шул нисбәттә файдалана алырлар.

Адәмнәрнең чын бәхетле вә сәгадәтле[10] булулары күркәм тәрбия, күркәм фазыйләтле хатыннар кулында булганы кебек, аларның иң заляләттә[11] вә сәфаһәттә[12] вә бәдбәхетлелектә[13] булулары да яман холыклы надан, әхлаксыз хатыннар кулындадыр.

Адәмнәрнең бәхет вә сәгадәтле булуларына сәбәп булган хатыннар «милләт вә инсаният аналары» исеме илә чакырылырга мөстәхыйкъ[14] булдыклары кебек, ахыргылары «милләт корткычлар вә ул милләтнең инкыйразга[15] йөз тотуларына сәбәпчеләр» дия исемләнергә тиешлеләрдер. Хатыннарның гыйлем вә мәгърифәт үгрәнергә булган ихтыяҗларын искә төшермәк бик тиешле эшләрдәндер.

Мәгърифәт бер яктыртучы ай шикелле булып, мәдәният бары аның яктылыгы илә генә тәрәккый[16] табып, кәмаләткә[17] ирешер. Хатыннар үзләренең гаиләләрен гыйлем вә мәгърифәт куәте илә генә яхшы һәм тиешле рәвештә идарә кыла алырлар.

Бер гаиләнең башы булган хатын балаларының мәгънәви тәрбияләренең гүзәл булмасына никадәр тырышса да, әгәр үзе гыйлем вә мәгърифәттән нихәбәр бер надан хатын булса, вазый-

---

[6] Әда итү – үтәү.
[7] Косурлык итү – кимчелек итү.
[8] Фазыйләт – артыклык, өстенлек, яхшы холыклылык.
[9] Васитә – арадашчы.
[10] Сәгадәтле – бәхетле.
[11] Заляләт – туры юлдан язу, азгынлык.
[12] Сәфаһәт – әрәм-шәрәм итү; бозыклык.
[13] Бәдбәхет – бәхетсез, явыз.
[14] Мөстәхыйкъ – хаклы, лаеклы; мохтаҗ.
[15] Инкыйраз – бетү, юкка чыгу.
[16] Тәрәккый – алга китү, прогресс.
[17] Кәмаләт – камиллек.

фасын тиешле рәвештә үтәүдән гаҗизә булыр. Гыйлем иясе вә тәдбирле[18] бер хатын йортында, гаилә арасында булган тынычлык вә татулыкны бозучы нәрсәләрне бик тиз аңлап, гыйлем вә тәдбирлелеге саясендә[19] андый эшләрнең булуларына юл калдырмас. Һәм дә үзенең гаиләсе арасында бер мәгълүматлы табиб шикелле булып, һәр эшне кирәгенчә йөртергә кулыннан килер. Ашамлык-эчемлекләр кеби хаҗәтләр, өй әсбабы вә шул гаиләдә сихәтенә лязем булган эшләргә күз-колак булып, расходын мөмкин мәртәбә аз тотарга тырышмагы кеби тереклек өчен иң кирәк булган эшләрне җиңеләйтергә өйрәнмәк йорт хуҗасы булган хатынның өстендә зур бер бурыч кеби булганлыктан, хатыннарның ничек кенә булса да үзләрен, шул бурычларын камил сурәттә эда кылырлык дәрәҗәдә гыйлем вә фазыйләт нуры илә нурландырмаклары бик лятемдер.

Хатыннар балаларының тәннәрен тышкы афәтләрдән сакламага никадәр тырышсалар, аннан да артыграк мәгънәви котларын китәрү афәтләрен китәрү хассаларын[20] саклап, әдәп вә тәрбия үгрәтмәкләре лязем. Аның өчен адәмнәрнең яшь ботак шикелле булган буйлары вә табигыятьләре, чәчкә бөреләре шикелле булган сихәт вә сәламәтлекләре бик әһәмиятле тереклек бакчасын караучы ана дигәнебез бер хатынның оста кулларына гына ачылып кәмаләткә ирешер. Гакыл вә тән җәһәтеннән камил булган бер баланы үстерә алган ана баласының бар күңелләрен ача вә юашлык бирә торган матур интизамлы[21] бакча да; тәрбия илә үстерелгән матур чәчкә шикелле кәмаләткә ирешкәнен күреп шатланыр, вә аның мондый тәрбия илә тәрбияләнүеннән үзе вә бөтен гаиләсе, хәтта бөек милләте дә чиксез күп файдалар күрер.

Баласын иренми вә армый-талмый тиешенчә тәрбияләгән бер ана киләчәк көнендә үзенә бер ярдәмче хәзерләгән, баласын игътибарсызлык вә наданлык илә үстергән ана алдагы көнендә

---

[18] Тәдбирле – алдан күрүчән.
[19] Сая – күләгә.
[20] Хасса – үзенчәлек.
[21] Интизам – тәртиплелек, кагыйдә буенча эш итү.

үзен хозурлык кыла торган, бала буласы урынга бер бәла хәзерләгән була.

Балалар, җәмгыять бәшириянең[22] берәр кирәкле әгъзалары булганга күрә, алган яхшы тәрбияләренең яки начар тәрбияләренең файда вә зарарлары, үзләренең ата-аналарына һәм дә бөтен инсаният галәменә кайтачагы билгеле бер эштер. Шуның өчен дә хатыннар балаларының үзләре артыннан берәр изге хәләф[23] булып калыр өчен дөньяга килгәнлекләрен онытмый, аларның чын адәм булулары өчен чалышмаклары[24] вә тәрбияләренә дикъкать итмәкләре ляземдер. Болай булганда, хатыннар әүвәл үзләренең мәгънәви хәлләрен төзәтеп, аналыкның никадәр мөһим вә олуг бурыч булганын фикерләмәк вә шул бурычларны гүзәл әда кылмак бик тиештер. Хосусан үзләрен шәфкать вә садакать[25] канаты астына сыендырган ирләренә бурычлы булдыкларын белеп, ирләренә гаид[26] булган вазыйфаларын иҗраэ кылырга[27] тырышмаклары беренче мәртәбәдә лязем булган эшләрдәндер.

Гыйлем вә тәрбия җәһәтеннән башка милләт хатыннарыннан бик күп дәрәҗәдә артта калдыклары хәлдә, ислам хатыннарының күңелләренең сафлыгы, вөҗданнарының яктылыгы Аллаһы Тәгаләнең үзләренә ихсан кылган[28] зур бүләкләреннән булганы өчен, һәрбер хатын үзенең шулкадәр бөек вә кадерле нигъмәтләргә мөзаһир[29] булганын уйлап, иренә, балаларына, бигрәк тә бөтен милләт, исламияткә каршы өстенә йөкләнгән мөкатдәс вазыйфаларын янә дә артыграк күркәм сурәттә үтәмәк вә шуның илә дә хатынлыкларының кадерен югары дәрәҗәгә күтәрмәкләре чын күңелдән өмет ителә вә шулай булмаклары һәм тиештер.

---

[22] Бәшир – сөендерүче, куанычлы хәбәр китерүче.
[23] Хәләф – алмаштыручы; киләчәк яңа буын.
[24] Чалышмак – тырышу.
[25] Садакать – турылык, дуслык, туры сүзлелек.
[26] Гаид – бәйләнешле.
[27] Иҗраэ кылу – үтәү, җиренә җиткерү.
[28] Ихсан кылу – ярдәм итү, булышу.
[29] Мөзаһир – ярдәм итүче.

## *Ислам хатыннарының әдәпләре*

Әдәп Аллаһы Тәгаләнең бер рәхмәтедер ки, адәмнең иманын арттырып, гомеренең озын булуына сәбәп булыр. Күңелен зурландырыр. Вә ризыгын киңәйтер. Әдәп инсанны нәфес арзуларына[30] иярүдән тыеп, һәрбер афәтләрдән саклар.

Хатыннарның иң кадерле һәм дә хөрмәтләргә тиешле булганнары – изге вә камил әдәпле булганнарыдыр. Мондый хатыннар ирләре өчен бетмәс вә төкәнмәс кыйммәтле хәзинә кебидерләр. Моның хилафында[31] булып, әдәп хариҗендә[32] йөргән хатыннар үзләренә багланган ирләре өчен түзә алмаслык бер рухани газаптыр ки, адәмне картаймас борын картайтырлар.

Иргә буйсынмак вә аның малын, җанын сакламак вә һәрвакытта аңа мәхәббәтле йөз күрсәтмәк хатыннар өчен лязем булган гыйбадәтләрдәндер. Җефетләнүдән максуд булган нәрсәләр бары ошбу эшләр илә генә табылыр.

Мондый гыйбадәтләрне үтәгән хатыннарның нәселләреннән күркәм әхлаклы вә милләткә файдалы балалар җитешер, әмма моның киресенчә булган әхлаксыз вә тәрбиясез хатыннардан, түгел милләткә файдалы адәмнәрнең җитешүе, бәлки җөмлә бәни бәшәргә[33] зарары тия торган балалар җитешер. Бәни бәшәр алардан зарар күрерләр.

Гарәп хатыннарының мәшһүрәләреннән Әсмабәнат Харис кияүгә барган вакытында ата-анасы аңарга ошбу үгетне бирмешләр.

«Сөекле кызыбыз! Тиз көннән һич күрмәгән, белмәгән вә ияләшмәгән бер кешегә зәүҗә[34] булачаксың. Син аңа туфрак бул, ул сиңа гөл булыр; син аңа чатыр бул, ул сиңа болыт булыр; син аңа җария бул, ул сиңа кол булыр; син аннан ерак булма, ул сиңа

---

[30] Арзу – теләк.
[31] Хилаф – киресе, каршы.
[32] Хариҗ – тыш, тышкы.
[33] Бәни бәшәр – адәм балалары; кешелек.
[34] Зәүҗә – хатын.

якын булыр; ул сиңа катылык кылса, син сабыр кыл, тагы ки син аңардан, ул синнән әмин булырсыңыз[35]!»

Менә, кызларым, тереклек итүнең әдәпләре ошбу рәвешле булыр. Хатынлыкның вазыйфалары шул эшләр илә хасил булыр.

Өйләнү табигый бер гадәт булган кеби, өйләнү соңында күркәм вә тату бер хәлдә тереклек итү дә Аллаһның олуг әмерләреннәндер.

Бер гаиләнең тора торган йорты бер бакча кебидер. Аның агачлары ир илә хатындыр. Бөре вә чәчәкләре дә балаларыдыр. Һавасы – яхшылык вә йомшаклыктыр. Хуш исләре – мәхәббәт илә шатлыктыр. Күге – якты булган бәхет вә икъбал[36], туфрагы да фәиз[37] вә бәрәкәт үсә торган җирдер.

Бу бакча бер мәңге булган яз шикелле булып, анда һәрвакыт тереклек вә камиллек әсәрләре табылмактадыр. Ләкин ни бар гаиләнең тора торган йорт-җирләре моның кеби тереклек вә рәхәтлек бакчасы булып җитә алмас, фәкать шундаен гаиләнекеләр генә ки, кайсылары тереклек итү юлларын белеп, яхшы торырга иҗтиһад итәләр[38].

Кайсыбер надан хатыннар, белемсезлекләре вә фикерсезлекләре сәбәпле, үзләренең файда вә зарарларын аера алмый, гомерләрен начар бер хәлдә үткәрәләр. Мондый хатыннар үзләренең кем икәнлекләрен белмәгән, дин вә вөҗданнарының хөкемнәренә каршылык күрсәткән мәхлүклардыр ки, тереклекләренең дәфтәрләре зур вакыйгалар илә туп-тулы булыр.

Ислам динендә иренә каршы әдәпкә хилаф[39] эшләрдә булган хатынына карендәшләреннән акыллы вә белекле бер кеше тарафыннан үгет вә нәсыйхәтләр бирелеп, ул хатынның хәлен төзәтергә боерадыр. Әгәр дә үгет вә нәсыйхәттә файда бирелмәсә, ата-анасы тарафыннан шелтәләнергә тиешледер.

---

[35] Әмин булу – риза булу.
[36] Икъбал – бәхет, уңыш; эшнең алга баруы.
[37] Фәиз – муллык, нигъмәт, бәрәкәт; белем.
[38] Иҗтиһад итү – тырышу.
[39] Хилаф – кире, тискәре.

Хасил ул хатынга изгелекнең хозур вә ләззәтен, явызлыкның зарарын вә куркынычлыгын аңлатканга кадәр тырышмак үзенең якыннарына инсаният наменнән иң зур бурычтыр. Хатыннарның күбесе, наданлыклары илә, эшләренең ахыры ни булачагын әүвәлдән уйлый белмиләр. Бинаән галәйһи[40] күп үкенечләргә төшәләр. Кайсыберләре исә, ачы-ачы тәҗрибәләрдән соң, ярамаган эшләреннән кайтып, гакылга утыралар.

Хатыннарның күркәм исемнәренең хөрмәтле булулары ирләрен олугламак, аларны ригая итмәк[41] илә буладыр. Чөнки дөнья, ахирәтне яратучы Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре ирләрне хатыннардан өстен итеп яратмыштыр. Кәлям кадимдә: «Ирләр хатыннар өстендә торалар!» – дия боермыштыр.

Ирнең яшерен серләрен фаш итү кадәр зур бер кабахәтлек һич тә булынмас.

Ир илә хатын яратылмышта берсе-берсенә каршы зур шатлык булырга лаеклыдыр. Шуның өчен һәрбер изге хатын күңел шатландыра торган нәрсәләрне бары иреннән генә эзләр.

Бер ананың баласын имезер өчен имезүче бер хатынга хаҗәте төшсә, изге, гакыллы, пакь нәселле, яхшы холыклы вә итагатьле[42] бер хатын эзләмәк кирәктер. Аның өчен, адәм ашаган ашына, бала да имгән сөтенә карап адәм булыр. Ана булган хатын балаларына тәрбия, итагатьлелек, канәгать вә йомшак күңеллелек өйрәтергә тиешледер.

Авызын капламый иснәмәк, кешегә каршы сеңермәк я киерелмәк, бармакларын шартлатмак, кирәк кадәрледән артык сүз сөйләмәк, бот өстенә бот куеп утырмак, юкка-барга ант итмәк, вәгъдә кылмак, кычкырып көлмәк, үзе юк вакытта бер адәмне гаепләп сөйләмәк кеби нәрсәләр ислам хатыннарының әдәпкә иң хилаф[43] вә гадәттән хариҗ[44] дия белгән эшләреннәндер.

---

[40] Бинаән галәйһи – шуңа күрә, шул сәбәпле.
[41] Ригая итү – кайгырту, олылау, хөрмәтләү.
[42] Итагатьле – күндәм, сүз тыңлаучан.
[43] Хилаф – киресе, каршы.
[44] Хариҗ – тыш, тышкы.

Әсмәгый хәзрәтләре, ифрат ямьсез вә бик вафасыз, бозык ирле бер матур хатыннан, аның иреннән күңеле хуш булып-булмавы тугрысында сорагач, хатын: «Иремнең Ходай каршында, әлбәттә, бер яраган эше бардыр ки, бәне аңа лаек вә муафикъ күрде. Яисә мин бер гөнаһ эш кылганмын дадыр, аны дөньяда ук минем гөнаһыма кәффарәт[45] кылгандыр. Аллаһның хөкеменә ничек риза булмаска кирәк!?» – дия, бик тугрылык илә җавап бирмештер.

Дөрестә, хатыннарның иң изге вә пакь-даманнары[46] ирләренең ямьсезлекләренә сабыр иткәннәре вә чыдамлылыклары илә түзгәннәредер.

Бик матур вә күркәм ислам хатыны илә ямьсез, җәфалы булган ире арасында ошбу сүзләр сөйләнмештер. Хатын:

– Өмет итәмен ки, Хак Тәгалә хәзрәте җәннәтенә һәр икебезне кертер.

Ир:

– Кайдан белдең?

Хатын:

– Сабыр иткәннәрнең урыны җәннәт әгъла[47] түгелмедер?

Ир:

– Бик яхшы. Йә, мин ничек?

Хатын:

– Сез дә минем матурлыгыма шөкер иттегез, шөкер иткәннәрнең дә урыны җәннәттер...

Хатыннар өстендә ирләренең хакы бик олуг, шуның өчен дә ирне ригая кылу[48] Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылудан саналыр.

Ислам хатыннарының кич кайткан ирләренә ачык йөз илә каршы чыгулары, олуг вә кадерле булган диннәренең боерганыннан булып, бу артык вә фазыйләтле[49] булган гыйбадәт, ислам

[45] Кәффарәт – гөнаһтан арыну өмете белән кылынган яки кылынырга тиешле эш.
[46] Пакь-даман – намуслы, гыйффәтле.
[47] Әгъла – иң югары, бик гүзәл.
[48] Ригая кылу – кайгырту, олылау, хөрмәтләү.
[49] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш.

аналарының фазыйләтле гадәтләреннән калма бер ядкарьдер. Чөнки алар кич илә йортларына кайткан ирләрен сәлам вә хуш өметлек илә каршы алып, төрле-төрле уен, көлке сүзләр вә шатлыклар илә арыганлыкларын вә күңел борчылуларын бетерергә тырышырлар. Ирләрен кайгылы күрсәләр, тиз үк аларны шатландырмага, бер билгеле табиб кеби, табигыятьләренә күрә тынычландыра торган дәва бирмәенчә, кайгыларын шатлыкка әйләндермәенчә, рәхәт тапмаслар иде.

Менә кызларым! Хатынлык, зәүҗәлек[50] шул рәвешчә булыр. Зәүҗәлекнең олуг исеме ошбудыр. Хатыннар өчен бәхет вә кадерлелек ошбу эшләр илә табылыр. Бу сүзләр безгә вә балаларыбызга гыйбрәтле дәрестер. Безләр башка милләт хатыннарына түгел, бәлки шәриф вә газиз булучы дин исламда булган хатыннарга, олуг мәртәбәле аналарга ияреп, вә боларның күркәм хәлләрен үзебезгә үрнәк итеп тотыйк! Чөнки башка милләт хатыннарының тәрбия кагыйдәләре, тереклек әдәпләре, фикерләре, хасил бөтен тормышлары бөтенләй башкадыр. Аларның тормышлары үз хәлләренә күрәдер. Без мөселманнарбыз! Бинаән гайләһи[51] ислам тәрбиясен онытмыйк! Исламча торыйк. Бәхетебезне дөньябыздан эзлик. Бу олуг булган ислам динен һәрвакыт тәкаддес[52] итеп, хөкемнәрен йөртик. Ул вакытта канәгать, күңел ныклыгы, озын фикерләрдән саклану, җенестәшләребезгә хөрмәт вә мәрхәмәт кылу хасил һәрбер изгелек вә фазыйләтләребезгә юлдаш булыр.

## *Ислам диненең артыклыгына бер үрнәк. Ана нәсыйхәте*

Кызым, сине бер иргә кияүгә бирмәкче булабыз. Зәүҗә булачаксың, адәмлеккә хезмәт итәчәксең, бәгъзе нәрсәләрне синең исеңә төшермәкче булам. Сине әхлак вә тәрбиядән өлешсез дип белгәнемнән, бу дәресләрне бирә дип уйлама. Балам! Адәм әдәп

---

[50] Зәүҗәлек – кияүдә булу; ир хатыны булу.
[51] Бинаән галәйһи – шуңа күрә, шул сәбәпле.
[52] Тәкаддес – изгелек, диндарлык.

вә тәрбия күргәнгә карап, үгет вә нәсыйхәткә юл булмаса иде, мин дә сиңа сүз сөйләмәкне артык вә кирәкмәс дип уйлар идем, ләкин нәсыйхәт, гакыллы вә тәдбирле[53] булган кешеләрне хәтеренә төшерү булып, әдәп-тәрбиядән хәбәрсезләрне юлга күндерү вә уяту булганга күрә, олуг вә кечек булсын, һәркемгә файдалыдыр. Бер адәмгә нәсыйхәт кылмак – фазыйләт юлын күрсәтүдер.

Ата-анасының байлыгына карап, бер кызның җефетләнүгә ихтыяҗы калмаса иде, шиксез син дә иргә барудан котылган булыр идең. Хәлбуки табигыятьнең кануны җефетләнүгә зур ихтыяҗ күрсәткән кеби, ирләрнең хатыннар тереклегенә, хатыннарның ирләр тереклегенә сәбәп булганы көн шикелле билгеледер. Ике күзем! Инде атаң-анаң йортыннан чыгып, башка бер йорт эченә китәсең, бер кош кеби оя алыштырасың. Китәчәк йортыңда һич йөзләрен күрмәгән, фикерләрен белмәгән вә мәсләкләрен[54] аңламаган адәмнәр бардыр. Аларның һәркаюсының – кирәк яшьләре, кирәк картлары булсын, холык вә табигатьләренә карап, мәхәббәтле йөз, ачык чырай күрсәтмәгә, һәрбер эштә ризалыкларын алмага, җария[55] кеби әмерләренә буйсынмага артык тырышырга тиешле булган эшләреңнәндерләр.

Үзеңне башкаларга сөйкемле күрсәтеп, аларның ризалыкларын алырлык бер фазыйләткә[56] хуҗа буласың килсә, хәзер сөйләячәк сүзләремне бик нык колак салып тыңла!

Җәмгыять арасында күркәм тереклек кадәр зур нигъмәт аслан[57] юктыр. Тереклек кагыйдәләрен безләргә ирләрдән артыграк үгрәнмәк вә артыграк белмәк ляземдер. Аның өчен ирләр, дөнья мәшәкатьләре арасында әйләнә-тулгана торгач, кайсы вакытта, табигатьләре алышынып холыксызланырлар, бу алышыну яхшы тормышның бозылуына сәбәп булыр. Ә күркәм холыклы вә белекле хатыннар исә мондый бозыклыкларны

[53] Тәдбирле – алдан күрүчән.
[54] Мәсләк – дөньяга караш, принцип.
[55] Җария – кол кыз.
[56] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш, яхшы сыйфат.
[57] Аслан – һич, һичбер вакытта, беркайчан да.

үзләренең уңганлыклары сәбәпле, йомшаклык илә төзәтә вә ирләренең ачуларын осталык илә китәрә алырлар.

Мәгълүматлы, белекле бер хатын иренең вә йорт җәмәгатьләренең табибәсе вә бик якын дустыдыр.

Балам! Сиңа яхшы тормышның кагыйдәләрен белдерә торган ун төрле нәрсә сөйләячәкмен. Бу ун нәрсә сине ирең илә бәхетле итеп гомереңне уздырырга сәбәп булыр. Ул ун төрле нәрсәләр ошбулардыр:

1) Ирең ашамак-эчмәк, кием-салым тугрысында сиңа нинди генә нәрсәне мәгъкуль[58] вә муафикъ күрсә дә, син аны яратып, шатлык илә кабул ит, яки аның күңеле булсын. Мин моны яратмыйм, фәлән-телән дип аның кәефен китәреп, аны борчыма.

2) Аның теләгән нәрсәләрен, үзеңә бер бурыч кеби белеп, тиз үк аны әда итәргә[59] вә җиренә җитәргә тырыш. Аның яратмаган нәрсәләренә начар күз илә карап, аннан саклан вә һәр заман аңа буйсынучы бул.

3) Пакьлек вә чисталыкка беренче мәртәбәдә тырыш. Адәм тәненең пакьлеге вөҗданының пакьлегеннән килер.

4) Йорт эчендәге тынычлык вә төзеклекне җибәрә торган һичбер эш кылма. Иреңнең күрмәге яки сизмәге илә ихласы кайтырлык нәрсәләрдән саклан ки, сиңа мәхәббәте кимеп, мәхәббәт урынына салкынлык хасил булмасын! […]

7) Иреңнең малын, җанын, игътибар вә хиссиятен, намус вә хакларын сакларга тырыш. Син аның һәрбер эшендә тереклек юлдашысың. Ул күргән зыян вә зарардан син дә өлешсез калмассың, шуның өчен иреңнең намус, игътибары да син, хакларын саклаучы да син булырга тиешлесең. Ушандак[60], исрафчан булудан – тиешсез расход тотудан бик сакланып, канәгатьле бул.

8) Синең фазыйләтле, кадерле вә бәхетле булуың ялгыз ireңә итагатьле[61] булуың илән генә булмас, бәлки синең иреңнең

[58] Мәгъкуль – яраклы, лаек, дөрес.
[59] Әда итү – үтәү.
[60] Ушандак – шулай ук.
[61] Итагатьле – күндәм, сүз тыңлаучан.

карендәшләренә, якыннарына ригая кылып[62], күркәм мөгамәләдә булынуың бигрәк тә ляземдер. Йорт эчендә күбрәк алар илә гомер итәчәксең, ирең өйдә юк вакытларда иптәшләрең алар булачаклардыр. Әгәр син алар илә начар мөгамәләдә булсаң, иреңнән күргән мәхәббәт вә илтифатны аяк астыңда таптап, гомереңнең ләззәт вә хозурын ачы вә бозылмыш итүче үзең булырсың.

9) Һичбер эштә ireңнең фикеренә хилафлык[63] кылма. Таки ул синең хакыңда дошманлык сизмәсен. Аның кайгылы вә борчулы вакытында син дә кайгылы вә борчулы бул. Ничек тә булса аны татлы сүзләрең илә юатырга, борчылуларын җиңеләйтеп, күңелен табарга кара, аның шат вә хозурлы вакытында син кайгылы булсаң, кайгы вә борчуларыңны белдерми-сиздерми йөзеңдә шатлык галәмәтләре күрсәтергә тырышып, аңа хәлеңне белдермә.

10) Зинһар ireңнең серен кешегә фаш итмә! Аларның серләре хак вә игътибарлардыр. Әгәр серләре фаш булса, кадерләре бетәр, игътибарлары китәр, кеше күзеннән төшәрләр. Ул вакытта син дә аның иза вә җәфасыннан котыла алмассың.

Синең өчен иң кирәкле булган үгет вә нәсыйхәтләр ошбулардыр, балам! Нәселебезнең кадерен вә фазыйләтен сакла! Вә безнең яхшы исем илә сөйләнүебезгә сәбәп бул, балам, ике күзем!

## *Күркәм холык*

Кызларым! Бер хатынның таккан бриллиантларыннан, энҗе вә мәрҗәннәреннән, ефәк вә хәтфә киемнәреннән дә артыграк вә матуррак бер җәүһәр бардыр ки, ул да булса күркәм холыктыр. Бармагындагы кыйммәтле йөзек, колагындагы алка, сырга[64] илә мактанып тәкәбберләнгән хатын һичбер вакытта адәм саналмас, чөнки боларның бер коры зиннәт кенә икәнлекләре, бүген бар булып, иртәгә юк булачаклары билгеледер. Бу киемнәр холкы

[62] Ригая итү – кайгырту, аңлау.
[63] Хилаф – киресе, каршы.
[64] Сырга – алка.

күркәм булмаган бер хатынга матурлык вә күркәмлек бирмәсләр. Мәгәр күркәм холык ляземдер. Ул нинди генә хатынны булса да, күркәм вә матур күрсәтә.

Бер изге вә күркәм холыклы хатын, гәрчә ул ямьсез булса да, аның йөзендә ялтыраган күркәм әхлак вә гыйффәт нуры илә адәмгә җан җылымлы, сөйкемле, бәлки дә бик матур күренер. Холкы начар булган бер хатын, гәрчә ул матурлыкта фәрештә кеби дә булсын, күзгә ямьсез, салкын күренер.

Күркәм холык адәмнәрне бер-берсенә сөйдерә торган сөйдергечтер. Мәхәббәт, яхшы тереклек, шатлык вә хозурлык, игътибар вә кадерлелек, хасил дөньяда ни төрле бәхетлелек бар исә, һәркаюсы күркәм холык илә табылыр. Холыксыз адәмне дөньяда кем сөяр? Начар холыклы адәм дөньяда ни табар? Мескен һәркөн үзе илә сугышыр. Явызлыгыннан үзен өзгәләр, сөхбәтләре[65] зарарлы булган өчен, һәркем болардан ерак китәр... Шул сәбәптәндер ки, начар холыклы адәмнәрнең һичбер кеше янында кадер вә игътибарлары булмас.

Тәҗрибә илә беленгәндер ки, берсе гүзәл холыклы, икенче берсе начар холыклы – ике кеше икесе дә бер төрле авыру, хасталык илә авырсалар, боларның күркәм холыклысы, үзенең холыклылыгы вә түземлелеге аркасында, бик тиз сихәт табар, чөнки дару аңа бик тиз тәэсир итәр. Аның табигате даруны кабул итәргә бик салихатлыдыр[66]. Икенчесе исә, түземсез вә холыксызлыгы илә, даруланудан көтелгән вә өмет ителгән файданы ала алмас.

Ислам хатыннары, башка милләт хатыннарына караганда, күркәм холыклы вә намуслыраклардыр. Яхшы вә яман холыклы хатыннар һәр милләттә булсалар да, дин кагыйдәләренә ригая кылу[67] ислам хатыннарында күбрәктер. Боларның күплеге ислам галәмендә күркәм холыклылыкка ни дәрәҗәдә ригая кылынганлыгын белдерәдер.

---

[65] Сөхбәт – аралашу, сөйләү, әңгәмә.
[66] Салихатлы – изге, сәләтле.
[67] Ригая итү – кайгырту, аңлау.

## *Игътикад*[68]

Аллаһка хәмед[69] вә шөкерләр булсын ки, мөселманнарның күңелләрен һидаять[70] нуры илә яктырткандыр. Бу һидаять нурының урыны игътикад дөреслеге, күркәм тереклек, вөждан пакьлеге кеби яхшы эшләрне җыйган кешеләрнең күңеледер.

Гарәп халкының һәркемгә бәхет кылган «тәрбия вә күркәм холыклар» ошбу өч нәрсәгә куелган исемнәрдер ки, болар исә мөселманлыкның зур шартларыннандыр. Кирәк төбе, кирәк тармаклары булсын, мәхыз[71] хикмәтле булган, мөкатдәс дөньябыздагы фарызлардыр[72]. Яурупалыларның сөйләп бетерә алмаган, үгрәтеп тә белдереп җиткерә алмаган фазыйләтләреннән[73] башка һичбер нәрсә түгелдер.

Исламнан башка милләт вә кавемнәрнең галимнәре тарафыннан мөкатдәс динебездә сөйләнелгән нәсыйхәт вә дәресләрне, кол сүзе булганы өчен кабул итмәүчеләр булса да, әлхәмдулилләһи, әһле ислам[74] арасында бу сүзләрне кабул итмәүче һичбер адәм булсын, юктыр.

Игътикад адәмне матди вә мәгънәви бәхет вә рәхәткә ирештерер. Аллаһы Тәгаләнең мондый хикмәтле әсәрләрен күргәндә, ул юктан бар кылучы Аллаһы Тәгаләне уйламый мөмкин түгелдер.

Игътикады камил булган адәм, кичнең караңгылыгын җибәрүче, айга яктылык бирүче, урманнардагы төрле агачларның, кырлардагы төрле үләннәрнең, шәһәр, авыл, сахраларда торучы адәм балаларының вә кош-корт, терлекләрнең тереклек итүләренә – аларның үсүләренә сәбәп булучы вә аларга файда бирүче кояш-

[68] Игътикад – чын күңелдән ышану, инану.
[69] Хәмед – мактау, мактап сөйләү, шөкер итү.
[70] Һидаять – туры юл эзләү теләге.
[71] Мәхыз – фәкать, саф.
[72] Фарыз – үтәлергә тиешле.
[73] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш, яхшы сыйфат.
[74] Әһле ислам – мөселманнар.

ның эсселек вә яктылыкны юктан бар итүче, мотлак[75] Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре генә икәненә ышанып, күңеле ачыларак, дәһриләр[76] кеби батыйль[77] игътикадларга тотылу бәласыннан котылыр. Ул кеше язның матурлыгын күреп хозурланган вакытта Аллаһы Тәгалә хәзрәтләренә тәсбих вә тәһлил[78] итеп, рухани зәвык вә сафаларга[79] чумар, җәй көннәрендә төрле-төрле җимешләр ашаган вакытта, важиб[80] Тәгаләгә хәмед[81] вә сәна[82] укыр. Кыш үзенең ак йөзен күрсәткәндә, аңардан да үзенә махсус бертөрле хикмәт вә гыйбрәт дәресләре күргән кеби булыр.

Менә мондый адәмнәр һәрвакыт тыныч вә рәхәт яшәрләр, кайгы-хәсрәтләре һич тә булмас.

Хөрмәтле кызларым! Дөньяда һәрнәрсә Хак Тәгаләнең теләве вә тәкъдирдә, һәм аның язмышы илә булганы өчен, адәмнәргә тәкъдиргә риза булмак, бер файдалы, яхшы эш булган вакытта, Аллаһка шөкер итмәк, зарар ирешкәндә Аллаһның ярдәмен көтеп түгел, кылмак һәр эшне Аллаһка тапшырмак кирәктер. Тәкъдирнең хөкеме үзгәрмәгәне өчен кайгырырлык бер хәл булганда, адәмгә кайгы-хәсрәт вә көенечкә бирелеп, үз-үзен борчымак вә бетермәк тиеш түгелдер. Бәлки сабыр итмәк кирәк тә, шул кайгы вә хәсрәт бирә торган нәрсәләрдән котылыр өчен, сәбәбенә керешеп, юл эзләмәк кирәктер. Чөнки артык сабырсызланып вә өметсезләнеп кайгырган адәм берничә төрле авыруларны үзенә чакырган булыр.

---

[75] Мотлак – ничек кенә булмасын.

[76] Дәһри – динсез.

[77] Батыйль – бозык, дөрес түгел, чын түгел.

[78] Тәһлил – «Ләә иләәһә илләллаһү Мөхәммәдүр-рәсүллүллааһ» дигән җөмләне әйтү.

[79] Сафа – рәхәтлек, кәеф, хозурлык, кайгысызлык.

[80] Важиб – шиксез үтәлергә тиешле.

[81] Хәмед – мактау, мактап сөйләү, шөкер итү.

[82] Сәна – мактау, мактап әйтелгән сүз.

## *Никах*

Җефетләнү – бу нинди яхшы вә нинди мәгънәле бер сүз. Табигатендә җан иясе булган мәхлукларның һәрберсе, нәсел калдыру өчен, бары бу җефетләнү кагыйдәсенә ригая кылулары[83] илә муафикъ була килгәннәрдер. Бу җефетләнү тереклекнең нур чәчә торган бер чишмәседер ки, адәмнәрнең саннарын күбәйтүгә хезмәт итүеннән башка, адәм балаларын күп явызлыклардан саклар. Бик күп тәүфикъсыз адәмнәр, өйләнгәннән соң, явыз вә бозык гадәтләрен ташлап, үзгәреп, тәүфикъка килмешләрдер. Дөньяда һичбер адәм өйләнүнең матди вә мәгънәви файдаларын белми калмас. Өйләнүдән максуд – нәфеснең начар уйлардан, начар вә бозык эшләрдән тыюлары, гаиләсенең матди вә мәгъ-нәви кирәкләрен хәзерләү, мәшругъ[84] булган шөгыльләр илә нә-сел калдырырга хезмәт итү кеби адәмлек вазыйфаларын әда итү[85] вә йөртүдер. Ибн Мәсгуд хәзрәтләре: «Ун көнлек гомерем булса да, өйләнүне телимен», – димештер. Янә бер хәдис сахихтә[86]:

«Ризыгыгызга никах илә сәгый кылыгыз[87]», – дия бирелмештер. Җефетләнүдә нинди зур нигъмәт вә бәрәкәтләнүләр булганы бу хәдис илә сабиттыр[88].

Икенче бер хәдистә: «Аллаһы Тәгалә хәзрәте өч кешегә рәхмәт әйтер: берсе сугышка киткән, икенчесе бала вә әһле гыяль[89] иясе булган, өченчесе дә бурычлы булган кешеләрдер», – дия бирелмештер.

Хакыйкатән, изге ният илә өйләнү пайдар[90], чыдамлы булып гаилә тәшкил иткәннән соң, аның бәхет вә сәгадәттә гомер итүенә сәбәп булыр.

---

[83] Ригая итү – кайгырту, аңлау.
[84] Мәшругъ – шәригать рөхсәт иткән, шәригатькә каршы килми торган.
[85] Әда итү – үтәү.
[86] Хәдис сахих – чын, дөрес, туры хәдис.
[87] Сәгый кылу – тырышу, бирелеп эшләү.
[88] Сабит – ачык; даими.
[89] Әһле гыяль – гаилә, гаилә әгъзалары.
[90] Пайдар – нык урнашкан, даими.

## *Качу – бөркәнчек*

Исламда бер кыз, җиде яшен үткәч тә, башына пәрдә куелыр. Бер кечкенә ханым зәүҗә[91] булачак, ана булачак бер кечкенә генә кыз, бер зур шатлык илә тәстир[92] (өретелү) галәменә керер. Анасына, туталарына ияреп, бөркәнчек бөркәнгән нәни кызларның кыланышлары никадәр сөйкемле вә күңелледер.

Ислам хатыннары һәрвакыт өретелмеш ирләре, ата вә туганнары, башка үзләренә мәхрүм булган якыннарыннан башка кешеләрдән мәхфузләрдер[93].

Мөхәммәд галәйһи вә сәлләм шәригате, хатыннарның өретүле булулары илә боерыр. Гакыллы ислам хатыннары бу зур әмерне үзләре Аллаһы Тәгаләнең мәңгелек нигъмәте дип белеп, хөкемен үтәмәк илә бәләнд[94] булучы ислам киемен киенмәктә булмышлардыр. Һәм мәңге киенмәктә булачаклардыр.

Тәсәттер[95] – шөкереннән гаҗиз булырлык бер ләтыйфтыр[96]. Моны ялгыз без генә түгел, хәтта мөселман булмаган хатыннар да бу якын заманнарга кадәр бер табигый эш санап, өретүле юрамышлардыр. Фәкать бу соңгы заманнарда гына өретелү гадәтен ташламышлардыр.

Качмаганлыкның нинди начар вә кайгылы эшләргә сәбәп булганы күп мәртәбә ишетелмәктәдер ки, моңа тәәссефтән[97] башка бернәрсә дә итәр хәл юктыр.

Бу сүзләребездән ислам хатыннарының һәнүз[98] кырык кат пәрдә астында аштан, көчтән, укудан мәхрүм калып, дөнья вә ахирәттән ни хәбәр буларак хайван кеби яшәмәкләре аңлашылмасын. Безнең милләтебездә ирләрдән качу, башка милләт хатын-

---

[91] Зәүҗә – ир хатыны.
[92] Тәстир – каплану, бөркәндерү.
[93] Мәхфуз – сакланган, сакланыла торган.
[94] Бәләнд – бөек, зур.
[95] Тәсәттер – каплану, бөркәнү.
[96] Ләтыйф – йомшак, гүзәл, мөгаем, нәфислек.
[97] Тәәссеф – үкенү, кайгыру.
[98] Һәнүз – һаман, һаман да.

нары кеби ирләр илә аралашу булмау бик гүзәллеге илә бәрабәр мәшругъ[99] вә мөстәхсән[100] эш булса да, ислам хатыннарының, бөтен хокукларыннан мәхрүм ителеп, хайваннар кеби ябылып торулары да бигрәк гүзәл эш түгелдер.

Занымә күрә[101], ислам хатыннары ни шәригать чикләгән чиктән чыкмый, вә ни дә үзләренең шәригать биргән хакларын югалтмый гына, әдәп вә шәригать даирәсендә хәрәкәт итеп, дин вә дөнья гыйлемнәрен тәхсил итү[102] илә инсаннар арасына кермәгә чалышмаклары[103] ляземдер.

Тәсәттернең гыйлем вә мәгърифәт үгрәнү өчен һич зарары юктыр. Чөнки исламда булган фазыйләт[104] вә мөтәфәннинләрнең[105] дәресләренә фөхул[106] рәҗелдән[107] ничә вә ничә затлар хәзер булмышлардыр. Имам Суютый хәзрәтләренең[108] йөздән артык хатыннардан дәрес алдыгы риваять ителмәктәдер. Бу фазыйләтләрнең һәм ирләр дәресенә хазирән булдыклары[109] китапларда мәшһүрдер. Һәм дә ничә вә әгъзаларның вәгазь мәҗлесләренә, ирләр хазир булып, аларның әсәрле вәгазьләреннән файда алмышлардыр.

Безнең Русия мөселманнары, качуга сылтау итеп, хатыннарын гыйлем үгрәнүдән манигъ кылып[110], үзләренең нәфесе арзуларына[111] хадим булмак кеби бер максуд өчен генә асра-

---

[99] Мәшругъ – шәригать кушкан, шәригать каршында дөрес булган эш.
[100] Мөстәхсән – күркәм, мактаулы.
[101] Заныма күрә – уйлавымча.
[102] Тәхсил итү – белем алу.
[103] Чалышмак – тырышу.
[104] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш, яхшы сыйфат.
[105] Мөтәфәннин – төрле гыйлемнәргә ия булган, энциклопедик галим.
[106] Фөхул – алдынгы, бөек, мәшһүр.
[107] Рәҗел – ир кеше.
[108] Җәлалетдин әс-Суютый (1445–1505) – атаклы мөселман дин белгече, 600 дән артык хезмәт, шул исәптән «Тәфсир әл-Җәлаләен» әсәре авторларының берсе.
[109] Хазиран булу, хазир булу – катнашу.
[110] Манигъ кылу – каршылык итү, киртә кую.
[111] Арзу – теләк.

макталардыр. Русия ислам хатыннарының хәзерге хәлләренә бер дикъкать итеп каралса, хәйрәтебездән[112] бармагыбызны тешләргә мәҗбүр булырбыз. Чөнки алар гали әл-гомум, бер гафләт[113] йокысына талмышлардыр ки. Дөньяда торудан бар максудлары – бер өстәлгә утырганда егерме төрле аш ашамак, яхшы вә кыйммәтле киемнәр киенмәк, кием-салым, күлмәк, калфак вә бриллиант вә асыл ташлар илә мактанышып, кәбирләнмәк[114], бер ирне үзләренә кол итеп, каршыларында тез чүктермәгә уйламактан, вә шуның шулай булуын тән, җаннары илә теләмәктән гыйбарәттер.

Ай Аллаһ! Без ни өчен, вә ни сәбәпле бозылдык?! Хак сүзләрне колакларыбыз ишетми, файдалы сүзләр сөйләшергә теләмибез түгелме? Тугры юлларны күзләребез күрми, һичбер нәрсәләргә гакылларыбыз ирешми!.. Хәлбуки, мәҗлесләргә җыелабыз, гали әл-гомүм, кием калыплары буларак, хайваннар кеби ашап-эчеп, өйләребезгә кайтабыз. Безнең арада ни тәгълим вә тәгаллем[115], вә ни дә тәхсил[116] хосусында сүзләр сөйләнер, вә ни дә милләткә файдалы бер эш кылыныр! Гәрчә арадан берсе мондый сүзләр сөйләмәгә керешсә дә, бер мохатәбә[117] табу ихтималы да юктыр.

Ислам хатыннарының тәхсил вә тәрбияләре өчен иҗтиһад кылмаган[118] тәкъдирдә, гыйлем вә фазыйләт[119] ияләре булачакларына аларның саф күңелләрендә урнашкан һәвәс вә изге ниятләре шаһиттер.

Безнең Русия мөселманнары, лаегынча тәрбия күрмәгәннәре сәбәпле, башка милләт хатыннарыннан артка калган булсалар да,

[112] Хәйрәт – аптырау.
[113] Гафләт – игътибарсызлык, саксызлык, ваемсызлык.
[114] Кәбирләнү – олылану, зураю.
[115] Тәгаллем – өйрәнү, белем алу.
[116] Тәхсил – уку, белем алу.
[117] Мохатәбә – кара-каршы сөйләшү.
[118] Иҗтиһад кылу – тырышу.
[119] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш, яхшы сыйфат.

Төркиядә бу тәрәккый[120] замананың биргән тәрбиясе илә файдаланган ничә вә ничә кәмаләт[121] вә фазыйләт иясе хатыннар бардыр.

Бу көндә Истанбулда гыйлем вә каләм куәсе[122] илә аерым булган ханымнардан мәкъбүлә[123] ләмган[124] – Нигяр[125], Фатыйма Галия, Әминә Сәмия[126], Фатанәт, Ләйлә, Мәһрелниса, Сания, Фәхрелниса, Фатыйма Расыйха, Гайшә, Садыйка вә башкалар кеби әдәбият тарихына алтын язулар илә язылырга тиешле булган ханымнар бардыр.

Үткән заманнарда да ничә мәгърифәтле галимәләр вә ничә мөнәүвәр[127] әл-фикер булган фазыйләтләр килмешләрдер ки, ахшам – кояш баегannan соң гашыйканә сайраулары илә тыңлап торган адәмнәрне тәмам оетып, телсез калдыра торган, моңлы тавышлы сандугач вә былбылларның тавышларыннан да әсәрлерәк вә йөрәкләрне имрәтә һәм көйдерә торган татлы вә мөлаем сүзләре илә ничә вә ничә гыйлем ияләре булган затларны хәйран калдырмышлардыр. Моның дөреслеген белер өчен, китапханәләребезне зиннәтләгән сансыз-хисапсыз төрле әсәрләр сөйләүче гуаһларыдыр[128]. Әгәр бу әсәрләрне моталәга кылынса[129], ислам хатыннарының иске заманнардан бирле гыйлем вә мәгърифәттән

[120] Тәрәккый – алга китеш, прогресс.
[121] Кәмаләт – камиллек.
[122] Куә – көч, куәт.
[123] Мәкъбүл (мәкъбүлә) – яхшы дип табылган.
[124] Ләмгъ – ялтырау, балкыш.
[125] Бу ханым дөньядан күчмеш вә кәмаләтне белгәннәр өчен бик зур кайгы булмыштыр (аңлатма китап авторыныкы – ред.). Нигяр – (1856–1918) – төрек шагыйрәсе. Үзенең эшчәнлеге өчен Солтан Абдул Хәмид II тарафыннан «Шәфкатьлелек ордены» белән бүләкләнә.
[126] Әминә Сәмия – төрек язучысы, Европада белем алган, хатын-кызның җәмгыятьтәге роленә багышланган әсәрләр авторы.
[127] Мөнәүвәр – якты.
[128] Гуаһ – шаһит.
[129] Моталәга кылу – уку, өйрәнү; мәсьәләне төрле яклап өйрәнеп, хөкем чыгару.

өлеш ала килгәннәре вә һәр заманның тәхсилдәге ихтыяҗына вә кирәклегенә карап кәмаләткә ирешүгә тырышканнары бик ачык күренәдер. Хосусан Яурупа мәдәниятен тергезгән хөрмәтле гарәп кәвеме эчендә гыйлем вә әдәпләренең камиллеге берлә бөтен дөньяга үрнәк булырлык меңнәрчә фазыйләтле хатыннар килмешләрдер. Гыйрак вә Әндәлүстә җитешкән ислам фазыйләтләре, инсаният галәмендә, фазыйл[130] вә кәмаләт күрсәтүче үрнәкләрдер.

Ислам хатыннары арасында булган хәдис күчерүчеләр, вәгазь әйтүчеләр, шагыйрә вә әдибәләр санап бетерерлек түгел.

Яурупалылар наданлык вә караңгылык эченә талган вакытларында ислам ханымнары гыйлем вә мәгърифәт илә фикерләрен нурландырмакта иделәр.

Элек заманнарда нәсваният[131] галәме, шулкадәр гыйлем вә мәгърифәт нурларына гарык булган булсалар да, бу хәзерге заманыбыздагы ислам ханымнарының хәлләрен вә гыйлем-тәрбияләрен күз алларыбызга китереп карасак, гакылларын хәйран калдырырлык дәрәҗә әүвәлгеләргә биәлкөл[132] башка улдыкларын күрербез. Ул мөхтәрәмә һәмишәләребез[133] шулкадәр кувәи гыйльмия вә фикрияләре[134] булган була торып та, ислам хатыннарының дин исламда булган бар хаклары югалмаслык сурәттә, Коръән кәрим вә хәдис шәргыйләрдән[135] катгый дәлилләр китереп, гакыйль бер-ике китап булсын, тәэлиф итеп[136], үзләреннән соң киләчәк һәмишәләренә ядкарь калдырмамышлардыр. Гаҗәбән!

Бер милләттә хатыннары никадәр билгеле, кәмаләт вә фазыйләтле[137] булсалар, ул милләт адәмнәре шулкадәр бәхетле вә шул мәртәбә галиҗәнаблек илә гомер итәрләр. Чөнки һәр мил-

---

[130] Фазыйл – өстен, яхшы.
[131] Нисван – хатын-кыз.
[132] Биәлкөл – һәммәсе beлән.
[133] Һәмишә – һаман, һәрвакыт, өзлексез.
[134] Кувәи гыйльмия вә фикри – гыйлем һәм фикерләү көче, дәрәҗәсе.
[135] Шәргый – шәригатькә караган.
[136] Тәэлиф итү – төзү, туплау.
[137] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш, яхшы сыйфат.

ләттә ирләрнең һәркөн никадәр мәшәкатьләр чигеп, мал казанмаклары хатын вә бала-чагаларының рәхәт вә шатлыкта тереклек итүләре өчендер.

Тәхсил[138] вә тәрбия күргән бер хатын моның кеби кирәкле эшләрне уйлап, иренең хозур вә рәхәтенә сәбәп була торган нәрсәләрне кылырга тырышып, вә бәхетле булуына сәбәп булган бер җан юлдашы ире булганны бик яхшы белер.

Бер хатын әүвәл ата-анасыннан да артыграк иренә якын түгелмедер? Инде ир илә хатын арасында бу кадәр якынлык булгач, юк кына сәбәпләр өчен гаиләнең тынычлык вә рәхәтенең җепләрен өзү һич дөрес түгелдер!

Наданлык сәбәпле килгән тәртипсезлек илә бер гаиләнең зур бәхет вә сәгадәт биналарын җимерү-вату ничек дөрес булсын?!

Гаилә – бу сүзнең эчендә никадәр зур мәгънәләр бардыр. Чөнки шул дөнья тереклегендә һәртөрле хәлләрнең вә һәртөрле эшләрнең булуына сәбәп булган адәм балаларының туып үсә торган урыннары – гаиләдер. Инсаниятнең мөкатдәс булган хөкемнәреннән файдаланып, бөтен милләт өчен зур хезмәтләрдә булынган адәмнәр таза, нык булучы нигез өстенә корылган гаиләләрнең тереклек җимешләредер. Бу кирәкле моталәга[139], адәмнәрнең иң гали мәсьәләләреннән булганы өчен, мәдәният каршында хатыннар таифәсенең[140] әһәмияте биргәк тә артмыштыр. Һәм һәркаюсына кечкенә вакытларыннан башлап тәхсил вә тәрбияләре мәгълүматлы булулары өчен иҗтиһад кылуның[141] тиешлелеге сөйләнмештер.

Бәгъзе бер гаилә арасында тереклекнең ләззәтләрен югалта торган начар эшләр вә күп ярамас хәлләр бардыр ки, боларның барысы да хатыннарның наданлыгыннан килмәктәләрдер. Моның кеби бәхетсезлекләрнең сәбәпләреннән булган наданлыкны

[138] Тәхсил – уку, белем алу.

[139] Моталәга – уку, өйрәнү; мәсьәләне төрле яклап өйрәнеп, хөкем чыгару.

[140] Таифә – җәмәгать, төркем.

[141] Иҗтиһад кылу – тырышу.

бетереп, кызларыбызның фикерләрен гыйлем вә гыйрфан[142], күркәм холыклар илә нурландырыр өчен тырышмак бөтен милләт исламиягә үтәве әлбәттә тиешле булган, бик зур бурычтыр.

## *Ислам хатыннарының гыйлемдә тәрәккыйләре*[143]

Тифлис казыеның кызы Хәйрия Мәгъмүмә ханым тарафыннан Истанбулда ханымнарга махсус нәшер ителә торган газета[144] иясе сәгадәтле Таһирбәк әфәнде җәнабләренә җибәрелгән мәктүб.

***Җәнаб мөхәррир!***

Шәһәребез булган Тифлистә мөселман кызлары өчен ачылган бер мәктәп тә булынмадыгыннан, Пәйгамбәребез (с.г.)нең [...] мөбарәк хәдис шәрифен[145] исемә алып, рус кызлары өчен ачылган институтка кердем. Монда, һәмишә шәригатемне тотып, милләтне саклап укымага керештем. Дәресләрем алга киткән саен, ят кавемнәр эчендә мөселманлыкның хакларын сакларга тырышадыр идем. Моннан соң мәктәпкә керәчәк кечкенә һәмширәләремә[146] батырчылык бирәчәгемне, аларга үрнәк булачагымны уйлагач, ул балаларча сөенечләрем, ул уйлаган бәхетлелекләрем эчемә сыймыйдыр иде.

Ничек мәктәптән шаһәдәтнамә алып чыктым, әүвәлге уем башка милләт хатыннары илә үз һәмширәләремнең хәлләрен чагыштырып карау булды. Без, мөселман хатыннарының, хәлләрен күргәч, елыйсым киләдер. Мөбарәк шәригатебезнең безгә биргән ул мөкатдәс рөхсәтләре урынына наданлык гадәтләренең әсире булганыбызны аңлагач, уемнан, кайгымнан ничә төннәр йокысыз калыр вә айларча тынычсыз булыр идем. Инде моннан

---

[142] Гыйрфан – аң, белем, тәрбия.
[143] Тәрәккый – алга китү, прогресс.
[144] Сүз 1895–1908 елларда Истанбулда чыккан «Hanimlara mahsus gazete» турында бара.
[145] Шәриф – кадерле, кадерләүгә лаек.
[146] Һәмширә – кыз туган.

соң, сөекле милләтемнең алдагы өмете булган балаларыбызны камил иҗтиһад[147] илә укытырга тотындым, җаным-тәнем илә ошбу эшкә керештем. Чөнки милләтемә вә адәмлегемә моннан артык бер хезмәт вә моннан артык бер бурыч күрә алмыйм. Алай да уртага чыккан мәшәкатьләр янә үз эшемне эшләргә ирек бирми иде.

Рус мәктәбенең мөдирәләре тарафыннан Кавказдагы төрле милләт хатыннарының алга китүләре тугрысында аерым-аерым языла торган үрнәк китабының мөселманнарга махсус булган кыйсемен[148] язу миңа тапшырылды.

Тугрылык, берлек, адәмлек вә мәгариф илә атказанган мөселманлыкның зурлыгын бу китапта күрсәтер өчен, мәгариф җәһәтеннән мактанырлык хәлебезне эзлидер идем. Иптәшләрем булган рус кызлары, мөселман кызларының укуларын бик арзу кылганнарына[149] күрә, язган кыйсемнең тәмамын вә соң нәтиҗәсе ни булганны көтми, укымавыбызга сәбәп шәригатебез булдыгы хикәяне табалар иде.

Иптәшләрем, Рәйнан кеби бәгъзе мөхәррирләрнең һич аңламый язылган хикәяләре илә миләрен тутырган булганнарына күрә, эшнең тугрысын аңлаганга кадәр арабызда бик каты бәхәсләр булды. Боларга булдыра алганым кадәр мөбарәк аять вә хәдисләрнең тәрҗемәләре илә мөселманлыкның кануннарын, безгә биргән рөхсәтләрен белдерер, мәгариф җәһәтеннән кырыйда калуыбызга сәбәп шәригатебез булмый, бәлки һәр милләтнең әүвәлләрендә булган кеби, искедән калма гадәт бәласе булганын сөйләр вә аңлатыр идем. Боларны ышандырыр өчен, мөселман һәмширәләремнең әсәрләрен табып күрсәтүем лязем иде.

Тәмам шул арада, караңгылыкта, урман арасыннан килеп чыккан нурлы кояш кеби чыкмыш «Ханымнарга махсус газета»гызга тугры килдем, берничә мәртәбә убып укыганнан соң, авызымнан ихтыярсыз: «Яшәгез госманлылар! Бар булыгыз, һәмширәләрем!» – дип кычкырган тавыш бүлмәмне яңгыратты.

[147] Иҗтиһад – тырышлык.
[148] Кыйсем – өлеш.
[149] Арзу кылу – теләү.

Газетагыз өчен, зур мөселман шәһәрләренең һәрберендә кызларга махсус гали мәктәпләр ачылганын ишеткәч, сөенеләчәк кадәр сөендем. Бөтен мөселманнарның мәгариф куәте илә берләшергә тырышканнары ишетелгәч, куанылачак кадәр куандым.

Сөекле хәлифәбезнең мәгарифкә булган зур һиммәтләре[150] аркасында Истанбулдан бу рәвешле таралган мәгариф нуры, ялгыз госманлы мәмләкәте тирәсен генә түгел, хәтта диңгезләрне, тау-ташларны кичеп котыпларга, Сибириягә кадәр җәелгән мөселманнарның фикерләрен нурландырмактадыр. Безнең кеби тәрбиягә, укымага миллионнар кадәр гаҗизәләргә юлбашчылык кылучы әүвәлдә газетагыздыр! Адәмлекнең тугрылыгы илә ант итеп әйтәмен ки, сезнең газетагыз госманлы матбугатына бик зур шәрәф[151] казандырмактадыр.

Хатын карендәшләребезнең, балаларыбызның тәрбиясе, йорт карау, адәмлекнең дәвамы тугрысында язылмыш мәкаләләрне кылычтан да үткен, туптан, мылтыктан да куәтлерәк санадым. Газетагыз Кавказ мөселман хатыннарын да дәртләндереп, аларның да уянуларына сәбәп булды: тиздән кызларга махсус мәктәпләрнең ачылачак хәбәре калебләргә иң зур сөенечләр, шатлыклар пәйда итте.

Газетагызны, дәгъваларыма күрә гуаһ[152] итеп, иптәшләрем булган рус кызларына күрсәткәч, могҗиза күргән кеби хәйран булып калалар, мөхәррир вә мөхәррирәләренә тәшәккерләрен[153] белдермәклегемне үтенәләр иде.

Ничә еллардан бирле тартып килдегем төһмәттән[154], бөтен һәмширәләремне наданлыктан котылырга сәбәп булган газетагызга бөтен Кавказ мөселман хатыннары исеменнән тәшәккер итәрәк, мөселманлыкның, ягъни адәмлекнең алга китүе өчен иҗтиһадымны[155] җәнабегезгә гарыз иттерәм[156].

[150] Һиммәт – тырышлык.
[151] Шәрәф – дан, дәрәҗә.
[152] Гуаһ – шаһит.
[153] Тәшәккер – рәхмәт сүзе.
[154] Төһмәт – яла ягу, гаеп тагу.
[155] Иҗтиһад – тырышлык.
[156] Гарыз итү – сөйләп яки язып җиткерү.

Газетагызның мәкаләләрен укымакта улдыгым ханым-һәмширәләремә күңелемнең иң тирән мәхәббәтен тәкъдим иттерәм.

Төрекчә әүвәл мәртәбә яздыгым бу мәкаләм, әдибә һәмширәләремнең мәкаләләрен керләндерүдән башка һич кыйммәте булмаганын белсәм дә, рус җирендә үз иҗтиһадым илә ярымйорты белдегем, төрекчә лисан[157] илә бу мәкаләмне язып күндердем, кимчелекләрен, ислам мәхәббәте наменә багышламагыгызны риҗа иттерәм[158]. Бигрәк тә, ватаннан газиз булган Истанбул шәһәреннән ерактагы исламлыкның алга китүенә гашыйка, яшь вә кайгылы күңелнең тәрҗеманы булган, шул хәсрәтнамәне гыйззәтегез илә бөтен мөселман кардәшләремә, һәмширәләремә белдерсәгез, моннан соң тагын, кыючылык итеп, газетагызның Кавказия мохбирәсе[159] сурәтендә мәктүбләремне җибәрмәгә вәгъдә кыламын.

Газетагыз һәрбер әтрафка таралдыгыннан вә ханымнарга махсус бик күп мәгълүмат бирдегеннән, шуның илә файдаланып, Баку мөселманнары да 150000 рублә җыярак, кызлар мәктәбе ачарга карар биреп, эшкә шөругъ иттеләр[160].

Тифлистә киләчәк кышта мөселман кызларына махсус рәсман бер зур мәктәп ачылачагы сөенечен хәбәр бирмәк илә фәхер иттерәм[161].

Ган Тифлис[162] фи 23 нисан[163] 1896 сәнә.
Казыйның кызы Хәйрия Мәгъмүмә

Бу мәктүбне язудан максудым – русча укучы ир вә кыз карендәшләремә үрнәк булмак өчендер. Заманыбызда русча укуның кирәклеге һич инкяр ителәчәк нәрсәләрдән түгелдер. Ләкин безнең рус мәктәпләрендә укучыларыбыз, кирәк ир, кирәк кыз

[157] Лисан – тел.
[158] Риҗа итү – сорау, үтенү, өмет итү.
[159] Мохбирә – хәбәрче, корреспондент хатын-кыз.
[160] Шөругъ итү – керешү, башлап җибәрү.
[161] Фәхер итү – мактану, горурлану.
[162] Ган Тифлис – Тифлистән.
[163] Нисан – апрель.

балалар булсын, милләтебездән тәмам аерылып, «татарлар-фәләннәр» дип милләтебезгә хәкарәт[164] күзе илә карап, нәфрәт күрсәтмәгә башлыйлар. Әгәр безнекеләр дә, Хәйрия ханым кеби, шәригатебезне тотып, милләтебезне саклау нияте илә укысалар, ят милләтләр арасында мөселманлыкның хакын сакларга тырышсалар, мөселманнардан «татар» дия качу урынына, ислам хөрмәтенә аларга ригая кылып[165], үзләрен дус вә карендәш кеби күрсәтсәләр, мәмләкәтебездә рус укуының ляземе милләтебезне саклар, хөкүмәттән хокукыбызны сорар, Государственная Дума кеби урыннарда бөтен милләт яклы сөйләшеп, хаҗәтләребезне алып бирер өчен, мөселманнарның укыган адәмнәргә ихтыяҗлары бик зур идеген йомшаклык илә аңлатсалар, укучылар илә мөселманнар арасында нәфрәт бетеп, мөселманнар да укуга күңел куярлар вә укучылар илә берлектә хәрәкәт итәрләр иде. Хәзер исә русча укучыларыбыз мөселманнарга «татар» дия карадыкларына каршы, мөселманнар да аларга «рус» дия карамакталардыр. Моның сәбәбе дә, вакыйган, русча укучыларыбызның бөтен исламлыкны онытып, дин исламда булган фарыз[166] вә важиб-ләргә[167] игътибар кылмадыкларыннандыр.

Зан гаҗизанәмчә[168], бу русча укучы яшьләребез исламиятне бөтенләй артка ташламый, динебездә булган гамәлләргә ригая кылсалар[169], җомга вә гаетләрдә, вакытлары булганда биш вакыт намазларда мәчеткә барсалар, мөселманнарга очраганда сәлам бирсәләр, вә алар илә аралашсалар, образованныйлыктан чыкмасалар кирәк?

«Өметсез шайтан», диләр. Алдагы көннәрдә, бәлки безнең дә мәктәп вә мәдрәсәләребез тәртипкә куелып, русча илә бәрабәр мөселманча да укылыр, вә яшьләребез, инсаният вә исламиятне

---

[164] Хәкарәт – хурлау, кимсетү, сүгү.
[165] Ригая итү – кайгырту, аңлау.
[166] Фарыз – үтәлергә тиешле.
[167] Важиб – тиешле, шиксез үтәлергә тиешле.
[168] Зан гаҗизанәмчә – түбәнчелек белән уйлавымча.
[169] Ригая кылу – кайгырту, олылау, хөрмәтләү.

ригая итәрәк, милләт илә бәрабәр хәрәкәт итәрләр, дия өмет ителмәктәдер. Аллаһ муафикъ әйләсен дә, шулай булсын!

## *Ислам хатыннарының киемнәре*

Ислам хатыннарының киемнәре тәмам хифзыссыйхәткә[170] муафикътыр. Хатыннар урамга чыккан вакытларында ят ирләрдән качарга тиешле булдыкларыннан, башларын, йөз вә муеннарын һәм күкрәкләрен өретү өчен шәл я чапан бөркәнерләр. Бу шәл, мәгънәви бер пәрдә булган кеби, һәрбер урын вә вакытларга махсус күкрәк томавы, тамак авыртулар, колак авыртуы вә чатнавы кеби авырулардан, ушандак[171] суык вә сыростьтан, кояш сугудан, канның мигә менүе, йөрәк сикерү, хуш китү, баш авыртуы вә башка төрле, эссе вә суыктан хасил булачак күп төрле авырулардан саклар.

Башларын өретмәгән Яурупа хатыннарының бу әйтелгән авырулардан котылмаулары билгеледер.

Ислам хатыннарының күлмәкләре илә башка төрле киемнәре дә тәннәрен яхшы саклар өчен бик муафикъ иттереп тегелмештер ки, боларның тегелүендә лязем булган кадәр киңлек илә, тәннең һичбер җире кысылып хозурсыз булмый, әгъзаларның куәтле вә сәламәт булуына ярдәм итәрлек дәрәҗәдә иркендер. Фикерләребезне күзебезгә матур күренә торган, марҗаларның тар, кысынкы киемнәренә – корсетларына, күлмәк вә кечкенә генә перчаткаларына, кысып тора торган аяк киемнәренә җибәреп карасак, болар безгә бик матур, килешле вә хуш күренәләр. Әмма шулай булсалар да, алар безнең өчен ияргергә яраклы нәрсәләр түгелдер. Бу киемнәр матурлык манерына кергән бер авырлык вә газаптыр ки, хатын диелгән ул нәзек тәннәргә зарардан башка бер нәрсә дә түгелдер.

Күз алдыгызга ике яшь кызны китерегез, берсе тәмам Яурупача, икенчесе тәмам мөселманча киенгән булсыннар, вә

[170] Хифзыссыйхәт – гигиена, сәламәтлекне саклау һәм аның юллары.
[171] Ушандак – шулай ук.

икесе дә шул киемнәрен киюне гадәт иткән булсыннар. Йә, карагыз инде, кайсы бигрәк матур? Кайсы бигрәк сау-сәламәт вә таза тәнле?

Әлбәттә, Яурупача киенгәне күрергә матур вә килешледер: биленең нечкәлегенә, үзенең асыл сымаклыгына карагыз. Корсет аны ничек тигез бер хәлгә куйган, ул тар аяк киемнәре, кечкенә перчаткалар кул-аяк кеби әгъзаларны никадәр кыскан, кечерәйткән. Хасил, шул кыз тәмам башка төрле бер сурәткә килгән. Икенче кыз гадәтчә киемнәр илә күзгә ул кадәр матур күренерлек түгел: кулларына кечкерә перчаткалар кимәс, аякларына мул гына аяк киемнәре кияр. Шул ике кызның элеккесе күзгә матур, килешле гәүдәле, күңелгә охшаулы бер кыз булып, икенчесе аңа караганда простой, килешсез бер гәүдәгә малик[172] түгелме?

Зинһар, кызларым, бу күренешкә алданмагыз, андый матур күренгәннең тышына карап ялгышмагыз, бу бер ялган күренештер ки, адәмне алдар.

Әгәр бу ике кыз илә бәрабәр чишенгән көенчә мунчада тугры килсәгез, ул тар аяк киемнәре, тар перчаткалар эчендә вә һәрвакыт кысып тора торган корсет эчендә тәненең иң кирәкле, сакларга тиешле булган әгъзалары һәрвакыт газапланып торган кыз илә гадәтенчә киемнәр кияргә гадәтләнгән кызны чагыштырып карасагыз! Кайсының тәне матур, төзек вә яхшы тәрбиядә үскәнен ул вакытта бик яхшы аңларсыз.

Яисә бу ике кызның хәлләрен һәрвакыт тикшереп торыгыз. Элеккесенең йөрәк, ашказаны, үпкә, бавыр, баш авырулары вә башка берничә төрле авырулар астында изелгәнен күрерсез. Икенчесенең исә саулыклы бер тереклеккә ирешкәнен белерсез дә, хәйран калырсыз.

Ай, тикшерүче ханым, син дә белерсең ки, бу яшь кызның авырулары кешедән йоккан авырулар булмаенча, үзен халык күзенә бик матур, бик мактаулы күрсәтер өчен киенгән тар вә кысан киемнәренең сыгынмалыкларыдыр.

Әледә ул яшьтер, матур вә күркәм киенәсе килер, ләкин җан дошманы булган авырулар башлангач, һаман артыр, бу бичара

[172] Малик – ия.

кыз да, бара-бара, авырулы вә кайгылы булып, ахырында үкенә башлар.

Яурупа мәдәниятенең кичә – көндез тырышып хәзерләнгән киемнәре нинди зарарлы эшләр тудырганны фән йөзеннән тикшереп карыйк. Төрле формаларда ясалган киемнәр тарлыклары илә күкрәкне, эчәкләрне тоташ бер тыгызлык эчендә булдырган өчен, ашказанын вә эчәге кеби аш сеңдерә торган кораллар белән кан йөрешенең башы булган йөрәкнең, сулу алырга махсус булган үпкәләрнең эшләрен читенләндереп, адәмнең тереклеге начар булуга сәбәп булуы билгеледер.

Кызларым, адәм бер фабрика кебидер. Эчендә әллә никадәр машиналар эшләр, моның бөтен кораллары бер-берсенә тоташтыр. Берсенең йөрүе акрынланса, бөтен машинаны акрынландырыр, берсе бозылса, бөтен машина туктар да, ул фабрика харап булып китәр. Моның эшләмәге коралларының иркен йөрүе илә генәдер.

Ашказанын кысу, берәр эчәгене, бавыр, үпкәсен тарландыру аларның махсус эшләрен эшләүдән тыю булып, бу хәл дәхый[173] вөҗүднең[174] башка кисәкләренең җибәрүедер.

Менә шушы уңайсызлыкларга сәбәп булган нәрсә бары шул корсет булып, башка тар киемнәрнең аерылуга ярамый торган кирәкле нәрсәседер.

Корсет бу хатыннарның йөрәк сикерүе, каты сеңгер вә эч авырулары, бала төшүе, гадәт вакытында күп чәнчүләр алулары, төсе юклыгы, бала китермәүләре вә хушлары китүе кеби авыруларга сәбәп булуы кеби бик күп зарарлары бардыр.

Хәтта корсеттан булган авырулар Америка хатыннарында түзә алмаслык дәрәҗәгә килгәннең соңында, аларның күбесе корсетларын халык җыела торган зур мәйданнарда бөтен халык күз алдында яндырып, моннан соң корсет кимәскә вәгъдә бирмешләр.

---

[173] Дәхый – тагы, тагын.
[174] Вөҗүд – гәүдә, тән.

Әдип, шагыйрь Әхмәд Мидхәт әфәнде[175] корсет хосусында: «Гомер ләзиз[176] эстәрсәң[177] ки, гомер газиз[178] эстәрсәң кимә!» – димештер. Бу нинди гаҗәп мәгънәле бер сүз!

Безнең кия торган киң вә җиңел аяк киемнәребез аякларны иркен вә рәхәт тоталар. Тар штиблет, туфли вә ботинкалар, моның хилафынча[179], һәрвакыт аякларны кысып тордыклары өчен, кашыну кеби рәхәтсезлекләргә сәбәп булырлар.

Гәрчә кием тугрысында булган ислам гадәтләребез Яурупа модасы кеби матур булмаса да, үзебез өчен бик яхшы вә һәрбер җәһәттән фән вә хикмәт кагыйдәләренә муафикътыр. Сихәт вә расход җәһәтеннән бик җиңелдер.

Без үзебезнең шул гүзәл вә камил булган гадәтләребезне ташламыйк! Күлмәкләребезне заманыбызда киелә торган манерда кимәктән, корсетсыз гына жакет вә сак[180] кеби киемнәр кимәктән зарар юктыр.

Әмма һәр яңа чыккан модага кызыкмыйк, адәмнең холкын никадәр бозганлыгын белмәгәннән килер ки, бу эш бер хатын өчен бик кимчелектер. Купшылыкны уртача киенүдән эзләмәк, гакыл вә тыйб[181] җәһәтеннән муафикъ вә бәхетнең нигезе булган икътисад җәһәтеннән дә бик ләземдер.

## ***Ярдәмнәр***

Хатыннар йомшак күңеллелек вә рәхимлелек тугрысында ирләрдән өстеннәрдер. Хосусан ислам хатыннарының йомшак күңелле вә шәфкатьле булучылыклары башка милләт хатыннарына караганда артыктыр. Ләкин ислам хатыннары, гәрчә

---

[175] Әхмәд Мидхәт – (1844–1913) – төрек язучысы, мәгърифәтче, төрек әдәбиятында кыска хикәя һәм роман жанрларына нигез салучы.
[176] Ләзиз – ләззәтле, матур.
[177] Эстәү – теләү.
[178] Газиз – кадерле, сәламәт.
[179] Хилаф – киресе, каршы.
[180] Сак – киң һәм озын хатын-кыз пальтосы.
[181] Тыйб – медицина.

аларның күңелләре милләт вә мәмләкәт һәм бала мәхәббәте илә яратылышларыннан ук туп-туры булса да, надан булдыкларыннан, шул мәхәббәтләрен вакытында вә урынлы истигъмаль итә[182] белмиләр.

Фәкыйрь, ярдәмчеләре булмаган, мохтаҗ кешеләргә яхшылык вә ярдәм кылмак, садака, зәкят[183] бирмәк ислам динендә боерылмыштыр. Бер яхшы эшкә ярдәм җәһәтеннән һиммәт[184] әсәре күрсәтмәк бик күңелле вә мактаулы эштер. Мөселманнарның олуг ярдәмнәре, изге хезмәтләре, хифзыссыйхәт[185] җәһәтеннән һәм файдалыдыр. Чөнки көн күрүе авыр булган адәмнәр, билгеле, сәламәтлекне бетерә торган эшләргә тотынырга батырчылык кылырлар. Хәлбуки зәкят вә садака начар эшләрнең юлын бикләп, аның урынына тынычлык, рәхәтлек бирер. Фәкыйрь балаларда[186] бала туу байларга караганда күбрәктер.

Бер фәкыйрьнең кызын тәрбияләп кияүгә бирү, һич кемсәсез[187] вә ярдәмгә мохтаҗ булган бер балага ана булып, ул бәхетсезне бәхетле итәргә сәбәп булудыр. Бу эш бай вә шәфкатьле хатыннар өчен эшләве бик җиңел булып та, зур бер адәмлек әсәре түгелмедер? Адәм мондый урыннарга тоткан акчасы илә ахирәт азыгы сатып алган булыр. Дөньяда байлыгын, милкен үзе илә бәрабәр ахирәткә һичбер кемсәнең алып киткәне юктыр. Безнең өчен анда кирәк булган байлык изге гамәлләрдер. Менә шуның өчен дә иман ияләре үз файдаларын изге эшләргә фида кылырлар[188].

---

182 Истигъмаль итү – куллану, файдалану, тоту.

183 Зәкят – ислам дине буенча хәлле кешеләр тарафыннан еллык керемнәренең кырыктан бере күләмендә түләнергә тиешле акча, мал.

184 Һиммәт – тырышлык.

185 Хифзыссыйхәт – гигиена, сәламәтлекне саклау һәм аның юллары.

186 Гаиләләрдә мәгънәсендә.

187 Һич кемсәсез – кешесе булмаган, ятим.

188 Фида кылу – корбан итү.

## *Тәһарәт вә намаз*

Бер ислам хатынының үз тәҗрибәсенә таянып язган мәкаләсен монда язудан максудым – ислам хатыннарына тәннәренең пакьлеге, матурлыгы өчен динебездә булган әмерләргә ияреп эш кылуда зур файдалар барлыгын исләренә төшерүдер.

Рәсүл (салләллааһү галәйһи вә сәлләм) әфәндемез хәзрәте Фатыймага мөбарәк тәннәрен су илә юмакта зур файдалар барлыгын сөйләмештер.

Исламиятнең хифзыссыйхәткә иң беренче ярдәм итә торган госелне[189] дин гамәлләре арасына кертүендә бик бөек хикмәтләр бардыр.

Хәзерге табиблар күп авыруларга каршы су илә дәва кылуны васыять кылалар. Вәхаләнки[190], безнең исламияттә ул заманнардан бирле үк мөселманнарның үз тәннәрен мунчаларда утырып, ахырдан саф су илә коенулары күркәм эшләрдән санала килгән.

[...]

Сеңер авырулары, кансызлык, тилчәлек, тиредә вә күздә булган авырулар, аш сеңмәгәнлек, ашказаны вә эчәкләр авырулары кеби хасталыклар вә зәгыйфьлекләр өчен бу рәвешле юынуларның күп файдалары бардыр. Тәннең һәркайсы җирендәге тир вә керләнү, я башкача тире алышынулары сәбәпле булган начарлыклар коену илә бетәр. Әгәр дә тән бу рәвешле пакьланмаса, кер вә тирләр тиренең су суыруы вә тән тын алу илә тәнгә кереп, күп вакытта начар хасталыкларны тудырыр. Болай булгач, тиешле вакытларда тәнне юмак – матди вә мәгънәви куәтләрне арттыра торган һәм гакылга муафикъ булган дарудыр.

[189] Госел – ислам динендә билгеле бер тәртип буенча бөтен тәнне юып коену.

[190] Вәхаләнки – чынлыкта.

Ошбу тугры сүзләр гакыл вә фикер иясе булган бер хатынның хәтеренә исламиятнең шартларыннан булган госел[191], тәһарәт вә намаз кеби иң кирәкле гамәлләрне төшерми калдырмас. Вә ул хатын да бу гамәлләрне кылудан баш тартмас!

Ислам хатыннарының динебездәге тагать[192] вә гыйбадәтләргә мәел[193] вә мәхәббәтләре намус вә вөжданнарыннан килгәндер.

Тәһарәт алу бу никадәр дә хуш вә шатландыручы бер нәрсә ки, тәһарәт алып, бит вә кулларны сөрткәч, күңелдә әллә нинди бер рәхәтлек сизелер, намаз да укып алгач, тәһарәтнең нигә бирелдеге, рәхәт вә хозуры кеби күңелдә дәхый[194] шатлык вә рәхәтлек һәм хозурлык ике өлеш артык булыр!

Хатыннар өчен гыйбадәт аларны һәртөрле бәхетлелекләрнең сәбәпләре булган күркәм тереклеккә җитәкләр өчен, Аллаһы Тәгалә тарафыннан аларга ихсан ителгән[195] бер фазылдыр[196]. Бигрәк тә тәһарәт су илә дәвалану урынына тордыгыннан, сөйләнгән авырулар өчен һәрвакыт кылына торган бер дәвадыр.

Тәннең тәһарәттә юыла торган җирләре ачык булганга күрә, һавадагы зарарлы микроблар керүгә бик уңайлы булганын, тоту, кашу илә бу авыру орлыкларының тәннең башка җирләренә ирешеп, күп начар авыруларга сәбәп булу ихтималлары бардыр.

Тәһарәттә бит вә куллар еш-еш юылып, зарарлы нәрсәләргә үрчергә ирек бирмәсләр.

Намаз тәннең һәрбер әгъзасының гадәтечә хәрәкәт илә тәрбия кылынып, куәтләнүенә сәбәп булыр. Тереклек итәр өчен лязем булган сәламәтлек куәт вә тәннең хәрәкәтләнүе илә генә камиллеккә ирешер.

---

[191] Госел – ислам динендә билгеле бер тәртип буенча бөтен тәнне юып коену.
[192] Тагать – Аллаһка гыйбадәт кылу; буйсыну.
[193] Мәел – кызыксыну, мәхәббәт.
[194] Дәхый – тагы, тагын да.
[195] Ихсан итү – ярдәм итү, булышлык итү.
[196] Фазыл – өстенлек, камиллек.

Намаз динебездә булган гыйбадәт, өстебезгә йөкләтелгән бурыч булуыннан башка, уңайлы вә һәрбер әгъзага тигез бертөрле гимнастик булып, хатыннарның ирләргә караганда күп шөгыльле вә һәрвакыт хәрәкәтле булмаган тәннәренең сихәтен саклар өчен зур файдалы бер шәйдер.

Тамырларның, итләрнең киңәюләре вә үсүләре, канның тигез йөрүе, үпкәләрнең асатлык илә сулу алулары, гәүдә вә табигатьнең төзек булуы, ашыйсы килү, аш сеңү кеби сихәт вә сәламәтлеккә сәбәп булучы нәрсәләр – барысы да намаз илә табылыр.

Бер хатын намаз васитасы[197] илә тәненең бу рәвешле куәт вә тәрбия хасил итүе илә бәрабәр, аңардан дәхый[198] мәгънәдә бик күп файдалар табар, ягъни гакыллы, тәдбирле[199], дин тотучы, изге, шәфкатьле, күркәм холыклы бер ананың бу фазыйләтләре[200] балаларына бер зур мирас вә кыйммәтле бер хәзинә хөкемендәдер.

## *Рузаның[201] матди вә мәгънәви файдалары*

Ислам хатыннары өчен югарыда сөйләнелгән ике төрле сәламәтлек чишмәләреннән башка, дәхый[202] сихәт вә сәламәтлек өчен әдасы[203] фарыз булган бер гыйбадәт бардыр ки, ул да булса рузадыр.

Нинди гакыл вә вөждан иясе булган адәм рузаның тәнгә булган файдаларын инкяр итәр икән?

Моның олуг файдаларын инкяр итеп, рузаны кабул итмәгәннәр булса, наданлыклары сәбәпле вә батыйль[204] уйда булдык-

[197] Васита – әмәл, чара.
[198] Дәхый – тагы, тагын да.
[199] Тәдбир – алдан күрүчәнлек.
[200] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш.
[201] Руза – ураза.
[202] Дәхый – тагы, тагын да.
[203] Әда – үтәү.
[204] Батыйль – бозык, дөрес түгел, чын түгел.

ларыннан булыр. Юкса, бу гамәлне тәхсин кылып[205], хәтта иярүчеләр дә юк түгелдер.

Руза, ашказаны вә эчәкләрнең түзә алмаслык авыруларына вә һәрвакыт арыганлыкларына каршы аларга бер зур рәхәтлек бирер.

Моның файдасы бик күптер: күп авыруларның, хосусан ашказаны авыруларының, башланган вакытында руза бер зур дәва урынына торыр.

Рузаның мәгънәви хасиятләре[206] һәм бик күптер:

Нәфесне ислах кылырга, аңа хаким булырга, дөньяның явызлыкларына каршы торырга, тереклекнең иң татлы ләззәтләрен сизәр өчен гыйбадәт кылырга руза тотучылык бик тиештер. Моның дөреслеген һәр ана белер вә балаларына үгрәтер.

Ислам хатыннарының дин вә мәзһәбтәге игътикадларының[207] сәбатлы[208] идекләрен күрә торып, мактанмаска мөмкин түгелдер.

Мөселман хатыннарының диндә булган мәхәббәтләре шулкадәр галидер ки, яшь кызлар бер сәбәп илә бу бурычларны, ягъни рузаны, үтәүдә кимчелек итсәләр, бу кимчелекне аслан аналарына белдермәскә тырышырлар. Чөнки бер ислам анасы, соң дәрәҗәгә кадәр балаларының дин эшләрендә пәрвайсызлык[209] итүләренә гайрәт итәр[210] һәм итәргә тиешледер.

Берничә кечкенә, надан балаларның руза тотмаганлыкларын сизгәч, аналарының шелтә вә җәза кылып, хәтта өйләреннән куып чыгарганнары күрелгәндер. Бер ислам хатыны өчен аналык мәхәббәте аның өстендә фикер вә күңеленең һәрбер ноктасында хөкем сөрә торган бер хис бардыр ки, бу да диндә булган бурычлардыр.

---

[205] Тәхсин кылу – мактау.

[206] Хасият – үзенчәлек.

[207] Игътикад – ышану, инану.

[208] Сәбат – фикердә, эштә нык торучанлык, чыдамлылык, даимилек.

[209] Пәрвайсызлык – игътибарсызлык, саксызлык.

[210] Гайрәт итү – тырышлык күрсәтү.

Инсаният тәрбиясенең нигезе диндә булган бурычлар өстенә корылыр. Әгәр бер адәм, ул никадәр тәрбия күргән булса да, диндә булган бурычларын үтәмәсә, ул камил адәм түгелдер.

Бер ана балаларына бирәчәк иң рухлы тәрбияне диндә булган бурычларны әда кылудан[211] эзләргә тиешледер. Балаларына мәхәббәте камил булган бер ана, ахырда кайда китәчәген уйлап, үзен вә сөекле балаларын дин хөкемнәрен әда итәргә ияләндермәгә ижтиһад итәр[212]. Һәркайсыбызның ахырда китәчәк урыныбыз билгеледер. Рамазан шәрифтә бик артык бәрәкәт хасил булыр. Руза тоту илә тәннең сәламәтлеге артыр. Гыйбадәтләр, тагатьләр[213] илә Ходайга якын булыныр. Зурлардан башлап, кечкенәләргә кадәр – һәркемнең йөзе көләр булып, шатлыклары артыр.

Йортларда Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләре артыр. Фәкыйрьләр мәгънә вә матдәтән[214] файдаланырлар. Байларның, фәкыйрьләрне зәкят вә садакалар илә шатландырып, вөжданнары рәхәт табар. Һәр җирдә, башка вакыттагыдан артык Коръән кәрим укылганы өчен, күңелләр фәиз[215] илә тулыр. Мөселманнарның һәрберсендә Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алыр өчен, бик ихлас илә тырышулары күренер. Исламиятнең чиксез фазыйләтләре[216] бу айда бигрәк беленер. Мөэминнәр бу айда бер-берсенә артыграк хөрмәт кылырлар.

Әлхасыйль[217], рамазан шәриф елда бер мәртәбә адәмнәрне һәртөрле изгелеккә, һәртөрле иркенлек вә бәхетлелеккә ирештерә торган мөбарәк айдыр.

Элекке заман хатыннары (борынгы хатыннар) үз көчләре илә тырышып, дөньяны идарә кылганнар. Аларга караганда без

---

[211] Әда кылу – үтәү.
[212] Ижтиһад итү – тырышу.
[213] Тагать – дини, Аллаһка гыйбадәт кылу, буйсыну.
[214] Матдәтән – матди яктан.
[215] Фәиз – белем, нигъмәт, бәрәкәт.
[216] Фазыйләт – өстенлек, яхшы эш, яхшы сыйфат.
[217] Әлхасыйль – җыеп әйткәндә.

нәрсә? Бер койты[218], ялкау вә тән тәрбияләүчебез ки: өйләрдә утырып, хәл телебез илә: без ачбыз, безне ашатыгыз, без ялангачбыз, безне киендерегез, диярбез.

Һич тә булмаса, безне болай тәрбияләп, бар кирәкләребезне җиткереп, рәхәтлек илә тереклек кылдырган ирләребезнең һәркөн безнең өчен тырышуларына шөкерана өчен, аларның бәхет вә сәгадәтләренә сәбәп булсак, үзебезгә тиешле булган эшләрне яхшы гына эшләп, аларга ярдәмче булсак, бигрәк тә яхшы булыр иде бит. Ләкин без, мәгаттәәссеф[219] табигатьнең өстебезгә йөкләгән бурычларын берәм-берәм аркабыздан ташладык. Ул эшләрне үзенә бурыч дип белә торган хатыннар бик аз калды.

Иң мөшкел вә мәшәкатьле булып та, үзе бик татлы бурычыбыз булган балаларыбызның тәрбиясенә кадәр, аларны да дөньяга килү илә имезүчеләр вә нянькалар кочагына атып, иң мөкатдәс вазыйфабызны аяк астыбызда таптадык!

Һәртөрле өстебезгә кия торган киемнәребез өчен безгә һәрвакыт магазиннар ачык вә тегүчеләребез хәзердер. Шуның өчен кисмәк, текмәк кеби эшләрдән дә үзебезне коткардык.

Иң кирәкле эшләребез булган аш пешерү вә хәзерләү кеби эшләрне дә ирләребезнең муеннарына да йөкләттек! Йорт, өйдәге хезмәтләребезне дә асрау вә хезмәтчеләр эшлиләр. Инде безгә ни калды? Бер баш-күз булу вә идарә кылу гына түгелме? Бу кадәр генә бер хезмәт тә мәдәниятнең хәзерге дәрәҗәсенчә хатыннарга күп булса кирәк. Чөнки Яурупа хатыннарын адвокатлык, докторлык, мөһәндислек[220] кеби ирләргә махсус булган хезмәтләргә керешү, шул баш-күз булып, карап эшләтү дә мөмкин булмаслык дәрәҗәгә җиткермештер.

Иртәдән кичкә кадәр йортыннан читтә булган бер кешенең, кич илә, арып-талып өенә кайттыгыннан соң, йортындагы эшләрне карап, идарә кылмагы мөмкинме соң?

[218] Койты – диалекталь сүз , «начар» мәгънәсендә.
[219] Мәгаттәәссеф – кызганычка каршы.
[220] Мөһәндислек – инженерлык.

Безгә, инсафыбызга кайтып, икърар кылырга[221] тиештер ки, хатыннарга булган хөрмәт вә яхшы исем, асылда шул борынгы заманның үз вазыйфаларын белеп, үз эшләрен үз көчләре илә эшләгән хатыннарына тиешледер. Чөнки алар үзләре вә ирләре киячәк күлмәкләренең сүсен мең төрле мәшәкать илә үзләре булдырыр, җебен үзләре эрләр, киндерен үзләре сугар, үзләре кисәр вә үзләре тегәрләр, имеш. Зиннәтләр өчен безнең кеби магазиннарда сатыла торган лента вә кружеволарга акча исраф итми, үз куллары илә челтәрләр ясарлар, имеш. Оекларының вә перчаткаларының йоннарына кадәр үзләре эрләр вә үзләре бәйләрләр, имеш. Һәм шундый мәшәкатьле эшләр арасында балаларын да үзләре карап үстереп, аналык бурычларын тәмам әда иткәннәр[222]. Шулай булса да, һәркаюсы сау вә сәламәт, вә заманыбызда бик еш очрый торган гасәби (нервный) авырулардан да ерак булганнар.

Эшләренең бу кадәр күплеге, көн күрү фикерендә булулары, безнең кеби өйдә тик ятып, юк-бар уйларга, сеңерләргә зарар бирә торган нәрсәләргә зиһен йөртергә вакыт бирмәгән. Хәзер исә, бу шөгыльләрнең юклыгы илә бәрабәр, сеңер авырулары һәркемне чорнап алган.

Бу борынгылар җөмләсеннән, үз күзем илә күреп белгән бер гаиләнең хәлен язу мөнасыйб[223] күрелде:

Әниемнең атасы Бәрәңге карьясендә[224] имам вә мөхтәсиб булып гомер кичермеш вә зәүҗәсе[225] илә берлектә яшәмешләр иде. Кечкенә вакытымда аларны бик сөя вә шуның өчен дә күбрәк вакытта алар янында торадыр идем. Бу икесе бик борынгы адәмнәр булып, искечә тереклек кылмакта иделәр. Никадәр байлыклары булса да, бер малай булсын, ялламый. Һәр эшләрен

[221] Икърар кылу – тану.
[222] Әда итү – үтәү.
[223] Мөнасыйб – яраклы.
[224] Бәрәңге карьясе – хәзерге Мари Ил Республикасының Бәрәңге районы үзәге. Татар авылы.
[225] Зәүҗә – ир хатыны.

үзләре эшлиләр иде. Йортлары зур, мәшәкатьләре күп булып та, белмим, ничектер, һәрбер эшләре тәртип илә эшләнеп, өйләре вә киемнәре гаять чиста, ашлары бик тәмле, кунаклары күп була торган иде.

Бабам таңнан күп әүвәл торып, әбиемнең кичтән мичкә өеп калдырган утынына ут кабызыр, әбием дә, һәр икесе тәһарәт алып, тәһәҗҗед[226] намазларын укыгач, озак Коръән укып утырырлар, сабак балалары килә башлагач, бабам да, билен буып, тышка чыгар да, сабакка килгән кызларга капка ачкач, үзе терлекләрне карарга китәр, әбием дә күптән морҗаларын япкан, урыннарын җыйган, идәннәрен себергән, һәрбер нәрсәсен урынына җирләштергән – үзләре менүгә, бер кунакка хәзерләнгән җылы вә күңелле бүлмә кеби, бүлмә хәзерләгән була торган иде.

Соң түбән өйгә кыз укытырга төшәр иде. Түбән өйнең миченә ягып җибәргәннән соң, йөздән артык кызга дүрт-биш җирдә борынгы шәмлек дигән нәрсәдә чыра яндырып, сабак укыта иде. Шулкадәр мәшәкать илә чыраны алыштыра-алыштыра укытып, вә шуның арасында самовар кую, күмер алу, морҗа ябу эшләре илә шөгыльләнеп тә ала иде.

Әбием заманында Бәрәңге карьясендә бер язу танымаган кыз булмый торган иде. [...]

Әбием менгәнгә кадәр бабам да терлекләрен карап кереп, икенче көнне сабак укытканда яндырыр өчен көлтә-көлтә чыра телеп хәзерләгәч вә аларны мич өсләренә кибәргә куйгач, иртә намазга мәчеткә китер, әбием дә кызларын озатып, югары өйгә менер дә намаз, зикер, тәсбих илә шөгыльләнгәннән соң, чыгып сыерларын савар, бабам кайтуына берәр тәмле нәрсә пешереп, каймак илә чәй хәзерләп куяр. Мине дә юындырып, өстемә чиста киемнәр киертеп, үзе һәм өстенә яхшы киемнәр киенеп, кияү көтә торган кыз кеби бабамны көтеп каршы алыр, тәмам хозур илә уйный-көлә чәй эчәрләр иде дә, бабам мәдрәсәгә китәр иде.

Әбием исә үзенең тегү-чигү кеби эшләрен эшләргә керешер иде. Бабамның мәдрәсәдән кайтуына аш пешерер, килгән


[226] Тәхәҗҗед – төнлә укыла торган намаз.

хатыннарга вәгазь сөйләр, чәй эчерер, әлхасыйль[227], йортта никадәр аңа тиешле эшләр бар исә, һәммәсен эшләр иде.

Бәгъзе төннәрдә мин дә уянып, бу ике җан иясенең һәр эшләрен тәртип илә эшләүләренә хәйран булып ята торган идем. Бер тавышлары, бер тыннары чыкмас, бер нәрсәне пычратмаслар, бер тиенлек нәрсәләрен юкка исраф итмәсләр, һичбер эшләрен безнең кеби бик зур эш күреп, гаугалап эшләмәсләр иде. Шулкадәр шөгыльләре күп булып та, һәр икесе сәламәт тәнлеләр, таза, симез, шат күңелле вә йомшак табигатьлеләр иде.

[227] Әлхасыйль – җыеп әйткәндә.

# *КЫЗЛАР ТӘРБИЯСЕ*[1]




[1] Сөләйманова Ф. Кызлар тәрбиясе. Икенче табгы. Оренбург: «Кәримов, Хөсәенов вә ширкәсе», [елы күрсәтелмәгән]. 32 б.

## *Кул һөнәрләре*

Яшь кызларны тәгълим вә тәрбия кылган вакытта, үзләре өчен иң кирәкле булып, һич өйрәнми калырга ярамый торган бер фән булса – ул да кул һөнәрләренең фәнедер. Иң югары мәртәбәдә булган бер белү, мәгълүмат һәм бу гадәтчә генә фәннең урынына тормаган өчен, яшь туташларның бер заман ул, бу фәнне өйрәнергә тырышулары лязем булыр, хатыннарга гына махсус булган кул һөнәрләре тереклекләре өчен дә үзләренә чиксез кирәкле булыр. Кул эшләренә оста булган фәкыйрә яшь вә эшче хатын кулларының эш белүе сәбәпле, әдәп һәм гыйффәт эчендә тереклек кыла алыр, бай фамилия ханымнары кул һөнәре аркасында бер хуш вә хозур вакыт уздырырлар вә мохтаҗларга ярдәмнәр кылып, адәмлектә булырлар.

Энә бер чын вә тугры дус булып, күп вакытта йорт халкының ярдәмчесе вә иң кыйммәтле коралларыннан берседер. Ялгыз вакытларда юаныч булып, эч пошуны бетерер, яхшы эшләр мәйданга чыгарыр вә кирәк булганда фәкыйрьлек вә аптырауга каршы торыр.

Кул һөнәрләрен кечкенә эштән башлап, тәртибе берлә өйрәнергә кирәк. Әүвәл башта бау чалудан вә озын-озын чәнчеп күкләүдән вә корама ялгаудан, ямаудан башлап, боларның һәрберсен тәмам оста эшләргә өйрәнгәннән соң, вакыты берлә сүтекләрен тегеп, ямау ямап, киемнәрнең кисәкләрен бергә күкләмәк вә бастырмак, төймә тагып, элмәк яки запонка ясамакка өйрәнеп, ахырда оек бәйләп һәм оекны ямарга өйрәнмәктер. Тегү эшләрен тәмам өйрәнеп җиткәч, тизрәк нәкышь[2] эшләре өйрәнер. Тырыш бер гаилә анасының юылган керләрен, күлмәкләрен төзәтеп, ертыкны тегеп, ямап, оек бәйләп, тишек оекларны ямап, гаилә анасына никадәр акча җыйдырачагын уйлап карагыз.

[2] Нәкышь – бизәк, рәсем, сурәт.

Кечкенә туташлар, кул һөнәренең һәркайсын эшләргә өйрәнегез. Аларны яратып эшләгез, ул эшләрдә оста булыгыз. Алар сезне һәм юатыр, һәм дә файдаландырыр.

Яшьләре үтеп, картая башлаган һәрбер хатыннар энәләрен мактап, шул моңлы сүзләрне сөйләмәгә мәҗбүрләрдер: «Энәм! Сиңа булган мәхәббәтем вә нигъмәтеңә шөкеремне һич сөйләмәк мөмкин булмаячакмы? Сиңа булган чын тәшәккерләремне[3] белдермиенчә, көннең һәр сулуында хезмәтеңне өстәп вә өмет итү берлә генә калырмынмы? Сине, үзләренә чиксез ышанылып та, ни бер көләр йөз, ни бер татлы сүз белән илтифат ителмәгән[4] дуслар кебек санармынмы? Ләкин ай, минем кыймматле хезмәтчем, тугры юлдашым, эшлекле ярдәмчем, оста коралым, рәхим итеп, миңа сөйлә ки, синнән эшләвеңне өмет иткән эшләремнән һичберсен бер генә вакытта миннән кызгандыңмы? Минем тәнемне йөрткән, мине киендергән, бүлмәмне зиннәтләгәнсең син. Кигән күлмәкләремә, яулыгымның бизәкләренә, тәрәзәдәге ак муслин[5] пәрдәләргә вә әлхасыйль[6], бик күп нәрсәләргә карыймын да, бөтен нәрсәләремнең вә бөтен кирәк-ярагым синең ярдәмең аркасында булганын күрәм мин, энәм! Кием текмәк, юрган капламак тугрысында миңа ярдәмдә булган вә кечкенә кызымның бик мактанып курчагына киерткән ал атлас күлмәгенең төрле кисәкләрен бер җиргә китереп оештырган – бар да синсең! Бик чын мәхәббәтнең вә фали[7] яры булган энә! Миңа сөйлә ки, һич тота белмәгән бармакларымның анам кулыма биргән материя кисәкләре өстенә ансатлык берлә чәнчеп үткәрә белүемне сынаган вакытларыңнан, ул сине осталык вә тизлек берлә чәнчүне һич белми, соңыннан бу турыда остарган вакытларына кадәр аларга санап бетермәслек һөнәрләреңне өйрәтеп вә ул бармакларның иясен дә үзеңә соң минутларына кадәр мин-

[3] Тәшәккер – рәхмәт.
[4] Илтифат итү – хөрмәт күрсәтү, игътибар итү.
[5] Муслин – бик юка, нәфис тукыма.
[6] Әлхасыйль – җыеп әйткәндә.
[7] Фали – бәхетле.

нәтдар[8] кылучы син түгелме?.. Имде синең аркаңда бу өйрәнгән һөнәрләрем өчен күңелемдә урнашкан чиксез мәхәббәтне саклаучы булып, сине мактаучыларның һәм иң беренчесе булачакмын, вә ни сөйләсәләр, алардан да артыграк мактауларга, мәдех[9] вә сәна[10] лаек булганыңны мактана-мактана сөйләячәкмен! Синең хакыңда хәзергә кадәр мактауларым бик аз, синең исә дусларым, җенестәшләрем каршында да кадерең бик зурдыр. Син бер юмарт нигъмәт бирүче коралсың ки, синең ярдәмең белән бичаралар карыннарын туйдырырлар, синең ярдәмең белән ничә кайгы вә көенечләр бетерелер, синең бер көн кулларда хәзер булуың никадәр файдалар вә изгелекләрне чакырып, тартып китерүен беләмсең, энәм? Бәхетсезлекләрнең ярдәмнәренә житешеп, фәкыйрьлекләрен вә мохтаҗлыкларын җибәрүеңне, вә буш вакытларны хозурлык берлә уздыртуыңны, вә эшләрне җиңеләйтергә ярдәм иткән, инсаниятькә килешерлек хезмәтләреңне сиңа сөйләмәделәрме? Ай, әгәр син аларга да акылың җитеп, язарга да көчең җитсә иде, бу турыда нинди күп башыңнан үткәннәрне яза алыр идең, синең бу хәлләреңне белгән вакыйга язучылар булса иде, алар өчен никадәр әсәрле, файдалы вакыйгаларның урынын алыр идең!».

Бер энәнең лисан[11] хәле (бер нәрсәнең рәвешеннән аңланган нәрсә): «Ай, кечкенә туташ! Син мине әүвәлге мәртәбә нәзек вә йомры кулларыңа алуың түгелме? Алай булса, минем шул сүзләремне яхшы гына тыңла! Бу дөньяда адәмнәр тырышырга тиештер. Тырышмаганнар һичбер вакыт адәм арасына керә алмасларын бер мәртәбә күз алдыңа китер, әүвәлләрдә ни хәлдә булганымны вә хәзер ни хәлгә кергәнемне күр дә, моның бер тырышу вә эш илә булганын аңла! Мин ул яратылган вакытымда

---

[8] Миннәтдар – күргән яхшылык, ярдәм өчен шатлык белдерүче, берәүнең яхшылыгы, ярдәме астында булуны танучы.
[9] Мәдех – мактау.
[10] Сәна – мактап әйтелгән сүз.
[11] Лисан – тел, сүз; сөйләве.

туфраклар астында күмелгән чи вә төзәтелмәгән бер мәгъдән[12] колчасы идем. Бар эшләре мәгъдән казып чыгару булып, атлары да мәгъдәнче аталган бер төрле адәмнәр тәмам мин торган урынга кадәр кереп, мине туфрактан чыгардылар, чистарттылар вә мине тимер ясадылар. Ут ярдәме белән вә күптөрле эшләр васитасы[13] белән мине тимер хәлемнән бер корыч чыбыкка әйләндерделәр. Ахырда икенче кешеләр бу корыч чыбыкны күп кисәкләргә бүлеп, бер башымны нечкәрттеләр вә икенче башымны яссыландырып тиштеләр; шуның өчен корыч чыбыгыннан энәгә әйләндем, җила[14] биреп ялтыратканнарыннан соң, оста булган эшләремне эшләр өчен кулдан-кулга йөри башладым. Имде уйлап кара, туташ! Әгәр тырышу эше булмаган булса иде, мин ничек мәйданга чыккан булыр идем. Әгәр тырышу нәтиҗәсез булып, мин булмаган булсам, өстеңдәге ул киемне ничек тегәрләр иде. Чөнки ул киемне өстеңә киюең минем аркамда булган кебек, аның төрле-төрле кисәкләрен бер-бергә китереп оештырган да мин».

## *Тегү эшләре*

Нәҗмия туташ әле уналты яшенә дә җитмәгәндер, бармаклары осталык вә тизлектә бер пәри бармагына охшаганлыкны сөйлиләр. Чөнки аның һичбер эшли алмаган эше юклыкны иптәш кызлары һәр көн күрәләр. Иң купшы вә иң читен киемнәрне тегүдә чиксез осталык күрсәтер, бу зур эшләрне генә түгел, бәлки гадәтчә эшләрдән, ямаулардан да ялкауланмас, гаять матур оеклар бәйләп, тишелгәннәрне бәйләп ямауга иренмәгәнлеге кеби, аларны болай энә берлә ямаудан да чирканмас. Әүвәлдә яхшы байлыклары булып, соңыннан тәкъдир Хода илә гадәттән тыш тарлыкка төшкән күп җәмәгатьле бер гаиләнең иң зур кызы

[12] Мәгъдән – металл, руда.
[13] Васита – әмәл, чара.
[14] Җила (җәлә) – ялтыравык.

булган Нәҗмия туташ үзенең гадәттән тыш осталыгы берлә йорт җәмәгатьләренең һәрберсенә йортларының хәзинәсе кеби саналмыштыр. Киемнәрне кешегә кистереп-тектергәндә, гаилә атасының кесәсеннән никадәр акчалар чыгасын белгән вә ишеткән Нәҗмия туташ бу сүзләрнең дөреслегенә ышанган өчен, киемнәрне үз кулы берлә кисеп-тегәргә өйрәнеп, керләрнең яхшы юылуын күзәтеп, аларны яхшы булдырырга тырышыр. Кыз кардәшләренә яңа киемнәр тегәр вә искергәннәрен төзәтеп, элегрәк тегелеп, модадан чыкканнарын сүтеп, модасын үзгәртеп, мода тугрысындагы эшләрнең иң нечкәләренә кадәр белер, кулының осталыгы, үзенең уңганлыгы аркасында бозып, яңа мода берлә тегеп зиннәтләгән киеме бөтенләй үзгәреп, яңа кием кеби күренер. Хатыннар киемен күзәтергә оста булдыгы кеби, атасының, ир кардәшләренең киеменә дә нәкъ бер тегүче шикелле төзәтергә кулыннан килер. Пальтоларның эчендәге атласларын алыштырыр. Яка вә җиңнәрендәге хәтфәләрен вә башка зиннәтләрен төзәтер. Төймәләрен яңартыр. Өзелгән элгәкләрне яңадан тагар, кесәләрен алыштырып, урынына яңаны куяр, кирәк булганда, бер дә белдерми ямар, кадакка эленгән җирләрне ямар. Хәтта хатын-кыз киемнәрен генә түгел, ирләр киемнәрен дә кисеп-тегеп, мәйданга куяр. Ай ул кадак эләктерүләре! Боларның мәктәп балалары өчен никадәр зарарлы булганын белсәгез, иртә берлә бер күлмәк я кием дә күренмәслек дәрәҗәдә булган кадакка эленгән бер җир ямалмаса, кичкә таба бик зур бер ертык булып күзгә чалыныр, бер перчаткада булган бер җеп өзелеп, әүвәл күренүе берлән тегелмәсә, шул кадәр тиз зураер ки, хәзер ул урыннан бармак тәмам чыга башлар. Башы сүсәргән бер оек, вакытында ямалмаса, юылганнан соң кер юа торган өйдән тубыксыз булып килер. Аякка киелеп керләнмәстән, ул аз гына мәшәкать берлә төзәтү мөмкин булып, пәрвайсызлык[15] сәбәпле, озак вә читен бер эш булганы күренер. Шуның өчен йорт эшләре караучыларның яки алдагы көндә йорт тотулары билгеле булган

---

[15] Пәрвайсызлык – тәрбиясезлек, җавапсызлык.

кечкенә кызларның мондый вак нәрсәләрне һәм күзләреннән ерак тотмый, Нәҗмия туташ кеби төзәтергә, ямарга кулларыннан килгән кадәр тырышулары ляземдер.

## *Кул эшләре өчен кирәкле булган нәрсәләр*

Кул эшләренә оста бер хатынның кирәк нәрсәләре, кораллары хәзер булырга кирәк. Аның өчен кораллар ни кадәр яхшы булса, эш шул кадәр яхшы вә ни кадәр ким вә начар булса, эш тә ул кадәр начар булып чыгар. Шуның өчен кул эшләренә оста буласы килгән яшь кызлар кулларында гаять мөкәммәл вә җиһазлы бер «өй» тартмасы булдырырга кирәк, эшли торган нәрсәләренең калынлыгына, юкалыгына күрә, энә вә җепне сайлый белергә кирәк, бу тугрыда сакланмаса, озак маташулар берлә вакытын үткәреп, эш һәм ямьсез булып чыгар. Мөкәммәл вә җиһазлы «өй» тартмасы дигәнемне өсте катифәләр[16] берлә зиннәтләнгән, эчендә кыйммәтле, нәфис нәрсәләр берлә тулы тартма дип аңланмасын, гадәтчә бер кәгазь тартма да бу эшкә ярар, бары эчендә түбәндә язачак нәрсәләр булса, бу вакытта ул тартма җиһазлы мөкәммәл «өй» тартмасы булган булыр. Әүвәле үк тартмада озынлык, кыскалык, нечкәлектә төрле-төрле вә иң яхшы энә эшли торган фабрикалар маркасында күп энәләр булырга кирәк. Яхшы сурәттән булган энәләр сынмас, убылмас, никадәр күп тотылса да, очы кәкрәймәс, энә фабрикаларында номерлар берлә тезелеп, кәгазьләргә куелыр, эре энәләр иң кечкенә номерлы, вак энәләр иң зур номерлы булыр; һәртөрле энә унике номерга бүленер, энәне эшләнә торган эшкә карап тотылу кирәк булганны, энәгә сапланган җеп бик озын, я бик кыска булмаска кирәклеген, вә куркынычлы казага сәбәп булмасын өчен, энәләрне һичбер вакыт авызга кабарга ярамаганын хөрмәтле укучы ханымнар үзләре дә белерләр. Энәләрне, тутыкмасын өчен, я энә савытына салырга, яки кирәк вакытта тиз генә

[16] Катифә – хәтфә, бәрхет.

алырга ансат булырлык итеп, катлы-катлы сукнога чәнчеп куярга кирәк. Бармакка бик таман булган берничә уймак та тартмада булырга кирәк. Җөй вә тирәк[17] үрнәкләре, өлгеләр, төрле-төрле нечкә вә юанлыкта җепләр, тирәкләр өчен төрле төстә ефәкләр, гәресләр[18] булырга кирәк. Тартмада болардан башка да кайчы, пәке, кайтан[19], шнур, лента, кием үлчи торган каеш, булавка, энә чәнчи торган мендәр, төймәләр булырга кирәк.

## *Кул эшләренә оста бер ханымның файдалы сүзләре*

Кул эшләре өйрәтүче оста ханым яшь кызларны кул һөнәрләре эшләргә кызыктырудан вә бу рәвешле аларны берничә файдалы белемлекләрдән хәбәрдар кылып, үзләре һәм башкалар өчен файдалы булуын белдерүдән яхшы һичбер нәрсә булмаганын, уйлаганын сөйләр һәм кул һөнәрләре эчендә файдалы булганнарын хаслап, зиннәткә, купшылыкка кайта торганнарыннан аерыр имеш. Кул һөнәрләре белмәгән кызларның әүвәл заманнарда һич кадере булмаганнан, вә мондый кызга һичкем кызыкмаганнан, һәр кыз кечкенә вакыттан ук аларны өйрәнергә гадәттән тыш тырышкан өчен, иске заман тәрбиясеннән калган буларак, заманыбызда һәм хәзер дә ялгыз бу һөнәрләрнең берсендә генә түгел, һәркайсында тәмам белемле карт ханымнар барлыгы ишетелмәктәдер. Менә югарыда сөйләнгән оста ханым да ул заманда, яшь вакытта ул һөнәрләрне өйрәнүдә бик югары китеп, берничә еллар кызларны өйрәткәндер. Вә бу вакытка кадәр яшь кызларны кул һөнәрләре өйрәнергә кызыктырып, кул эшләре кызларны әвәрә булу бәласеннән коткарыр өчен, тәмам бер файдалы юл икәнен дәгъва кылып әйткәндер.

Һәммә җенесебез булган барча хатыннар өчен эшне сөюдән кирәкле һичбер нәрсә юктыр. Эш күңелне шөгыльләндерер: ул

[17] Тирәк – үсемлек, чәчәк бизәкләре үрнәге.
[18] Гәрес – җептән сугылган бизәк.
[19] Кайтан – шнур, тасма.

күңелгә берничә төрле бәла вә кайгыларны уйларга ярарлык бер вакыт калдырмас, хәтта вакытны хушлык берлә уздырыр. Әвәрәлек адәмне фәкыйрьлеккә, мохтаҗлыкка төшерер вә күп кайгыларга гөрефтар кылыр[20], вә хәтта гомерне эч пошуы берлән үткәртер, әвәрәлеккә өйрәнгән кызларның әүвәлге табигатьләрен куйганнары хәзергә кадәр һич күренмәгәнлеге өчен, кызларны кечкенә вакытыннан һәртөрле эшкә ияләндерергә кирәк. Өендә утыруны белмәгән, өй эшләре берлән шөгыльләнүдән вә кул һөнәрләре кеби берничә күңелле эшләрдән ләззәт алмаган бер хатын ни эшли белер? Билгеле, ләззәтләрне читкә чыгып эзләве лязем булыр. Бер хатын кеше өчен моннан да яман, хәтәр нәрсә булырмы? Ләкин оста ханым кул һөнәрләренең һәрберсен кыз балаларга өйрәтүне бик мәслихәт күрмәс[21], нәфис эшләрне, бизәкләрне хави[22] эшләрне вә сырма вә бик нечкә эшләрне өйрәтү тиеш булмый, яки киемнәр, күлмәкләр, сөлге, эскәтер кеби нәрсәләр текмәк вә искеләрне төзәтмәк, вә гадәтчә җөйләрне яхшы итеп осталык берлә текмәк кеби төрле-төрле файдалы эшләрне эшләмәк, вә ямау ямамак, төзәтмәк, танбур[23] вә канва эшләмәк, оек бәйләмәк, киндер сукмак, кием вә сөлге, эскәтер кеби, күлмәк-ыштан кебиләрне кисмәк шикелле алдагы көндә йорт тота башлагач кирәк булачак тегешләрне белү кирәклекне белдереп, кия торган киемнәрен кечкенәдән үз куллары берлә эшләргә өйрәтеп, бер йортка хуҗа булганнан соң, андый нәрсәләрне магазиннардан зур бәһаләр берлә барып алуга яки тегүчеләргә күп акчалар биреп тектерергә гадәтләндермәскә, соң дәрәҗәдә тырышырга кушкандыр.

[20] Гөрефтар кылу – дучар булу.
[21] Мәслихәт күрү – тиеш күрү, яраклы дип табу.
[22] Хави – эченә алган.
[23] Танбур – тамбур, ыргак белән чигү.

## *Керләр вә моңа кирәкле булган шартлар*

Әүвәл заманда йорт эшләре берлә шөгыльләнә торган хатыннар өйләрендә керләр куяр өчен бер шкаф хәзерләп, бик күп керләр, йөздән артык простынялар булдырырга тырышырлар иде. Бара-бара бу гадәт җуелмыш, вә тугрысы да җуелырга тугры килмештер, чөнки мондый нәрсәләр ясар өчен кирәкле материя вә киндерләрнең хәзерге очсызлыгында ни вакытта теләсәң, теләгән кадәре сөлге, эскәтер, күлмәк, ыштан, простыня хәзерләү мөмкин булган өчен, һәр елны бу нәрсәләр кирәк кадәрле хәзерләнеп, берьюлы күп акчалар тотып, ясап, өйне кер берлә тутыруда бер файда да юктыр. Йорт эшләрен өсләренә алучылар керләрне һәрвакыт барлап, яхшы сакларга вә урыны берлә тотарга тәмам кулыннан килсен, яхшы юылмаган керләр күзгә бик ямьсез күренгән кеби, өскә һәм киясе килеп киелмәс, бу кер начар булуы өчен, ирләр һәркайсы ачуланучан булыр, яхшы юылмаган яки яхшы тәгәрәтелеп төрелмәгән кер күрсәләр, ачуларын күрсәтерләр. Тиешсез ысул белән юылган керләр тиз череп, тотмаслык бер хәлгә килер. Кер юучы хатыннар күп вакыт керләрне борып сыккан вакытта пәрвайсызлыкларыннан ертып бетерерләр. Суга хлор кеби керне яндыра торган нәрсә салырлар, шуңа күрә йорт эшләре караучы хатын мондый берничә төрле эшләрдән сакланыр өчен чын күңеленнән тырышып, керләр берлән шөгыльләнергә вә һәрбер нәрсәне күзенең алдында эшләтергә кирәк. Баш яулыклары, кул яулыгы, кисия[24] нәрсәләре, җиңнәр, якалар, пәрдәләр һәр ни вак вә яхшы керләрне я гаилә анасы үзе юса, яки карап алдында юдырса, һич читенлеге, ышандыруы булмаган бу эштән юылган нәрсәләрне саклап вә карап, юып яки юдырып, ул керне юган вакытта ертудан, начар юуудан саклаган яки сакланган булырлар. Яшь кызлар һәм иренми вак вә нечкә нәрсәләр юылган вә үтүкләнгән вакытта бу эшләрне эшләүчеләр янында булып, аларның осталыкларын бик

[24] Кисия – кисея, үтә-күренмәле юка киҗемамык тукыма.

белергә тырышып карап торсалар, яки аларга булышсалар, аз вакыт эчендә ул эшләрне өйрәнеп, алар кеби оста булырлар. Керләрне юарга хәзерләнгән вакытта берәм-берәм бик нык санап дәфтәргә язып куярга кирәк. Чөнки бер онытылу яки бер ялгышу сәбәбеннән керләр юылып киптерелгәннән вә йорт башы хатынга тапшырылып саналганнан соң, үкендерерлек орыш-талашлар чыгар. Нинди генә кер булса да булсын, төзәтерлек, ямарлык нәрсәләре күренсә, урнаштырганга кадәр карап, тикшереп, төзәтеп, ямап куярга кирәк. Төзәтерлек булган нәрсәнең төзәтүен кичектерү, икенче кер юган вакытта ул нәрсәне юып булмаслык кылу димәктер. Чөнки сәлдерәгән бер урын бик зур ертыкка әйләнгәне кеби, вә ул көенчә юылганда тотарга, я кияргә ярамаслык булган булыр. Күп гаилә аналары булыр ки: керләр юылып киптерелгәннән соң, керләрне үтүкләгән, төзәткән вә һәртөрле керләр үз урынына рәтләп, сорты берлә урнаштырылган соңында, кер комодларын яки кәрзиннәрен ачып багарак, үзләренең эшлеклелекләреннән мәгърүр булып мактанырлар ки; мондый эшләрдән мактансалар да хаклары бардыр. Чөнки төрле-төрле йорт нәрсәләренең һәрберсе үз урынына урнашылганын күрү кадәр күңелгә хуш килә торган һичбер эш уйланмас, шуның өчен һәрбер йорт иясе хатын керләрне куйган урыныннан бернәрсә алырга теләгән вакытта керләрнең астын өскә китермиенчә, мәшәкатьсез икенче керләр арасыннан табып ала белергә кирәк. Вә һәм яңа юылган керләрнең хәзер тотмастай-ларын хәзер тота торганнарының астына куеп гадәтләнергә кирәк, юасы һәм юарга бирелгән вакытта бер-берсе өстенә атылып, чуалтып бирелмәсен, һәркайсын сорты берлә булып, әүвәл вә соң юылачакларын рәт берлә берсе артыннан берсен юарга яки юдырырга кирәк.

## *Керләрне һавага кую*

Ошбу рәвешле керләрне һавага куярлар. Һавага кую керләрне бик агартыр.

Керләрне түбен борау берлә тишекләгән кисмәккә яки кәрзинкәгә берәм-берәм, керлеләрен аска, чисталарын өскә куйганнан соң, кисмәкне өсте ачык өч аяклы бер эскәмия өстенә куеп, астына ләгән куеп, өстенә капчык киндере кеби юан киндер ябылып, бу киндернең өстенә керләрнең һәркайсына җитәрлек чамада көл иләп салыныр, өстенә ябылган киндерне кисмәкнең авызын бәйләп, көлнең өстеннән акрын-акрын җылы су салыныр. Бу су керләр арасыннан үтеп, тишекләрдән ләгәнгә агар, бу аккан суны алып, җылытып көлнең өстенә янә салыныр, кат-кат шулай салынып, көлле су керләрнең арасыннан үтә-үтә, кер тәмам агарып, таплары бетәр. Һава өчен су гадәтчә генә җылы «бу» булырга кирәк. Кирәк һава ясар өчен, кирәк кер юар өчен, суның кер юарга яраклы булганын белергә кирәк. Суның яраклы булганы сабынның күбекләнүе берлә билгеле булыр, күбекләнмәсә, ул су кер юарга ярамас. Инеш, елга, чишмә суларында бу хасият булса да, иң яхшысы яңгыр суыдыр. Кое сулары кер юарга яхшы түгелдер. Ләкин керне синкеләү өчен кое сулары тотылыр. Чөнки кое суы корычлы булганнан, буяуны кергә сеңдерер.

Бу заман кер юар өчен көл истигъмаль киленү[25], онытылу дәрәҗәсенә килгәндер, кер юучылар көл урынына сода тотканлыктан, керләрнең чыдамсыз булуы тәәссеф[26] берлән күренмәктәдер, яки бер манердан буларак керләрне казанда кайнатып, пар берлән бер төрле һава ясый башламышлар. Моның манеры исә керләрне бер ләгәнгә берәм-берәм урнаштырып, өстенә суык селте яки суык содалы су салып чылатканнан соң, иртәгесен бер махсус казанга куеп, астына ягып кайнатылыр. Кайнаган вакытта керләрнең майлы матдәләре судагы сода яки селте берлә кушылып, сабын кеби күбекләнәрәк, керләрне бетереп агартыр вә бу ике манерның кайсы берлә булса да, һава ясап беткәннән соң, керләрне сабын берлә яхшылап юылыр, һава ясарга яки керләрне юарга башламастан әүвәл юкалык-калынлык, эрелек-ваклык,

[25] Истигъмаль килү – кулланылу, файдаланылу, тотылу.
[26] Тәәссеф – үкенү, кайгыру.

аклык-төслелек, керлелек җәһәтеннән керләр берничә төрлегә аерылганнан соң, эшкә башламак вә һәрбер төрлесе аерым-аерым үз алдына юылырга кирәк. Әгәр аермый, ничек тугры килсә шулай катыштырылып, кайнатылып юылса, бик керле булганнарының керле сулары, керләре икенче чиста керләргә чыгып, аларның әүвәлгедән дә бигрәк керле булуына сәбәп бирелгән булыр. Ак кердән башка төсле вә буяулы керләр һичбер вакыт һавага куярга ярамас һәм ак керләр берлә катыштырылмас.

## *Сабын берлә кер юмак*

Әүвәлдә язылганча, керләр берничә төрлегә аерылыр. Һәртөрлесе аерым-аерым юылыр; кер юарга керешмәстән әүвәл, бер кисмәккә яртыдан югарырак бик кайнар су сулып, өстен каплап куелыр вә суны хәзерләр, хәзерләгәч тә керләрне берәм-берәм чылатып, астына-өстенә тигезләп сабын сөртеп юылыр вә керле, таплы җирләрне бик яхшы, таплары беткәнче уып, сыкканнан соң, баягы кайнар суга салыныр, керләрне берәм-берәм уып, кайнар суга салганнан соң, ике-өч катлы киндер берлә кисмәк авызы капланып, иртәгә кадәр торыр, иртәгесен тәкрар[27] су кайнатып кисмәктә керләр берәм-берәм алынып чайкалганнан соң, янә өстенә-астына сабын сөртеп уылыр. Моннан соң керләр сабынлы көенә бөкләнеп, янә кисмәккә кайнар су эченә берсе өстенә берсе тезелер, моннан дәхый[28] керләр берәм-берәм алынып сыгылыр. Бер казанның яртысына кадәр су салынып, кер юганнан калган сабын кисәкләрен турап, бер кечкенә кастрюльдә эретеп, казанга салыныр, суы күбекләнгәннән соң, баягы керләрне салып, егерме минут кайнатылыр. Соңрак берәм-берәм казаннан алып, янә сабын берлә юганнан соң, чайкалып, бик яхшы сыгылып, синкеләргә тиешле булганнары синкеләнеп, селкеп, җыерыкларын бетереп, җилгә яки кояшка кибәргә

[27] Тәкрар – кабат.
[28] Дәхый – тагы, тагын да.

куелыр. Менә бу рәвешле юылган керләр гаять ак вә чиста булыр, төсле керләр дә ак керләр кеби юылса да, болар бик эссе су берлән юылып, һич кайнатырга ярамас, уңа торган ситса яки йон нәрсәләр суда һич торгызмый, тиз генә салкын суда сабын берлә юып, бик тиз чайкарга кирәк. Һичбер вакытта ике төрлесен бергә куярга ярамас. Аерым-аерым куеп чайкарга, уңа торган нәрсәләрне бер уч тоз салынган суда манганнан соң, чайкарга кирәк, төсле оеклар юылганнан соң, серкә катыштырылган суда манып чайкалыныр. Керне синкеләмәктә синкенең иң яхшысын сайларга кирәк. Ике кат киндергә төйнәп, вак-вак төеннәр ясарга, керләрне буяганнан соң, бу төеннәрне киптерергә кирәк, буяу бозылмый кибеп, икенче манарга хәзер булып торыр. Кер синкеләсе суны теләгән кадәр кубакта вә кирәк бер төстә булдырыр өчен, буяулы төеннәрнең берсен кирәк кадәрле суның эчендә сыгылып, су керсез булырлык төскә кергәннән соң, керләрне бераз манылыр. Һәркайсы бер төстә булсын өчен, арада беренә буяулы төенне сыгылыр. Синкеләнгән керләр тиз үк сыгылып, бауларга элеп киптерелер. Әгәр сыгылганнан соң эленми озак торса яки сыгылып җитми калса, кердә буй-буй сызыклар булып, ямьсез булып кибәр. Керне синкеләмәстән әүвәл, хәзерләнгән суга бер чүпрәк манып, төсен тәҗрибә кылып карау лязем булыр.

## *Фланельләр юмак*

Фланельләрне юарга ярамас, юылса, төкләре коелып төшәр һәм бик ямьсез булып кадере китәр. Фланельләр сабынлы җылы суда, өстенә сабын сөртелеп, кылдан ясалган щетка берлә бик тигезләп щеткаланыр. Әгәр бик керле булса, бераз суда салыныр. Фланельләр саф суда чылатылса, каты булыр, йомшаклыкларын саклар өчен сабынлы суда юарга кирәк. Фланельләрне он берлән һәм юылыр. Фланельләрне он берлә юарга эстәленсә[29], өч кашык

---

[29] Эстәү – теләү.

онны ике литр сабынлы суда изеп, болгатарак кайнатылыр. Боламык кеби бер нәрсә булыр. Моның яртысы эссе көенчә фланельнең өстенә тәмам сеңгәнче, кул берлән ышкып сөртелер, калган яртысының өстенә кайнар су салынып болгатканнан соң, сабын сөртелеп, щеткалап юып, чайкап киптерелер. Фланельләрне бәрәңге берлән юарга эстәленсә, бераз бәрәңгене әрчеп изеленгәннән соң, аз гына сабынлы су берлән басылып, каты бертөрле камыр ясалыр, бу камыр сабын урынына тотылыр. Фланельне әүвәл эссе суга куеп, бәрәңге сабыны сөртелеп, щетка берлә щеткалап юылыр, янә гаять эссе суга манып чайкаганнан соң, суык суда юылып киптерелер. Һәрбер йон материаллар һәм ошбу манерга йомшак вә ялтыравыклы булып, әүвәлге төсләрен һич югалтмаслар.

[…]

## *Үтүкчелек, крахмалчылык*

Керләр кибеп җыелганнан вә җыерылмас өчен төрелгәннән соң, аларның төрелгәннәрен сүтеп, дымлы көенчә яки крахмалга манып, өсләреннән кызган үтүк берлә үтүкләп, керләрне ялтыратып җыерыкларын төзәтүче хатынга үтүкче, крахмалчы хатын диярләр. Үтүкче хатынның эше ялгыз керләрне үтүкләү генә түгелдер. Керләрнең ялтыратырга, ашландырырга тиешлеләре өчен крахмал хәзерләвен дә белүе ляземдер. Шуның өчен үтүкчелек фәне крахмалны изеп, куесын-сыегын белгәннән соң, керне манып үтүкләнгән вакытта бер чите ялтыравыклы, икенче чите тонык, бер чите каты, икенче чите йомшак яки бер чите гаять шома, икенче чите бөрешкән һичбер урын калдырмый, һәрбер җирне бертөсле итеп, осталык берлә үтүкләүдән гыйбарәт бер нечкә фәндер.

Имде крахмалны ничек изәргә кирәклекне сөйләү кызлар өчен бик зур файда булачагыннан, аларга түбәндә язылган шул берничә юллардан гыйбарәт булган сүзләрне белергә тырышып

укулары риҗа ителер[30]. Крахмалга манган керләр үтүкләнгән вакытта өсләрендә һичбер җыерык калдырмый карап үтүкләргә кирәк. Әгәр җыерыклар калса, яңадан крахмалга манмак вә эшкә яңадан тотынмак кирәк булыр.

*Гадәтчә крахмал.*

Бер касәгә ике я өч кашык крахмал салынып, өстенә аз гына суык су салынып, бик яхшы изелер. Моннан соң эченә крахмалларга җитәрлек су салыныр.

*Пешкән крахмал.*

Әүвәлге кеби эшкә башланыр. Крахмал яхшы изелеп җиткәч, кирәк кадәрле кайнар су акрын гына салыныр, агач кашык берлә катыштырылып, юаш кына утта егерме кадәр кайнатылыр. Крахмал пешеп җиткәндә, куәтле катыштырылып, сирәк кисиядән[31] сөзелеп, күк буяу берлә төс бирелер.

*Бурлы[32] крахмал.*

Крахмалланган керләрне ялтыравыклы итәр өчен, изелгән крахмалны пешергән вакытта, ул бик аз суда изелгән крахмалның сигездән бере кадәр бур ташы кушылыр. Кисия пәрдәләре кеби крахмалга манылган нечкә нәрсәләрнең һәрберсе үтүкләнмәстән әүвәл, берәм-берәм алып, куллар берлә җыерчыкларын төзәтелер. Болай иткәндә, үтүкләгәннән соң өсләрендә крахмал ябышып калмас һәм бик ялтыравыклы булыр.

Крахмалланган нәрсәләрнең каты булуы шарт булса, аны бер көн әүвәл пешереп, хәзерләнгән крахмалга манып, икенче көн үтүкләнүдән бер чирек әүвәл пешмәгән крахмалга манылыр. Крахмалланасы нәрсә никадәр нечкә булса, крахмал ул кадәр куе вә никадәр калын булса, ул кадәр сыек итеп хәзерләнер. Хатын юбкалары, күлмәкләр, кровать простынялары, француз күлмәкләренең яка вә җиңнәре пешмәгән крахмал берлә, кисия, пәрдәләр кеби нечкә нәрсәләр пешкән крахмал илә крахмалланыр. Үтүклә-

---

[30] Риҗа итү – сорау, үтенү, өмет итү.

[31] Кисия – кисея, үтә-күренмәле юка киҗемамык тукыма.

[32] Бур – ак төстәге йошмак известь, акбур.

нәсе керләр үтүк хәзерләнгәнгә кадәр яхшылап төрелеп, кәрзиннәргә тутырылып хәзерләп куелыр. Үтүкли башлаган вакытта берьюлы үтүкләп бетерлек нәрсәләрне өсләренә бераз су бөркеп чылатылыр. Моннан соң читләреннән тартылып, өсләрендәге җыерыклары бетсен өчен, һәр читеннән тартып, төзәтелеп, икегә яки дүрткә бөкләп, һәрбер мәртәбәдә юешнең тигез кибүе өчен һәркайсы бер-берсенең өстенә куеп үтүкләнер. Бу вакытта керләр төрлесе төрлегә аерылып куелса, бертөрледән булган берничә керләр чиксез ансат үтүкләнеп, эш һәм бик яхшы эшләнеп, бигрәк тиз бетерелгән булыр. Бу арада крахмалланасы керләр бер читкә куелып торыр. Крахмалланган керләр үтүкләнгәнче, бер коры простыняга төрелеп торыр. Үтүкли башламастан әүвәл, һәрвакыт үтүк астында була торган үтүк бозының өстенә үтүкне тигезләп куелыр. Үтүкнең астын балавызлы бер чүпрәк берлә сөртелер, балавыз шәме булса, бигрәк яхшы. Үтүкләүче хатын зуррак керләрне үтүк бик кызу вакытта, кечерәк керләрне үтүкнең кызуы сүрелә башлаган вакытка туры китереп үтүкләргә кирәк. Өстендә үтүкләнә торган өстәл җитәрлек кадәр киң вә башка өстәлләрдән биегрәк булмак кирәк. Өстәл өстенә икегә яки өчкә катланган йон одеал, шәл кеби нәрсә ябып, аның өстенә бер мамык простыня ябып, болар өстеннән, шумасын өчен, өстәл астына бик киереп нечкә җепләр берлә бәйләргә кирәк. Өстәл булмаган сурәттә, бу җәймәне идәнгә җайлап үтүкләсә дә булыр. Керләр үтүкләнеп төзәлгән вакытта, бертөрле нәрсә бергә тигезләнеп, кат-кат төрелер. Бу катлау тугрысында һәм бертөрле чама тотарга кирәк. Бик зур кисәкләр итеп төрелсә, комодларга, сандыкларга урнаштырган вакытта мәшәкатьле булыр, бөгелер. Бик кечкенә кисәк итеп төрелсә, бик тигезләп тезеп салып булмас, гадәтчә итеп төрергә кирәк булыр.

## *Өй эче, бүлмә*

Бер яшь кызның бүлмәсенә керелсә, алдагы көндә ни рәвешле бер хатын булачагын бик тиз белергә булыр. Чөнки ул

бүлмәгә күз төшәр-төшмәс, андагы җыйнаклык вә җыйнак түгеллектән, ул кызның үзе өчен, бигрәк тә алдагы бер көндә аның белән бергә гомер итәчәк башка адәмнәр өчен хәзерләнүче гаять кыйммәтле бер йорт хатыны булып-булмаслыгы хәзер саналыр.

Имде бераз бу кечкенә аерым бүлмәгә кереп, күңелебезгә килгән нәрсәләрдән кыскалык берлә генә мәгълүмат бирим. Бер карауда ул бүлмәгә керүчеләрнең гадәттән тыш яратуларына вә чиксез хушлануларына сәбәп булып, эчендә торучының бер күркәм табигать иясе вә бер күп эшләрне сөюче кыз булуына шөбһә калдырмас. Бер якта кар кеби ак чыбылдыклы карават күзгә күренергә, өстендәге түшәк гаять гүзәл кабартылган, простынясы һич җыерылмый, тәмам тигезләнеп ябылган, мендәрләре кабартылып, урынына бик яхшы куелып, мендәр япмасы берлән өретелеп, бары мендәр башларының ап-ак тарткылары гына күрсәтеп куелган. Бу рәвешле төзелгән карават тузан кунмасын өчен кар шикелле ак кисия[33] берлә өретелеп, тәмам матурланып хәзер торыр. Караватның башында бер намазлык төрелеп куелган; моның өстендә яшь кыз, азан әйткәч тә килеп, биш вакытта фарыз[34] намазларын укыр. Бераз читтәрәк бер гардероб вә бер комод күренер. Берсе керләрне, икенчесе киемнәрне куяр өчен булып, комод өстендә бер уенлы сәгать, ике шәмдәл, бер йомырка шикелле көзге вә ике чәчәкле банка берлә зиннәтләнгән булыр. Тәрәзә янында бер язу өстәле, стена ягында бер китап шкафы булыр. Язу өстәлендә язу нәрсәләре вә бер «өй» тартмасы куелган, вә китап шкафының эче мәкяфәт[35] өләшенгәндә алган китаплары берлә гакаид[36], әхлак тугрысында утыздан артык яхшы тышланган китаплар куелганы күренер. Болардан башка җиһазлардан бүлмәдә бер кресло вә өч урындык булып, бу бүлмәдә булган нәрсәләр шулардыр. Күрәсез бит, бу бүлмәдә

[33] Кисия – кисея, үтә күренмәле юка киҗемамык тукыма.
[34] Фарыз – намазның мәҗбүри үтәлергә тиешле өлеше.
[35] Мәкяфәт – бүләк, мактау.
[36] Гакаид – иман.

зиннәтле һичбер нәрсә, тәкәллефле[37] һич җиһаз юк. Шулай булса да, аны күргәннәр матурлыгына, чисталыгына никадәр исе китәр. Эченә кергән адәм никадәр саф вә яңа һава тәнәффес кылыр[38]; аннан һич чыгасы килмәс. Монда шатлыкны, хушлануны тараткан нәрсәләр булса, ул да бары андагы тәмам җыйнаклык, чиксез пакьлек, аның ничек җыештырылырга, ничек чистартылырга кирәклеген сиздергән күркәм табигатьтер. Шуның өчен бөтен бу төрле-төрле нәрсә сыйныфларыннан өй эченең һәрбер тарафында дәхый[39] булуы ляземдер. Бер йорт тотучы хатын тора торган йортының бер эчен генә яхшы карау җитми, аның мөмкин кадәр һәрбер җирен яхшы рәвештә булдыру важибтер[40]. Моны булдырыр өчен аңа һичбер ялкауланмаска кирәк. Берничә изба вә кыйммәтле йорт нәрсәләре алырга кызыгу урынына, чисталыкны күзәтү шарты берлән кирәк яңа, кирәк иске, ничек булса булсын, файдалы вә чыдамлы булган нәрсәләрне сайлап, өендә булдыру важибдер. Бер бүлмәне зиннәтләмәк вә матур күрсәтмәк өчен бик аз нәрсә ляземдер ки: әүвәл стеналарны гаять чиста итеп тоту яки очсыз, матур кәгазь берлә кәгазьләүдер. Тотылгач, ялтыравыклары беткән нәрсәләрне ялтыратыр өчен бераз лак алып куймак, бик чиста пәрдәләр берлә тәрәзәләрне матурландырмак һәм боларга кушылып, тәрәзә пыялалары вә яңаклары, вә тузан куна торган һәрбер нәрсәнең чиста тотылуы, идәннәрнең, ишекләрнең һәрвакыт юылып, бик пакь тотылуы ляземдер. Шуның өчен йортның эчендәге нәрсәләр һәрберсе ошбу сурәттә зиннәтләнеп, һәрвакыт пакь тотылса кирәк. Сәламәтлекне саклау җәһәтеннән вә кирәк табигатькә хуш килү җәһәтеннән, йорт иясе хатынга бик зур кул өстенлектер.

---

[37] Тәкәллефле – ясалма, мактану өчен.
[38] Тәнәффес кылу – сулау, тын алу.
[39] Дәхый – тагы, тагын да.
[40] Важиб – тиешле, шиксез үтәлергә тиешле.

## *Урын такымнары*[41]

Төрле сурәттә вә төрле бәһадә булган тимер караватлар тоту хәзер һәркем тарафыннан рәгъбәт кылынгандыр[42], чөнки боларның кандала ояламасын өчен вә ансатлык берлән корылып, бозылыр өчен бүлмәдә урын аз алуы, аз гына мәшәкать берлә чистарту мөмкин булуындагы файдалары күбрәк. Там[43] бер урын нәрсәләре караватта ятылса, бер матрас, бер үлән яки кыл мендәр җиргә җәелсә, бер йон түшәк, ике матрас, бер баш, бер йөз ястыгыдыр. Әгәр туп-тугры кош йонынннан булган түшәк өстенә ятылса яки кош йонынннан булган ястыкка ятылса, хифзыссыйхәт[44] кагыйдәләренә хилафлык[45] кылынган булып, зарары хәзер сизелер. Матрасларның өстенә ябар өчен ике я өч простыня, вакытына күрә бер я ике йон, я мамыктан ике өретү[46] тәмам бер урынның җиһазларыдыр. Моннан артык җиһазлары булса, бик тәмам бер урындыр. Моннан башка урын баш очы берлә аяк очы бертигез дип әйтерлек, бик аз гына баш асты югарырак булырга кирәк. Каты урын йомшак урыннан артыграктыр. Кечкенә балалар кыш өчен бер кыл мендәр илә түшәк, җәй көне ялгыз кыл мендәр өстендә ятулары сихәт өчен муафикътыр. Иртә берлә йокыдан торганнан соң, урын җыеп, җыелгач, аска җәелгән юрганнар, көрпәләр селкеп, җилгә алып һаваландырганнан соң, урыннарына куелыр. Әгәр һаваландырмый, барын бер караватка өеп, кич берлән янә шуларны җайлап ятылса, сихәткә бик зарары булыр. Әгәр сәламәт вакытта урынның сихәткә муафикъ булмаган рәвештә куелуы бертөрле тынычсызлыкларны, авыруларны китерергә сәбәп булса, гаҗәба[47], авыр авырулар берлә рәхәтсез

---

[41] Такым – төркем, төр.
[42] Рәгъбәт кылу – теләү, омтылу, кызыксыну.
[43] Там – тулы, бөтен, төгәл.
[44] Хифзыссыйхәт – гигиена, сәламәтлекне саклау һәм аның юллары.
[45] Хилафлык – каршылык.
[46] Өретү – җәймә.
[47] Гаҗәба – ни гаҗәп!

булганнарны никадәр зарарландыруы лязем булыр. Дару кылынучы табиб, авыру яткан бүлмәнең мөмкин мәртәбә һавасының яхшы яңартылуын васыять кылыр. Ләкин урынының сихәткә файдалы кылып төзәтелүеннән бик сирәк бәхәс кылыр. Чөнки бер өй хатынының аннан хәбәрсез булуын күңеленә дә кертмәс. Күбрәк авыруларның озакка китүләренә вә кешегә йогуына караватларның вә урын-җирләрнең сихәтне сакларга хилаф[48] рәвештә булуыннан башка бер сәбәп тә юктыр. Шуның өчен авырудан терелә башлаган адәмнәр урын-җирләрен я бөтенләй алыштырмак, я пакьләндермәк бик ляземдер. Бу тугрыда матрасларны, көрпәләрне[49] пакьларга васыять кылыр. [...]

Йонның тетелүе йорт халкы арасында эшләнүе мөмкин булса да, тәдбирле[50] өй хатыны матрас, көрпә вә ястыкларны чистартырга кирәк булган вакытта эшчене үз йортына чакырып, үз күз алларында эшләтерләр, янә тәкрар итәм[51]: урын-җир затларыннан булган һәрбер нәрсә гадәттән тыш чиста тотылырга кирәк. Әгәр урыннарда кандалалар күренә башласа, яшеренгән җирләреннән ул зарарлы нәрсәләрне бетермәк тугрысында һич ялкаулык кылырга ярамас. Бер яңа йортта тоташ иренми бетерергә тырышу алардан котылыр өчен кифая кылыр[52]. Ничек тә боларны үтерер өчен беренче дару – стеналардагы агач нәрсәләрнең ярыкларына, матрасларның җөй араларына, пәрдә вә чыбылдыкларның бөгелгән урыннарына, караватт тимерләренең араларына, идән такталарының ярыкларына мондый нәрсәләрне үтерә торган порошок алып сипмәктер.

[48] Хилаф – кире, тискәре.
[49] Көрпә – мендәр.
[50] Тәдбирле – алдан күрүчән.
[51] Тәкрар итү – кабатлау, кабатлап әйтү.
[52] Кифая кылу – җитәрлек, кирәк кадәр булу.

## *Кунак бүлмәсе*

Зал – кунак өчен хәзерләнгән бер бүлмәдер. Бүлмә һәркемнең байлыгына вә урынына килешерлек рәвештә җиһазланып вә охшарлык манерда зиннәтләнгән булырга кирәк. Уртача зурлыкта булган бер залның җиһазлары күбрәк вакытта бер кәнәфи, алты кресло, дүрт урындык, берничә төрле рәвештә матур эскәмия, түгәрәк өстәл, бер комод, бер пианинодан гыйбарәттер. Түгәрәк өстәл бүлмәнең уртасына куелып, өсте мраморлы булмаса, бер эскәтер ябылыр, газета вә китаплар, вә эченә тәбрикнамәләр куелган бер зиннәтле тарелка яки касә куелыр. Пианино, йорт иясе ханым музыка белмәсә дә, бүлмәгә гүзәллек бирүче, файдалы нәрсәләрдән берседер. Җәй көнендә тәрәзәләргә кисия пәрдәләр куелып, кыш көнендә калын материаллардан ясалган пәрдәләргә әйләндерелер. Комод ике тәрәзә арасына куелып, өстенә яхшы бер көзге куелыр.

Икенче өстәлнең уртасына бер уенлы сәгать куеп, вә моның ике ягына кәндилле шәмнәр илә зиннәтләнгән ике шәмдәл вә ике лампа илә зиннәтләнер. Вә һәр икесенең өстендә бик оста эшләнгән вак-төяк, тансык, матур нәрсәләр куелырга кирәк. Йорт иясе хатынның күркәм табигать иясе вә кул эшләренә оста булуына бер дәлил булсын. Идән такталары буялган булмаганда, идәнгә бер ковер ябарга кирәк. Идәнне матур вә хуш күрсәтәсе килгән бер хатын кунак бүлмәсе берлә ашый торган бүлмәне гүзәл чәчәкләр вә матур яфраклар берлән зиннәтләр, кыш көне болар урынына кышлый торган гөлләр яки ясалган чәчәкләр куяр.

Өенә кич берлән кунак киләчәген белгән бер хатын кичке ашамакны, вә хезмәтчеләренә дә аш хәзерләр өчен кирәкле нәрсәләрне тиз үк хәзерләтеп, кунак бүлмәсенә кирәк нәрсәләрне хәзерләттерер. Вә кунакны яхшы алыр өчен, һәр нәрсәне хәзер булдырыр. Һәр нәрсә җитеш булган бер йортта һәрвакыт кич кунарга килгән карендәшләр, газиз дуслар өчен аерым бер бүлмә хәзерләп кую ляземдер. Кунакларны гадәттән тыш гыйззәт,

хөрмәт кылыр өчен кулдан килгән кадәр тырышырга кирәк. Кунакларның кеше өендә булганнарын күңелләренә китертми, гүя үз өйләрендә булган кеби булсыннар өчен, бүлмәләрендә һичбер нәрсә ким булмаска кирәк. Аларның кич рәхәт үткәрүләре өчен, бүлмәләрендә хәзерләнгән нәрсәләрдән башка су берлә тулы бер графина, янында бер стакан, язар өчен кирәкле нәрсә, бер кичке лампа илә бер дә кул шәмдәле янында бер коробка шырпы булырга кирәк. Комод өстендәге лампалардан башка шәмле шәмдәлләр вә бүлмәнең мөнасыйб[53] урынында кием эләр өчен вешалка – чөй, бер сөлге, бер туалет өстәле, бер ләгән, бер су савыты, сабын, туалет, юына торган су булдыру һәм бик яхшы булыр. Кыш булса, бүлмәсе яхшылап ягып җылытылган булып, исе тимәсен өчен, форточкаларын ачылган булсын. Караватта яки идәндә хәзерләнгән урында йоклау вә рәхәтлек өчен һәр кирәкле нәрсәләр хәзер булсын. Кунаклар тәмам рәхәтләнеп йокласыннар.

## *Котлау вә яки күрешә бару – хәл сорый бару*

Котлау – хәл сорый бару арада дуслыкны арттырыр, хәл вә урында бездән олугларыбызга, дуслар вә кардәшләребезгә, үзләре берлә танышлыгыбыз булган күршеләребезгә котлауларыбызны вә тәшәккерләребезне[54] әда кылырга[55], арада бер сәбәп булган бу иске гадәтебезне бетерергә тырышулар бик файдасыздыр.

Котлаулар – хәл сораулар я ихтыярсыз, я ихтыяр беләнбулыр. Ихтыярсыз булганнар шөкер кылырга вә корбан бәйрәмнәрендә күрешә барулар, бәйрәм котлаулары вә якыннарыбызның шатлык вакытларында күз яктылыгы яки бер каза, я кайгы вакытында баш саулыгы догасын кылыр өчен, барып хәлне белүдер. Бәйрәм котлаулары бәйрәмнәр керү берлән кайсы көнендә булсын, барырга яраса да, хатыннар әйткәнчә: «Хатыннарның

[53] Мөнасыйб – яраклы.
[54] Тәшәккер – рәхмәт әйтү.
[55] Әда кылу – үтәү.

бәйрәмнәре утыз көндер», – дигән сүзгә ияреп, ялкауланмый, тизлек берлә хөрмәт олуглыгы җәһәтеннән әүвәл күрешергә тиешле булганнарыннан башлап, тәртибе берлән тиз күрешеп эшне бетерү әдәп вә тәрбиягә муафикъ булыр. Бәйрәмнәрнең беренче, икенче көннәрендә иң хөрмәтле затларга вә кардәшләрдән иң зурларына, башка көннәрдә икенче якын дусларыбызга вә кардәшләребезгә бәйрәм котларга барылыр. Шул көннәрдә бәйрәм котларга килүчеләргә һәм каршысына котларга бару лязем булыр. Күңел ияләре дусларыннан, я танышлыгы булганнардан берсенең шатлыгы яки кайгысы булса, һич әсәрләнми калмаслар, вә үзләренә әсәр иткән шатлык яки кайгыны хәзер аларга белдерергә мәҗбүр булырлар. Никах гакде[56] кылынудан, мәртәбә югары күтәрелүдән, медаль алудан котларга барыгыз, дусларыгыз сездән мәмнүн булсын[57]. Йорт җәмәгатьләреннән берсе вафат булганнарның, кайгылыларының хәлләрен сорый барыгыз, сезгә соң дәрәҗә күңелләрен койсыннар. Якыннар вә дусларыгыз вафаты, күршеләрнең авырган вакытларында күп мәртәбә хәлләрен белегез, вә авыру яратырлык булса, я сезне күрәсе килгәне беленсә, аның хәлен сорый бару адәмлек, бәлки диянәтчә[58] лязем булган эштер. Котларга яки хәл белергә барган вакытта бик аз бер заман торырга соң дәрәҗә дикъкать ителсен. Мәсәлән, бәйрәм котлау вә башка гадәт белән котлауларда йорт иясе көчләп утыртмаганда, егерме минут яки ярты сәгатьтән артык утырмаска кирәк. Якыннар яки дусларга болай күрешә баруның яки кунакка баруның билгеле чиге булмаса да, күп булса бер сәгатьтән үтмәгәне артык булыр.

Озак утырылса, сөхбәтнең[59] арты киселеп, артык сүз табылмаслык бер дәрәҗәгә киленер, йорт иясе ханымның йөзеннән вә хәленнән эче пошуы беленсә яки сәгатькә караганы күренсә, аннан кайтып китүегез хәерле булыр, чөнки бу хәле үзенең

[56] Никах гакде – никах уку.
[57] Мәмнүн булу – риза булу.
[58] Диянәтчә – дин нигезендә.
[59] Сөхбәт – аралашу, сөйләү, әңгәмә.

барасы җире барлыгын яки йорт эчендә кирәкле эшләре булганын белдерә торган хәл булганын, күрешеп сөйләшү кадәрдән артык утыруыгыз килешмәс. Йорт иясенең күп утырганга эче пошканы иснәп, йокысы килгән кеби киерелеп-сузылып, кулларын угалап, бармаклары илә уйнавыннан һәм мәгълүм булыр.

Котларга вә күрешергә барган урынга икенче күрешүчеләр килгәнне күрер-күрмәс, тиз үк аннан китәргә хәзерләнергә кирәк. Үзеннән соң килгән кешенең китүен аслан[60] көтәргә ярамас. Гадәттә булган котлауларга, хәл белергә, туйларга барганда унбиштән ким яшьтә булган балаларны алып бармаска кирәк. Кардәшләр, дуслар берлән күрешә я хәл сорый, я кунакка барганда, бер яшь хатын яки яшь кыз олугларның алдында гаять әдәпле бер хәлдә булырга кирәк. Утырган урынында бер якка таянып тормаска, әгәр урындыкка утырган булса, урындык артына сөялмәскә кирәк вә һичбер вакытта ботларны берсе өстенә берсен куймаска кирәк. Әдәп белән төз генә, алдына карап утырырга, хосусан олуглар сөйләшкәндә арага һичбер сүз катыштырмаска кирәк, үзеннән бер нәрсә сорамаганда, сүз сөйләмәскә кирәк. Сөйләгәндә һәм бик шыпырт яки бик кычкырып сөйләмәскә кирәк. Тыңлаудан артыграк сөйләмәгә, гадәттән тыш һәвәсле булган күп сөйләүче хатыннарның гадәтенчә, барысы бердән сүз сөйләп, һичберсе берсенең сүзен икенчесе ишетмәслек бер хәлдә булу бәласеннән һәм үзләренең һәм халыкның котылуына тырышырга кирәк.

## *Мәҗлес*

Кунак чакырган вакытта кунакларны хөрмәтләр өчен йорт иясе хатынның ашларны вакытына күрә хәзерләп вә табынның кирәгенчә төзелүен төзүчеләргә кушып вә һәрберсенә бердән күз төшереп карамагы иң беренче бурычыдыр. Йорт иясе хатын кунаклар килә башлаган вакытка кадәр һәрбер эшләрне бетертеп,

[60] Аслан – һич, һичбер вакытта, беркайчан да.

ялгыз кунакларны каршы алып, аларны бик хуш итүдән башка һичбер эшне соңга калдырмаска кирәк. Һәрбер кушасы эшләр алдан кушылган булсын. Кунак килгәч, һичбер нәрсә эзләп, шөгыльләнеп йөрмәслек итеп, табынны бик яхшы корган булсын, чөнки кунакларны каршы алган вакытта йорт иясе хатын күз алдында булмаган бер өйгә керүләре кеби күңелсез эш, вә аның кунакларын ташлап китеп, аш өен, чоланнарны, аш хәзерләнгән бүлмәләрне әйләнеп-тулганып йөрүе кадәр начар эш һич булмас. Әгәр урынында табын корырга вә аш бирергә оста хезмәтче хатыннары булмаса, йорт иясе хатын кунаклар килүдән ул табын корыласы бүлмәгә барып, табынны үзе хәзерләмәгә вә ашның табынга ни рәвешле куелачагын вә кайсы артыннан кайсы куелачагын хезмәтче хатыннарга өйрәтеп куймагы яки бу эшләргә оста бер-ике хатынны мәҗлес көннәрдә хак берлән тотуы лязем булыр. Ашлар тәмамланганнан вә кунаклар бар да килеп беткәннән соң, ашар өчен табынга утырылганда, йорт иясе хатынның эше кирәк сөхбәт[61] арасында, кирәк истирахәт[62] вакытында булсын, гүзәл вә тәмле сүзләр вә күп куштанлыклар берлән кунакларының һәрберсенең хәтерләрен алып, аларны сыйларга, һәрберсе өчен кирәк булган аз гына бер нәрсәне дә ким булдырмаска мөнхәсыйр[63] булып калыр.

## *Бәгъзе нечкә гадәтләрнең урыннары*

Ике кеше бергә йөргән вакытта уң яктан, вә әгәр өч булсалар, икесенең уртасыннан бару яхшыдыр. Урамда олыларга тиешле бер кеше берлә бергә барган вакытта, ничек тә булса аннан бераз артка калып барырга кирәк булыр. Кеше күп булып, тыгызлык урыннарда бер нәрсә ашамак, кирәк кем булсын вә кирәк нинди нәрсә булсын, бармак берлә төртеп күрсәтмәк вә

[61] Сөхбәт – аралашу, сөйләү, әңгәмә.
[62] Истирахәт – ял, ял итү.
[63] Мөнхәсыйр – бөтен яклап чолгап алынган, камалган.

юлда очраган кешеләрне күрү өчен артына әйләнеп бакмак тәрбиясезлек булганлыктан, бу эшләрне кылмак һичбер дөрес булмас. Нәселе, байлыгы вә кардәшләре берлән мактанмак, тәкәбберлек, олылану яки ахмаклык итмәктер. Кунак чакырган яки өенә бер кунак киләсен белгән йорт иясе хатынның ялтыравыклы зиннәтләр берлә кунакларыннан артык булмаслык гадәтчә генә бер рәвештә бизәнеп киенмәге лязем булыр.

Язылган хатларны бик карап язмак, уйламый язмаска тырышмак бик кирәкле бер эштер. Аның өчен дүрт юллы бер гади записка ни рәвешле укып, ничек тәрбия күргәнегезне бер минутта күрсәтер вә уйламый язылган берничә сүз гаепле кылып, сезнең язарыгызны төшерергә җитәр: «Сүз һава кебидер, ләкин язылса, җуялмас». Үз исемегезгә язылмаган хатларны, нәрсә өчен булса да булсын, һич ачарга ярамас вә кул куймыйча һичбер вакыт хат язарга ярамас. Кемнән килгәнне белмәслек рәвештә хат язмак намуссыз вә оятсыз кешеләрнең эшедер. Һәрбер ана кызына җибәрелгән хатларын укып, я укыттырып, ни тугрыда икәнен белергә бурычлыдыр. Әгәр сезгә берничә кеше янында бер хат бирелсә, аны аслан[64] ачып укымагыз, мәгәр тиз җавапны көтеп торсалар гына. Болай булганда, ул хатны яки записканы укыр өчен рөхсәт сорагыз. Чакырылган кунакларга гадәттән тыш гыйззәт[65], хөрмәт кылмак аларның рәхәтлеге өчен кирәк булган һичбер нәрсәнең, кем булмаслыгы өчен, кулдан килгән кадәр тырышырга кирәк. Мосафир булып дусларыгызның өенә барсагыз, я алар тарафыннан чакырылсагыз, аларның һәрбер эшләренә ярагыз. Безнең татарда бер мәкаль бар: «Кунак булсаң, тыйнак бул», – дигәннәр. Мөмкин булганда, аларның хезмәтчеләрен хезмәткә кушмагыз, сезне куйган бүлмәләрендәге урын-җирләрне вә башка әсбапларны керләндерүдән, бозудан соң дәрәҗә сакланыгыз.

[64] Аслан – һич, һичбер кайчан.
[65] Гыйззәт – хөрмәт, кадер, мәртәбә.

Вә сусаулы, эч пошулы вә авырулы булган кешеләр мәҗлескә бармаска кирәк, чөнки барсалар, һәм үзләренә, һәм башка кунакларга тынычсызлык биргән булырлар.


Хифзыссыйхәт[66] безне сихәт вә сәламәтлекне сакларга өйрәткән бер гыйлемдер. Адәмгә килгән авыруларның бетүенә мөмкин кадәр хезмәт кылган нәрсә – хыйфзыссыйхәттер.

Чисталык – сихәт вә сәламәтлекнең кирәкле бер шартыдыр. Чисталыкның башлыча кораллары икедер: тәһарәт, мунча. Җәйге кеби кыш көнендә һәм биш вакытта өстебезгә фарыз[67] булган намаз өчен тәһарәт алудан һичбер чирканырга ярамас. Һава тирегә ябышып, аны керләндерә торган бер тузанны хави булганнан[68], биш вакыт өчен алынган тәһарәт тире чистартыр һәм Аллаһның әмерен урынына китерергә сәбәп булыр. Чисталар өчен мунча – иң яхшы бер нәрсәдер.

Ләкин анда ярты сәгать я өч чиректән, иң күбе бер сәгатьтән артык торылмасын. Бу тугрыда ванналар да файдалыдыр, ваннада ярты сәгатьтән яки өч чирек сәгатьтән артык торырга ярамас, эсселекләре утыз бер илә утыз биш дәрәҗәдән[69] артык булмаска кирәк. […]

[66] Хифзыссыйхәт – гигиена, сәламәтлекне саклау һәм аның юллары.
[67] Фарыз – үтәлүе тиешле булган.
[68] Хави булу – эченә алу.
[69] Дәрәҗә – градус.

## *МӨГАЛЛИМӘТЕЛ-БӘНАТ: КЕЧКЕНӘ ХАНЫМНАРГА УКУ КИТАБЫ*[1]


اثر: فخرالبنات سليمانوا

معلمة البنات

برنچی جزء

کچکنه خانملره اوقو کتابی

مکتب ابتدائیه‌نك ایکنچی صنفنه مخصوص

ناشری: «کریموف، حسینوف وشرکاسی»

اورنبورغ

«کریموف، حسینوف مطبوعات شرکتی» نك مطبعه‌سی

۱۹۰۸

НАУЧНАЯ БИБЛИОТЕКА КФУ
0001135672

[1] Сөләйманова Ф. Мөгаллимәтел-бәнат: Кечкенә ханымнарга уку китабы. Оренбург: «Кәримов, Хөсәенов ширкәте», 1908. 34 б.

**Мөхтәрәмә туташларга бер-ике сүз**

Хөрмәтле туташлар, кечкенә ханымнар, сез инде, әлхәмдүлилләһи, язу таный башладыгыз.

Ошбу китапта язылган хикәяләрне аңларга тырышып, бик дикъкать илә укыгыз.

«Начак холыклы кызлар» хикәясеннән гыйбрәт алып, шулар шикелле начар холыклы булудан сакланыгыз.

«Яхшы холыклы кызлар» хикәясе чыкканда, сез дә шулардан үрнәк алып, яхшы холыклы булырга тырышыгыз.

## Бисмилләһир-рахманир-рахим!

## *I. Ничек укырга кирәк*

Калын тавыш белән яхшы итеп укыр өчен, ялгыз сүзләрне тотлыкмый укырга җитмәс, туктарга тиеш урында туктап, гыйбарәгә тиешле рәвешен бирергә кирәк.

Бер китап укыган вакытта, тиешле булган җирләрдә туктарга өйрәнер өчен, шуннан яхшы бер кагыйдә булмас:

Укыган вакытта сәктә[2] дип аталган шул «,» ишарәгә[3] очрасагыз, «бер» дип әйтерлек вакыт туктап торыгыз. Нокталы сәктә дигән шул «;» ишарәгә яки ике нокта дигән бу «:» ишарәгә очрасагыз, «ике» дип әйтерлек вакыт торыгыз; тыныш дип әйтелә торган шул «.» ишарәгә очрасагыз, «бер, ике, өч» дип әйтерлек вакыт торыгыз.

Укыган вакытта гыйбарәгә тиешле рәвешне бирү дигән сүз сөйләшкән шикелле итеп уку дигән сүздер. Сөйләшкәндә бераз ашыгыбрак сөйләшерләр. Шат яисә кайгылы булганны, бернәрсә сорауны яисә бер сүзгә җавап бирүне билгеле итеп сөйлиләр, сөйләшү рәвеше дә вакытына күрә алышыныр; менә укыган чакта да нык сөйләшкән кеби укылыр.

[2] Сәктә – пауза; мәгънәсе белән «өтер»гә туры килә.

[3] Ишарә – билге, тамга.

Китапларда сораганга, галәмәт өчен шул «?» кечкенә ишарә тотылырга, исеменә «истифһам»[4] диярләр.

Шатлыкка, кайгыга, аптырауга, куркуга, кызгануга билгеле өчен бу «!» ишарә тотылыр: исемендә «тәгаҗҗеб»[5] яисә «нәда»[6] диярләр.

Түбәндә язылган гыйбарәләргә кирәк булган рәвешне бирегез, өйрәткәннәремне яхшы аңлаганыгызны күрсәтегез!

1. – Зәйнәп, бүген минем белән бергә уен уйнарсыңмы? Китапны бергә алыйммы, ни әйтәсең?

– Ярый, кардәшем, ал.

2. – Аһ, нинди яхшы! Никадәр шатланам! Анам мине тутама алып барачак; шатлыгымнан нишләргә белмим!

3. – Бүген бик кайгылымын: атам бик авырыйдыр. Мескен әткәем! Ничек ыңгыраша! Бер дә тавышланмыйм да, рәхәтләнеп ятсын.

4. – Сүземә җавап бир, Мәрьям, каләмне син алдыңмы? Аны кайда куйдың? Бигрәк рәнҗетәсең.

5. – Бүген иртә берлә эшчеләрнең берсе баскычтан төшеп вафат булды. Никадәр кызганыч! Инде балалары нишләрләр.

6. – Мине үз ирегемә куй, Гайшә, мине төртәсең, һәркайчан минем берлән уйныйсың, туйдым инде синнән, янымнан кит!

Яхшы уку бик сирәк бер эштер. Укучылар арасында бик яхшы укучылар аздыр. Укый белгән бер кеше берлә начар укый торган бер кеше икесе бер хикәятне укысалар, ничек тә булса, ул хикәя берсе-берсеннән аермалы булып ишетелер. Тыңлап торган бер кеше ике китап укый торганнардыр дип уйлар. Элеккесендә кешенең бик тыңлыйсы килер, икенчесендә исә кеше тыңлаудан бизәр. Минем кечкенә укучы хөрмәтле кызларым! Яхшы укырга

[4] Истифһам – сорап белү, белү өчен сорау; сорауны белдерә торган сүз; сорау билгесе.

[5] Тәгаҗҗеб – гаҗәпләнү, ис китү.

[6] Нәда – үкенү.

тырышыгыз, укый торган нәрсәгезгә күрә, табигый бер тавыш берлә кирәк булган рәвешне бирегез. Акрын тавыш берлә укудан, укый торгач тотлыгудан качыгыз, бик кызу да, бик акрын да укымагыз; туктый торган урыннарга туктап, сүзләрне билгеле итеп әйтегез. Дәхый[7] бер сүзне ике мәртәбә укымаска тырышыгыз.

*Сөальләр:*

Калын тавыш илә яхшы итеп укыр өчен нишләргә кирәк?

Бер китап укыганда тиешле урыннарда туктауны өйрәнер өчен кайсы кагыйдәне тотарга кирәк?

Яхшы уку өчен лязем булган сыйфатларны кыскача гына сөйләгез.

## *II. Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре вә Аллаһның нигъмәтләре*

Май аеның бик матур иртәсендә һәрбер тараф матурланган иде. Чәчкәләр кояш яктысы берлә ачылмыш, тәмле исләре берлә һаваны исләндермәктә иде. Чык тамчылары алмаз кисәкләре кеби ялтырамакта иде. Кошлар яфраклар арасында сайрашмакта иде. Күбәләкләр чәчәкләргә очышып уйныйлар иде. Мөршидә анасы берлә бергә бакчада йөридер иде, күзенең алдында булган нәрсәләргә хәйран булып карыйдыр иде. Кинәттән Мөршидә:

– Әни бу нәрсәләрнең барын да кем яратты?

– Аллаһы Тәгалә яратты, балам, өстендә тереклек кыла торган җирләрне, җирне яктырта торган кояшны, бөтен дөньяны янә Аллаһы Тәгалә яратты. Һәрнәрсәне юктан бар кылган Җәнабе ваҗибе[8] әлвөҗүдне[9] безгә сөяргә тиеш. Аның өчен, безгә бар нәрсәне бирүче мәгәр ул гынадыр.

---

[7] Дәхый – тагы, тагын да.

[8] Ваҗиб – үтәлергә тиешле; эшләнми калмаска тиешле эш, бурыч.

[9] Вөҗүд – барлык, бар булу.

– Сөекле әнкәм, балаларга аналарны бирүче дә Җәнаб Хакмы?

– Әйе, балам, шөбһәсез.

– Әнкәм, менә «Олуг вә кече итүче Аллаһ» дигәннәренең сәбәбен хәзер аңладым.

## *III. Күчергечкә яраралык бер кечкенә кыз*

Рабига чиксез гакыллы бер кечкенә кыздыр. Анасы үзен дәшер-дәшмәс уятыр: кайсы вакытта кечкенә кыз урыннан тормаска вә бераз йокларга теләсә дә, анага, хәтта үзеннән зурларның һәрберсенә буйсынырга кирәклеген белгәнгә күрә, тиз үк урыныннан торыр. Үзе генә киенер. Әгәр Рабиганы үзе генә киенә алырлык зур бала дип уйласагыз, ялгышасыз. Үзе бары җиде яшендәдер. Башны тараганда чәчне бераз тартсалар да, һич еламас. Чәчләрен тараганда тиреләрен тунаган кеби акыручылар бар да холыксыз балалардыр. Рабига ялгыз башына суык су белән юыныр. Кулларын сабын берлә юар, киемнәрне щеткалар, мөмкин мәртәбә бүлмәсен җыештырыр вә киенер. Акыллы вә уйлы кечкенә бу кыз көче җитәрлек эшләрне бетергәч, атасының вә анасының кулларын үбәр, алардан кәефләре яхшы булып-булмаганны сорар. Моннан соң аңар чәй бирерләр; шурпа ашар яки икмәк берлә сөт эчәр. Вә әлхасыйль[10], анасы ни бирсә, шуңар разый булыр. Аның өчен, Рабига исемнәре түбәндә сөйләнгән кызлар шикелле назланмас. Әгәр мәктәпкә китәр вакыты җитмәгән булса, йөрер, курчак уйнар, анасының хезмәтләрендә булыр вә бәгъзе вак-төяк нәрсәләр сатып алыр. Мәктәпкә китәр вакыты җиткәч, барып анасының кулын, кечкенә кардәшенең яңагын үбәр. Букчасын алыр вә сөенә-сөенә мәктәпкә китәр. Аны юлда күргәннәр: «Никадәр сөекле бала», – диярләр.

Рабига мәктәптән котылып килгәч, анасы сабакка тырышуыннан килгән арыганлыкны бетерер өчен, тирләп арымаслык кадәр генә уйнап, күңелне ачарга рөхсәт бирер.

---

[10] Әлхасыйль – җыеп әйткәндә.

Аның өчен, тәдбирле[11] хатын, бала, уеннан тыелып, һәрвакыт укырга гына кушылса, баланың күңеле кайтып, зиһене таралачагын, баланың укымаска хәйлә эзли башлавын бик яхшы белер.

*Сөальләр:*

Рабига ни өчен кечкенә кызларга күчергеч итеп күрсәтелер?

Анасы чакыргач, анасы янына килгән вакытта, битне вә кулны юган вакытта ни рәвешле эш кылыр?

## IV. Ата вә ана

Сөекле балалар, бала вакыт тереклекнең иң бәхетлелеген белмисез! Алдагы көндә бала вакытыгызны уйлап, бик сагыначаксыз, ата-анагызны бигрәк артык сөячәксез вә аларның яхшылыкларын вә сезнең өчен җаннарын фида кылырлык[12] хәрәкәтләрен аңлаячаксыз. Әгәр аларны югалту һәлаклегенә очрасагыз, ягъни вафат булсалар, аталык урыннарын исегезгә төшереп, «Аһ, әгәр белгән булсам иде!.. Әгәр хәзер дә терек булсалар иде, никадәр мәхәббәтләрен казаныр идем, никадәр аларны бәхетле итәр идем!» – диярсез. Болай булгач, нәни-нәни биби[13], кызлар, хәзердән аларны артык сөяргә, аларга буйсынырга башлагыз, һәртөрле борчудан аларны саклагыз, нигъмәт кадерен белмәгән тиле балалар кеби, аларны рәнҗетмәгез. Ялгыз атагыз берлә анагызга буйсыну белән берлә генә дә калмагыз, остазларыгызга, тәрбия кылучыларыгызга, якыннарыгызга, хәтта яшьтә сездән олуг булганнарга һәм буйсынып хөрмәтләүдә кимчелек кылмагыз вә алар янында уен уйнамагыз.

[11] Тәдбирле – алдан күрүчән.
[12] Фида кылу – корбан итү.
[13] Биби – хатын-кыз; матурларның матуры.

*Сөальләр:*

Балалык ни өчен иң бәхетле вакыттыр?

Балалар ата-анасына вә олыларга каршы ничек булырга кирәк?

## *V. Намия берлә анасы*

– Анагызны күп сөясезме, сөекле кечкенә кызым?

– Аһ! Дөрес, җан вә күңелдән.

– Афәрин, балакаем! Аны бик сөегез, аның өчен, бер ана җир йөзендә булган нәрсәләрнең иң яхшысыдыр.

Туган көнегездән бирле сезне тырышып баккан, сезне мәхәббәт берлә сөйгән, сез бигрәк кечкенә вакытта кичә вә көндез бишегегезнең яныннан аерылмаган анагыздыр. Авыру булган вакытыгызда сезне баккан, елаган вакытыгызда үбә-үбә күз яшьләрегезне корыткан анагыздыр. Хак Тәгаләнең рөхсәте берлә сезне йөретергә вә сүз сөйләшергә өйрәткән янә анагыздыр. Вә әлхасыйль, сезгә теләгән нәрсәләрегезне биргән яки хәзерләгән, вә сезнең бәхетле булуыгыздан башка бернәрсә уйламаган ушандак[14] анагыздыр.

Шуның өчен ана хакы ата хакыннан артык зурдыр. Аналарның балага шәфкате атадан артык булган өчен, ана хакы ата хакы кадәр ике өлештер. Болай булганда, анага изгелек вә һәр сүзенә буйсынып, һәрвакыт ризалыгын табарга тырышу ләземдер. Аларның җаннарын борчырлык, аларны рәнҗетерлек кадәр холыксыз вә ярамаган балаларның булуына һич ышанылмас.

Бу тугрыда бер яхшы кечкенә кызның уен укыгыз:

Намия гаять күңел табучы бер кыздыр. Анасы, аны эшләргә ярамый торган бер эшне эшләтмәс өчен, бары аңар: «Бу эш минем җанымны борчыячак», – дип әйтер, хәзер кечкенә кыз тик торыр.

[14] Ушандак – шулай ук.

Беркөн Намия анасы берлә базарга барганда, бер кечкенә ир баланы кулыннан тоткан бер хатын күрде. Бу кечкенә бала бер җиде яшендә булса кирәк иде. Ачуланган, акыра иде, бик елый һәм карыша иде. Намия анасына әйләнеп әйтте:

– Бу бикә кечкенә баланың анасы түгел микән?

– Нидән сорадың, кызым?

– Аның өчен, җанын бик борчый.

Янә бер көн Намия иптәшләреннән берсенең үкереп-үкереп елаганын күреп, бу кечкенә кызның ни өчен болай елаганын сорады.

– Анасы үлде дә, шуның өчен...

– И Аллаһ! Аналар үләләрме?

– Әйе, сөекле кызым, үләләр. Мин дә беркөн сине куеп китәчәгем, бары бу кайгының син зур булгач төшүен Хак Тәгалә хәзрәтеннән өмет итәмен.

– И! Алай булгач, әнкәем, мин зураерга теләмим, һәрвакыт кечкенә булып каласым килә! – дип анасына җавап биргәннән соң, Намия бераз уйлау берлә анасына сарылды.

Бәхетле ана, кечкенә кызының бу уйлары өчен көлемсерәде, күзләре яшьләнде.

Шуңа күрә, аналар балаларына кеше янында сеңермәскә, иснәмәскә, анда-монда төкермәскә, кулын иягенә, башын кулына, аягын аягының өстенә куймаска, кешегә аркасы берлә әйләнмәскә, кирәк тугрыга, кирәк ялганга булсын, ант итмәскә, һәркемнән әүвәл сүзгә керешмәскә, бары үзеннән соралган нәрсәгә кирәк кадәр җавап бирергә, зурлар сүз сөйләгәндә сүзгә катышмаска, бер җирдә утырганда үзеннән зур кеше керсә, аяк өстенә торырга, аның янында чүгеп, әдәпле утырырга, һичбер кешегә яман сүз сөйләмәскә, яман сүз сөйләгән балалар берлә сөйләшмәскә, боерсалар, балалар да аларны тыйганнарына вә боерганнарына буйсынырга тиешләрдер. Болай булмаганда, аларны рәнҗеткән вә җаннарын борчыган булырлар.

*Сөальләр:*

Бер ананың баласына булган мәхәббәтенә дәлилләрен санагыз.

Намия начар кечкенә ир баланы күргәч ни әйтте?

Үкереп елаган бер кызны күргәч ни уйлады?

Аналар балаларына нинди эшләр боерып, ниләрдән тыйган вакытта, аларга каршы балалар нишләргә кирәк?

## *IV. Назлы илә атасы*

Балаларым, көн буе сезнең өчен тырышкан – атагыздыр. Сезнең һәрвакыт яхшы ашап-эчүегез, тәнегезне саклар өчен матур-матур киемнәр киенүегез өчен акча табу тугрысында никадәр зәхмәт вә мәшәкать чиккәнен белсәгез! Атагыз күп вакытта бик арыган була, алай да һич хафа булмас, чөнки газиз балалар бик сөя вә үзенең тырышуы алар өчен бик тиеш булганын белә. Кечкенә-кечкенә ханымнар! Һәрвакыт атагызга үзеннән шатланганыгызны белдерегез вә аны һич ачуландырмагыз.

Аталарның калын бер тавышы булганнан, берәүне орышмак вакытларында куркытачакларын бик яхшы беләсез. Кич берлә атагыз эшләрен бетереп өйгә килгән вакытта, тиз үк кулын яки итәген үбеп, хәлен сорагыз вә үзен сөйгәнегезне аңар әйтегез. Моның өстенә сезне кочагына алып сөячәген, арыганлыгын онытачагын күрәчәгегез кеби, бигрәк тә сезне ышандырам ки, атагызның сездән ризалыгын сөйләсәгез, никадәр булганын күрерсез.

Инде атасын бик сөйгән бер кечкенә кызның хикәятен укыгыз.

Назлының атасы игенче иде. Бер көн печән төягән бер арбаның түбәсеннән төште вә бик күп җирләре авыртты. Аны өенә китергән вакытларында һичберкемне танымаслык бер хәлдә иде, бары ике сәгатьтән соң күзләрен ачып сөйләшә башлады.

Назлы чиксез өметсезлек эчендә калды. Бүлмәнең бер почмагында кулларын күтәреп, сөекле атасын үзенә багышлауны вә аның күп еллар гомер итүен Хак Тәгалә хәзрәтеннән сорады.

Бу эш булган төндә Назлы һич күзләрен йоммады. Төн уртасына таба урыныннан торды, яланаяк, бик сакланып кына, сулу алып-алмаганын ишетү өчен, терек икәнлеген белер өчен, атасының яткан урынына якын килде.

Борылып киткән вакытында авыру сорады:

– Кем ул?

– Мин идем, әткәем.

– Ни кирәк, кызым, ни өчен тордың, әллә авырыйсыңмы?

– Әткәем, хәлеңне белмәкче булган идем, бик кайгырдым, һич йоклый алмыйм.

– Сөекле балам, зарарлы түгелмен. Никадәр күңел алучы син, кызым, кил сине бер сөйим дә, бар, йокларга кара, вә рәхәт бул, иншаллаһ, иртәгә яхшы булырмын.

*Сөальләр:*

Җәмәгать эчендә атаның хезмәте нидер?

Ни өчен бу кадәр мәшәкатьләргә түзәр?

Назлының атасының башына нәрсә килде?

Күңелне тынычландыру өчен кечкенә кыз ни эшләде?

## *VII. Вахидәнең тавыгы*

Вахидә бу минутта бик шөгыльле бер кечкенә кыздыр. Үзенең матур кара тавыгы утырадыр иде. Берничә көннән бирле чебиләр йомыркадан чыкканнар.

Һәркөн иртә берлә, хәтта үзе чәй эчмәстән элек, Вахидә чебиләренә ашарга чыгарыр. Аларга пешкән йомырка сарысын турап яки җебетеп, хәзерләп куйган икмәк катыларын бирер. Кайсы вакытта аларга бәрәңге вә арыш оныннан камыр да бирә.

Соңыннан суларын алыштырыр. Чебиләр зурайгач, аналары кеби җимешләр, үләннәр, кортлар, орлыклар вә һәртөрле ашлыклар ашаячаклардыр.

Вахидәнең ун чебеше бардыр. Һәммәсе берсе-берсеннән матурдыр. Иртә берлә кояш чыккан вакытта, чебеш читлегенең

астында, чебиләр, йөриселәре килеп, читлекне ачсын дип, Вахидәне сабырсызланып көтәләр.

Аналары чебиләрне астында җылытып тоткан канатларын ачар, сөекле балаларына «кыт-кыт» дип тышка чыгар. Тавык, бар эше шул булганга күрә, чебиләрен һичбер күз алдыннан югалтмас.

Һава начар булса яки чебиләре ераккарак китсә, һаман «кыт-кыт-кыт» дип аларны чакырыр, алар да бу тавышка йөгерешеп, аналары янына килерләр.

Аларның сүз тыңлаганнарына каршы тавык та җирне казыр вә аларга корт эзләр. Корт тапкан вакытта, аны ашый дип уйлыйсызмы? Хәер, аны һич уйламас! Үзенең бәхетле булуы өчен, балаларының кирәк булган нәрсәгә малик булуларын[15] эстәр[16].

Аналарының күңелләрендә һичбер нәрсә үлчәнмәс. Аның өчен аларның күңелләре мәхәббәт вә шәфкать берлә тулыдыр.

Балаларны сакларга кирәк булган вакытта, башка заманда ул кадәр куркак булган тавык батыраер.

Карчыга, тилгән кеби ерткыч бер кош күрендеме, куркыныч тырнагының алдына атылыр, вә үзенең хәтәрле тавышлары, канат кагулары вә бу дәрәҗә батырлыгы илә күбрәк һава качкыннарын куркытыр. Хәтере азрак бер хайван күргәндә, ни ният берлә килгәнен белер өчен, көтеп торыр. Әгәр хайван тыныч кына үтеп китсә, тик кенә торыр, канатларын җилпәзә ачар, бераз алгарак барыр вә аңа: «Көчең җитәрлек булса, кил, әлбәттә, сиңа каршы торырлык бирәүне күрерсең!» – дигән кеби күренер.

Тавык ялгыз асрар өчен генә махсус бер хайван түгелдер. Ите бик җиңел, гаять файдалы, хосусан йомыркасы бик файдалыдыр, хәтта итеннән артыграк тәмле һәм кадерледер. Йорт тавыклары, кортлар алдыннан, аерым буларак, һәркөн йомырка салыр, бераз йомырка салганнан соң, йомырка басу ниятендә булганнарын белдерерләр. Бу вакытта асларына ун-унике

[15] Малик булу – ия булу.
[16] Эстәү – теләү.

йомырка куярлар ки, егерме-егерме бер көн эчендә чебиләр чыга башлар.

Тавык аналык мәхәббәте вә шәфкатенең бер зур сурәтедер.

*Сөальләр:*

Вахидә чебиләрне ничек асрар?

Балалары үзеннән ерак киткәндә, аларга бер хайван якынлашкан вакытта тавык нишләр?

Безгә тавыкны нәрсә кадерле итәр?

## *VIII. Кечкенә балаларның яхшы сөт анасы*

Кечкенә-кечкенә ханымнар, хайваннар эчендә иң кадерле вә иң файдалы бер хайван булса, ул да сезгә сөт биреп, һәр көн аның сөтен эчкәнегез бер хайван, ягъни сыердыр.

Сезгә аның рәвешләрен сөйләвем лязем килерме? Тыңлагыз. Сыерларның сары дигән, кызыл, коласы, ак, чуары булыр; башы ике зур мөгез берлә зиннәтледер ки, очлары, хайван бер җиргә аның берлә орса, ул җирне асатлык берлә тишәр өчен югары калгандыр.

Сыерның имчәкләре бардыр. Бу хәлдә зәват сәди[17] сыйныфына кермештер; дүрт аягы бардыр, шуңар күрә чарпадыр[18]; печән берлә асралыр, әкәл әннәбаттыр[19]; ашаганда күшәр, ягъни ашларын ике мәртәбә тешләре берлә чәйнәр, хайван ...рә[20] сыйныфындадыр. Бу урында сезгә нәрсәләрне белдерү лязем күренер.

Бер үләнлектә утлап йөри торган сыерлар яки сарыкларны карап торсагыз, аларның үләнне ашар-ашамас йотканнарын күрерсез. Шул хайваннар, әүвәлге ашказаннарын, ягъни ашказан-

---

[17] Зәват сәди – имезүчеләр.
[18] Чарпа – дүрт аяклы хайван.
[19] Әкәл әннәбат – үлән белән тукланучы.
[20] Сүзнең беренче өлеше төшереп калдырылган, мөгаен «мөҗтәрә» сүзедер, «күшәүчеләр» мәгънәсендә.

нарының әүвәлге кесәсен тутырган вакытларында (аның өчен аларның ашказаннары дүрт кесәгә бүленгәндер) йоклар өчен түгел, бары ашларын тәмамлар өчен генә үләнлекнең бер почмагына барып ятырлар.

Кисәк-кисәк башларын, муеннарын сузарлар. Шулай иткәндә, бугазларының түбен башыннан, әүвәлге ашказаннарыннан авызларына таба бер кечкенә йомарлык үләннең югары чыкканы күренер. Хайван аны яңа баштан акрын-акрын тешләре берлә чәйнәр. Бер ярым, ике сәгать кадәр күшәр, бу мәртәбәсендә ашлар ашказанының икенче кесәләрендә сеңәр өчен кирәк кадәрле изелгән булыр.

Менә, ханым-кызлар, инде мәгълүмат сахибе[21] була башлыйбыз, хәзер: зәват сәди, чарпа, әкәл әннәбат, хайванат мөҗтәрә дигән сүзләрнең ни дигән сүз икәнен өйрәндегез. Ярый, без янә хикәябезгә керешик.

Кызларга бер сыерның гаять шат бер хәлдә булуын вә бозавы берлә уйнар өчен сикерә башлаганын күрмәк гаҗәп кызыклы күренер. Ул сыер яңадан яшәрер, чабар, сикерер, шаярыр. Бу бозавын сөяргә теләгән вакытында бозауның борынын теле берлә ялар. Моңа каршы бозау да, балаларга эченнән сурәт килеп чыга торган коробкалар бүләк итеп бирелгәч, ничек капкачын ачканда кинәттән бер ямьсез сурәт килеп коробкадан чыга, шуның шикелле башын югары күтәреп яңадан уйный башлар өчен, сөекледер анасына юл күрсәтер. Бервакытта сыер [...] Мисырда бик мөкатдәс бер хайван иде. Бу көндә дә Һиндыстанда бер төрле мәзһәбкә[22] мәгъбүд[23] тотылмактадыр. Ул мәзһәбтә булган һиндыстанлылар аны хөр тотарлар вә үтерүне чиксез бер гөнаһ санарлар.

Сыер күбрәк вакытта фәкыйрь адәмнәрнең бөтен байлыгыдыр. Аларга файдасы бик күп булыр. Сөте берлә май һәм

[21] Сахиб – ия.
[22] Мәзһәб – юнәлеш, дини юл.
[23] Мәгъбүд – табына торган зат.

эремчек ясалыр, тизәге тиресләрнең иң яхшысыдыр. Бу тирес аркасында уртача бер туфрак яхшы иген бирер.

Күн эшләүчеләр тиресеннән кәҗүл[24] вә олтанлык хәзерләрләр. Аяк киемнәре, ат сбруе вә иярләре, кечкенә, матур сумкалар һәм юлга бик уңайлы саквояжлар ясалыр.

Ләкин бары болар гына да түгелдер: кыллары берлә мендәр ясар вә башка нәрсәләрнең эчен тутырырлар. Мөгезләреннән тарак, төймә, тарелкалар, кашыклар, сөякләреннән каптырма вә беләзек кеби нәрсәләр ясалыр. Келәй вә шикәрнең төсен ялтырата торган сөяк порошогы, сеңерләреннән камчы вә скрипка кылы, эчәкләреннән казылык тышы, эч маеннан туң май, шәм ясарлар, үте май табын бетергән вә рәсем буяган вакытта тотылыр.

Үгез һәм кадерле бер хайвандыр. Көчле вә эшкә яраклыдыр. Сабыр вә чыдамлыкның тырышу вә эшләүнең бер зур мисалыдыр. Игенлекләрнең арысланы, абзарларның каһарманыдыр. Кыр вә авыл эшләренең һәртөрлесендә файдалы бер хайван булганлыгы кеби, ите дә чиксез ашлыклыдыр. Бу рәвеш берлә һәркемнең байлык вә азыгының нигезен күрсәтәдер.

Кечкенә ханымнар, югарыда сөйләгән хайваннарның безгә булган яхшылыкларын исегезгә төшереп, һич йорт хайваннарын рәнҗетмәгез вә аларны мөмкин булган кадәр күзәтегез.

*Сөальләр:*

Ни өчен сыер зәват сәди[25] хайваннарыннандыр, чарпадыр[26], әкәл эннәбаттыр[27] вә хайванат мөҗтәрәдерләр[28]?

Бу кадерле хайваннан әйткән нәрсәләребезнең беразын сөйләгез.

Үгез нәрсәгә ярар?

Йорт хайваннарына ничек эш кылырга кирәк?

---

[24] Кәҗүл – бик нәфис, юка күн, нигездә кәҗә тиресеннән ясала.
[25] Зәват сәди – имезүчеләр.
[26] Чарпа – дүрт аяклы хайван.
[27] Әкәл эннәбат – үлән белән тукланучы.
[28] Мөҗтәрә – күшәүче.

## IX. *Яхшы кечкенә күңел*

Дөньяда булган адәмнәрдән берничәсенең күп, башка берничәләренең дә аз акчасы булган кеби, бик күбегезнең һич акчасы юктыр.

Күп акчасы булганнар байлар, һич акчасы булмаганнар фәкыйрьләрдер. Фәкыйрьләр бик кызганырлык бер хәлдәдерләр, ләкин намуслы булырлар. Кирәкләренә гайрәт берлә торсалар, безнең рәхим кылуыбызга хаклары булыр.

Балалар, кесәгездә бераз акчагыз булса, бер микъдарын фәкыйрьләргә бирегез. Уенчыклар берлә перәннекләргә барысын да тотып бетермәгез. Бер теләнче күргән вакытыгызда, аңар ыспайлык, йомшаклык вә яхшылык берлә садака бирегез, бу вакытта садакагыз аңар бик хуш килер, сезгә учын ачкан өчен оятлы булмас, чөнки сезнең күңелегезнең арулыгын күрер. Сез дә хәзер хикәятне сөйләячәгем бер кечкенә кызга охшарсыз.

Шадиягә беркөн тутасы шаярмаган вә китабыннан ялгышсыз ике кәгазь укыганы өчен бераз акча бирде.

Шадия бер курчак сатып алыр өчен өйгә якын бер урында булган кибеткә йөгереп китте. Кибет эченә кергән вакытта кочагында бер кечкенә баласы булып, теләнмәктә булган бер фәкыйрә хатын күрде. Моны күргәч, Шадия: «Акчамны фәкыйрь хатынга бирим микән, әллә курчак сатып алыйм микән?» – дип уйга калды. Балага карады: мескен мәгъсумнең[29] үзенә көлем-серәгәнен вә аркасында телем-телем вә гаять керле бер кием булганын күреп, чиксез кызганды.

Һич уйламыйча, ыспайлык берлә генә акчасын теләнче хатынга сузды. Мескинә хатын да: «Шөкерләр итәрем, минем нәни-нәни кечкенә ханым, бик юмартсыгыз. Аллаһ хәзрәте морадыгызны бирсен, сезне сараннарга мохтаҗ кылмасын!» – диеп, акчаны алды.

[29] Мәгъсум – гөнаһсыз яшь бала.

Шадия һичбер уенчык алмый аннан кайтты. Бары эшләгән хәере өчен күңеле бик шат булды.

*Сөальләр:*

Байлар фәкыйрьләргә ни рәвешле булырга кирәк?

Шадия акчасын биргән өчен яхшылык иткән булдымы, яманлыкмы?

Сез дә аның кеби эшләр идегезме?

## *X. Яктырту*

Кыш көннәр кыска булыр, кояш сирәк күренер. Әүвәлге биш сәгать эчендә һич яктылык булмас.

Кечкенә кызларым, көндезнеме яки кичнеме бигрәк артык сөясез, сөйлә, күрим?

Көндез ни, кич адәмнең җанын борчыр. Адәм барасы җирен көчкә күрә алыр. Әйе, бик дөрес, балам, адәм караңгылыктан котылу өчен, май шәм, каты шәм, керосин вә газ лампасы яндырып утырырга яки барасы җиренә барырга мөмкин.

Бөтен бу нәрсәләрне аерым сөйлим.

Май шәм туң май берлә, ягъни сыерларның яки сарыкларның эч мае берлә ясалыр. Эч мае берлә шәмне ничек ясарлар? Туп-туры туң майны калыплар эченә салалар вә урталарына мамык җебеннән пилтә[30] куялар. Май шәм берлә каты шәм арасында аерма нәрсә? Каты шәм ясар өчен туң майның үзен тотмаслар, ләкин стеарин исемендә туң майдан чыгарылган бер нәрсә тотарлар.

Каты шәмнәрнең пилтәсе гаять нечкә вә ыспай вә үрелгән булыр. Машина берлә кисәргә хаҗәт булмас.

Кадриянең анасы ашаган вакытта бер газ яндырыр. Ахшамнан соң бүлмәләргә яки балконнарга артыграк яктылык кирәк

[30] Пилтә – филтә, ягулык матдәсе сеңдерелеп, ут кабызып яктырту өчен кулланыла торган киндер тасма (лампада, керосинкада), фитиль.

булса, берничә лампалар тотылыр, эчләренә зәйтүн мае я керосин салыныр. Лампаларда янган зәйтүн мае төрле-төрле үләннәрнең орлыклары яки чикләвекләре изелеп чыгарылыр. Болардан башлычасы «турса»[31] «вакульза»дыр[32].

Керосин җирдән чыгарылыр. Бу сәбәптән мәгъдән[33] мае яки таш мае дип аталыр. Керосин табар өчен бәгъзе вакытта гаять тирән коелар казылыр. Бүгенге зур шәһәрләрнең кайсы газ берлә яктыртылгандыр.

Һава шикелле күзгә күренми торган вә һава, янә ике дәрәҗә җиңел булган бик начар иследер ки, исеменә һава газы диләр. Бу һава газын каты булган мәгъдән күмереннән чыгарырлар.

Кайсы зур шәһәрләрдә берничә борынгы әсәрләр[34], зур биналар, магазиннар электрик яктысы белән бергә яктыртылгандыр.

Башкаларыннан бигрәк якты булган бу яктылык, кояш яктысыннан аермасыз бер дәрәҗәдә булыр.

Яктырту бәхәсендә булганыбыз өчен бер-ике сүз шырпы тугрысында сөйлим. Шырпыларның ике очыннан берсе күкерткә буялыр, вә күкертнең өстенә дә бераз гына фосфор сөртелер. Ышку берлә, ялт итеп китүкән нәрсә – фосфордыр. Күкерт җирдән чыгарылыр, вә фосфор хайван сөякләреннән ясалыр.

Фосфор бер зәһәрдер, шуның өчен кулына кергән һәр нәрсәне имәргә теләгән кечкенә балалар кеби шырпыны аслан[35] авызга тидерергә ярамас.

Сөйләгән нәрсәләребезнең берсе дә, гаять файдалы булуы берлә бергә, никадәр казаларга да сәбәп булыр. Шырпы берлә уйнамакчы булып ут чыгарган яки ут уртасында калып һәлак булган, яки бер лампага якын барып, я лампаны кулына алып,

[31] Май тормасы орлыгы (аңлатма китап авторыныкы – ред.).
[32] Бертөрле кыр кәбестәсенең орлыгы (аңлатма китап авторыныкы – ред.).
[33] Мәгъдән – руда.
[34] Әсәр – тарихи истәлек.
[35] Аслан – һич, һичбер вакытта, беркайчан да.

өстенә аударган тыңлаусыз балаларның ялгышлык берлә булган кыйссаларын уйлагач, адәм курку эчендә калыр.

Артык саклану ни эштер, чөнки ут бик асатлык берлә ялкын алыр, шуның өчен лампаларны чистарткан вә эчләренә керосин тутырган вакытта, нәрсәләрне вә янган сигара вә ут шикелле нәрсәләрне ерак тотарга кирәк.

Кич берлә коры җирдә бик күңелсездер, ләкин диңгездә бигрәк тә күңелсездер. Батыр көймәчеләребез озын сәяхәтләрдә диңгез читләрендә, түбәләрдә гаять ялтыравыклы якты җибәрә торган, вә бу яктыны еракларга кадәр җиткерә торган фонарь дигән колгалар булмаса, күп хәтәрләргә очрарлар.

Көймәчеләр кайткан вакытларында ерактан күренгән вә үзләренә «Тыныч булыгыз, хәзер сөекле йортыгызга килдегез, җәмәгатегез, ватандашларыгыз сагынып көтеп торалар, аларның яннарына килеп, арыганлыкларыгызны бетерегез, ял итегез!» – дигән кеби, бу шәүләләрне күргән вакытта шат булырлар.

*Сөальләр:*
Ни берлә яктыртабыз?
Май шәме вә каты шәм ни берлә ясалыр?
Лампаларда янган зәйтүн мае нидән булыр?
Керосин берлә һава газлары ни нәрсәдән чыгарылыр?
Балалар шырпыга кагылырга ярыймы?
Фонарьләр нигә ярарлар?

## *XI. Сәгыйдә. Хисап белеме*

Сезгә бер начар хикәя сөйлим. Исемә төшкәндә, хәзер дә көләмен.

Кичә кич берлә яныбыздагы шикәрче кибетендә утыра идем. Күршем кечкенә Сәгыйдә дә анда килде. Бик көләр йөзле иде, конфет сатып алыр өчен анасыннан акча алганын аңлата иде. Дөресендә, шикәрчедән бераз конфет, ике кисәк алма шикәрләмәсе сорады.

Шикәрче аңар сораганын биргәннән соң, бурычының күпме икәнен әйтте.

Кечкенә кыз кулын кесәсенә тыкты. Портмонетын алып ачты. Вә эчендә булган акчаны, ягъни ике егерме тиенлек, бер илле тиенлек, беразда икешәр тиенлекне прилавка өстенә түкте.

Моны күреп, шикәрче әйтте:

– Кечкенә ханым, миңа күп акча бирәсең, бары егерме алты тиен җитәр.

Сәгыйдә, гаять оялып, шул рәвешле җавап бирде:

– Әфәндем, кулымдагы акчамның барысы шулдыр, эченнән сезгә тиешле булган кадәрен алыгыз.

Бу сүздән шикәр алырга килгән адәмнәр кычкырып көлмәгә башладылар, Сәгыйдәнең хисап белмәгәне мәйданга чыкты. Шикәрче алачакны алып, үзенең кечкенә алучысы Сәгыйдәгә әйтте:

– Сезнең яшегездә булган бер ханым хисап кылырга белү тиеш, балам, тизрәк хисап өйрәнүегезне васыять кылам[36].

Сәгыйдә калган акчаларын җыйды, гаять оятлы булып, тизрәк аннан чыкты.

*Сөальләр:*

Сәгыйдәнең башына килгән эшне сөйләгез.

Хисап белүнең ни өчен бик файдалы икәнен сөйләгез.

## *XII. Тыңлаусыз Шәкүрә*

Шәкүрәдән дә тыңлаусыз кечкенә кыз табуы мөшкел булачактыр. Тотыш аңар: «Шакирә, шуны шулай эшләмә, моны болай эшлә, дип, моны болай итмә», – дип әйтеп торырга мәҗбүрләрдер. Чөнки ул аңламыйча, моны я аны эшләр, аның өчен ялгыз үз гакылына килгәнен эшләр.

Үткән атнада башына ни килгәнен беләсегез киләме? Эш бик яхшы үтте. Ләкин Ходай хәзрәте аны саклады. Башына килгән

---

[36] Васыять кылу – биредә: киңәш итү.

казага сәбәп булган нәрсәне икенче мәртәбә эшләмәскә үзенә үгет бирәмен.

Шәкүрә ханым дәү анасының янына барган вакытта, бүлмә урам ягында булганнан, килгәнне-киткәнне күрер өчен, һаман тәрәзәгә йөгерер. Дәү анасы, аяксыз булып, урыныннан кыймылдый алмаганнан, аңа берсе артыннан берсе: «Шәкүрәчегем, тәрәзәдән асылма, чөнки соңыннан төшеп, бер җиреңне имгәтерсең яки үлемгә сәбәп булырсың», – дисә дә, кечкенә тыңлаусыз: «Юк, ханым әбекәем, син һич курыкма», – кеби җавап биреп, тагы артыграк асылынып тышны карар.

Кичәге көн, Шәкүрә урамнан бер уен тавышы ишетеп, тиз генә тәрәзәгә йөгерде, үзенең начар холкы буенча, уен тавышын яхшырак ишетмәк вә уйнаучыларны да яхшы күрмәк өчен, тәрәзәдән артык асылынды. Һәм Шәкүрә бер юлы юкка чыкты. Кечкенә кыз хәзер бүлмә эчендә күренмәс булды, чөнки асылынган вакытта башы авыр килеп, түбән төшкән иде...

Аяксыз дәү анасы барып аны коткарырга көче җитмәгәнгә, бар коты илә өйдәге җәмәгатьләрне кычкырып чакыра башлады. Тыңлаусыз кыз нишләгән иде? Стенага асылынып калган иде, әле дә яхшы, стенада виноград чыбыгы бәйләр өчен бер чөй кагылган иде. Аллаһның хикмәте илә, Шәкүрәнең кәмәре[37], шул чөйгә эләгеп, кечкенә кыз стенага асылынып калды. Карагыз, нинди хәтәрле тору! Бер читтә стена төзәтүче бер оста, Шәкүрәнең кычкыруларын ишетеп, баскычын алып, аны коткарырга килде. Оста вакытында җитеште. Чөнки кечкенә кызны котылдырган вакытта кәмәре өзелде, әгәр бер минут кичеккән булса, Шәкүрә төшеп, ташлар өстендә кисәк-кисәк булачак иде.

Бу эш булган урынга тиз үк Шәкүрәнең атасы, анасы килделәр. Аны үлек кеби төсе беткән, тетрәмәктә, куллары җәрәхәтләнгән, кан берлә тулган бер хәлдә күргәч, аны орышырга һич хаҗәт калмаганын вә тыңлаусызлыгының җәзасын тапканын белделәр.

[37] Кәмәр – билбау.

*Сөальләр:*
Шәкүрәнең зур кимчелеге нидер?
Башына ни каза килде?
Ничек котылды?

## *XIII. Кыш хозурлары*

Кайвакытта һава бик суык булганда, кечкенә балаларга: «Кыш бабай килә», – диярләр.

Кышны гадәттә аркасына бер иске чикмән, башында колакчын булып, һәрбер җире каплаулы булып, бары борынының очы гына күренеп, таягына таянып килгән бер адәмгә охшаталар.

Кыш кайгы бирә торган бер вакыттыр: һава суык булыр, кар явар, бу вакыт, бар адәмнең җанын борчудан башка бер эш булмаса да, бәгъзе вакыт хозуры да бардыр. Җил искән вә тышта кар, яңгыр каты яуган вакытта, кичләрдә бер якты утның каршысында гаять җылы бер бүлмәдә булмак вә янында атасы-анасы, ир туганнары, кыз туганнары булмак нинди хозур булыр! Күбрәк моның кеби риясыз[38] җыю-ашауларда, олуг бабай үткән замандагы хикәятләрне сөйләр вә олуг карендәш мәктәптә вакытында дәресләренә никадәр тырышканын вә дәресләрдә беренче чыкканын вә бик күп мәкяфәт[39] алганын сөйләр.

Ата вә аналарының тәрбиясендә ир туганнар илә кыз туганнарының бергә үткәргән минутлары никадәр татлы булыр! Адәм терек булган мөддәттә[40] һәр заман атасының йортын тәмам сагынмаклык берлә исенә төшерер. Ул урында бөтен йорт җәмәгате бергә җыелган вакыт бер-берсен артык сөйгәнлекләре сизелер. Аһ! Сагыначак бер урыннары, суыктан сакланыр өчен кияр киемнәре, тамакларын туйдырыр өчен ашар икмәкләре булмаган фәкыйрьләрнең вә балаларының хәлләренә каралса, никадәр кызганыч бер хәлдә күренерләр. Аталары булмаган үксез

---

[38] Рия – бер эшне кешегә күрсәтү өчен генә эшләү; икейөзлелек.
[39] Мәкяфәт – бүләк, мактау.
[40] Мөддәт – вакыт, ара, срок.

вә ятим балалар никадәр бәхетсезләр, кызганыч вә аяныч хәлдәдерләр. Ханымнар, ата-анагыз терек булганы өчен никадәр бәхетле сез! Гаҗәбән бу тугры сакчыларыгызны озак вакыт кулыгызда тота алырсызмы?

*Сөальләр:*
Кыштан бәхәс итегез.
Хозурларын, читенлекләрен сөйләгез.
Нинди балалар өчен читен булганын сөйләгез.

## *XIV. Кардан адәмнәр*

Кар яуган чакта бик хозурланамын. Ак вә җиңел булган берничә кечкенә-кечкенә кар кисәкләренең һавада очышканын күрүдән артык хозур бернәрсә булмас. Китәләр, киләләр, әйтерсең бергә уен уйныйлар.

Ир туганнарым да карларны бик сөяләр, барлык югарыда сөйләгән сәбәп өчен генә түгелдер.

Зур-зур кеше, хайван сурәтләре ясарлар, яки туплар ясап, бер-берсенә атып уйнарлар. Бу манерда кар тубы сугышы ясыйлар. Кайсы вакытта араларыннан берсе яраланыр. Бу уеннан бик хозур табарлар. Ләкин мин үзем бу фикердә түгелмен. Кар нәрсәдер?

Сөекле кызым, күктә бер ары, бер бире йөреп тормакта булган болытларны күрәсезме? Менә шул болытлар һәммәсе сулардан, диңгезләрдән күтәрелгән пардан булган. Җәй көннәренең һава җылы вакытта шул су өсләрендә төтен кеби күтәрелгән парлар югары күтәрелеп, салкын һавага җитә дә, су тамчысына әверелә, чөнки әгәр дә пар, салкын бернәрсәгә тисә, хәзер үк су була. Менә шул болытлардагы тамчылар үзләренең авырлыклары сәбәпле, җиргә төшәләр, күктән төшә торган сулар өстеннән күтәрелгән пардан хасил булган тамчыларга яңгыр дип әйтәләр. Әмма кар исә шулай ук җирдән күтәрелгән парлардан хасил була. Ләкин җирдән күтәрелгән парлар, кыш көннәрендә күккә күтәрелеп, салкын һавага тию илә тамчыга әверелеп өлгерә

алмыйча, шул пар көенчә туңа да, җиргә әллә нинди бик күркәм рәвештә йолдыз кеби яки акча кебек булып, очып-очып төшәләр. Менә шул җирдән, сулардан күтәрелгән парлар, бик салкын булганлыктан, тамчы булып әверелә алмыйча, пар көенчә туңып җиргә төшүләренә «кар ява» диеп әйтәләр.

Кар ява башлагач, тышта бик салкын булганлыктан, бөтен сулар туңалар. Алай булса да, мәмләкәтләребездә кар җирдә бик аз вакыт торыр, кояш яктысы берлә эрер. Таулы мәмләкәтләрдә болай түгелдер. Мәсәлән, Пруссия тирәләрендә булган Кишиш таулары язын вә кышын тоташ кар берлә өретелгән кеби, Альп дигән таулар берлә Пәйрәнә[41] тауларының вә башка биек тауларның югары түбәләре кар берлә өретелгән, эсселек сизелгән вакытта, күбрәк зур бер кар кисәкләре, таулардан кубып, елгаларга йөгереп төшәр. Бу еректан карап тамаша кылырга бик кызыклы бер нәрсәдер. Якыннан каралса, зур казаларга сәбәп булыр.

Русиядә җирне ничә айлар кар каплаган вакытта сәяхәт итмәкче яки хозур өчен йөрмәкче булсалар, арба зурлыгында бер кавым чаналар тотарлар ки, болар ат берлә тарттырылырлар. Кар вә боз өстендә шуарлар, бер табанлы чана берлә күп вә ерак җирләргә йөрерләр. Боз бик катылангач, күп адәмнәр аякларына коньки киеп, боз өстендә шуарлар. Бу алар өчен зур бер хозур булыр.

Коньки берлә боз өстендә шуа башламас борын, бик сакланырга кирәк. Чөнки боз яхшы туңмаган булса, ватылып, коньки берлән шуучылар һәлак булырлар. Кечкенә кызлар ир туганнарын сакланып йөрергә, бигрәк тә коньки берлә шумаска кушарга кирәк.

Кар чиксез файдалыдыр: җирне яңгырдан да яхшырак чылатыр, һавада тузан көенчә булган вә үләнне җирдән чыгара торган нәрсәләрне хави булыр[42], меңнәрчә зарарлы чебеннәрне үтерер, кар үзе гаять суык була торып, җирне суыктан саклар.

---

[41] Пәйрәнә – Пирин.
[42] Хави булу – эченә алу.

Кыш артык хәтәрсез, бары гаять читен авырулардан саналган томау вә суыктан кул-аякларның ярылу вакытыдыр. Аларга сабыр илә түзеп, мөмкин кадәр тиз үткәрергә тырышырга кирәк. Томаудан асатлык берлә котылыр өчен, үзен бик җылы тотарга кирәк, юкә чәчәге вә чәй кеби күкрәккә шифа бирүче нәрсәләр эчәргә кирәк. Әгәр мөмкин булса, бик яхшы тирләргә тырышырга кирәк. Кул вә аяклар ярылуы өчен иң яхшы дару – авырткан җирләрне глицерин берлә уарга кирәк. Бу авыруга сәбәп булган нәрсә – куллар берлә аякларны эсседән суыкка, суыктан эссегә чыгару яки кулларны вә аякларны бер мәртәбә суык, икенче мәртәбә җылы су берлә юмактыр. Күбрәк бу авыру, кулларыбыз туңмасын дип, һәрвакыт җылы су берлә вә кайсы вакытта, онытып, суык су берлә юган кешеләр берлә мәктәп балаларына пәйда булыр. Шуның өчен кулларны гаять туңган вакытта эссе утка якынлаштырмаска кирәк яки бик эсселәнгән вакытта каты суыкка чыкмаска кирәк.

*Сөальләр:*

Болытлар нәрсәдән чыгар?

Яңгыр нәрсәдән булыр?

Кар нәрсәдән булыр?

Файдасы нәрсәдер?

Коньки берлә шумак ничек булыр? Вә моның илә шуучыларга ничек сакланырга кирәк?

## *XV. Кайнар пирог теләүче бармы?*

Бер кечкенә шәһәрнең ачыклык булган бер урынында, зур агачларның күләгәсендә бер кавем балалар уен уйныйлар имеш. Фәкыйрьләрдән бер хатын улы Гафиф илә кызы Гафифәне йөртер өчен, шул урынга китмеш. Бу ике бала никадәр өсләренә начар кием кигән булсалар да, куллары вә битләре гаять чиста, үзләре гаять матур вә чиксез тәрбияле имеш. Уенчыклары булмаганнан ике туган туфрактан бер кавем пироглар ясамышлар вә мичкә

куйган булып, ара-тирәдә: «Кайнар пирог эстәүче[43] бармы?» – дип кычкыралар имеш. Берничә адәм читтәрәк гаять гүзәл киенгән вә яннарында (нянька) караучылары булган дүрт-биш данә кечкенә ханымнар туп берлә уйныйлар, баудан атыналар имеш.

Туп кинәттән ясаган пирогларның өстенә килеп төшмеш. Вә Гафифә аны алып караганнан соң, атмакчы булмыш, ләкин атарга торганда, вак ханымнардан берсе килмеш вә тупны Гафифәнең кулыннан тартып алганнан соң, аңа әдәпсезлек берлә: «Тупны миңа бир! Без сезнең берлә уен уйнамыйбыз!..» – димеш. Бу сүзләр өчен Гафифәнең анасы бик кайгылы булмыш вә сөекле кызының ул кечкенә ханымнар тарафыннан кагылганын күреп, күзләре яшь берлә тулмыш. Кызына әйтмеш ки: «Балам, кил, ул кечкенә ханымнарның янына барма, алар сине яратмыйлар, чөнки шыксыз син, алар кебек матур түгелсең!».

Шул вакытта янә бер кавем ханымнар да, хозур кылыр өчен, кырга чыкмышлар, үтеп барган вакытта боларга очрамышлар. Эчләреннән бер ханым кечкенә ханымның эшләгән эшен күрмеш вә Гафифә анасының сөйләгән сүзләрен ишетмеш. Фәкыйрь хатынның янына барып, күңелен тапканнан соң, Гафифә берлә кечкенә ир туганы Гафифне сөймеш вә аларга кәнфитләр бирмеш. Соңыннан кечкенә тәрбиясез ханымның янына барып: «Бу сәгатьтә бик зур гаепле булдың, кызым. Синнән бигрәк тәрбияле, бигрәк гакыллы булган баласын хурлап, бу мескен ананың күңелен калдырдың. Шуны белегез ки, фәкыйрь баласы булып, гүзәл вә чиксез тәрбияле бер кечкенә кыз, бай булып, тәкәббер, тәрбиясез, каршы булган бер кечкенә ханымнан бигрәк артык сөелер», – димеш. Мәгәр бу сүзләрне сөйләгән ханым ул тәрбиясез кечкенә ханымның анасы имеш.

Анасының бу сүзләрен ишеткәч, кечкенә ханым чөгендер кеби кып-кыз булмыш, эшләгән кабахәтлеген аңламыш, вә йөгереп Гафифәне үбеп, аның берлә татуланмыш.

[43] Эстәүче – теләүче.

*Сөальләр:*

Кечкенә ханымның Гафифәгә каршы кылган эше өчен ни әйтерсез?

## *XVI. Көнчелек*

Ир туганнары вә кыз туганнары булган балалар бик бәхетле-ләрдер, бергә уен уйнарлар вә бергә йөреп, хозур кыла алырлар. Ир туганнар берлә кыз туганнар иң яхшы иптәшләр вә Җәнаб Хакның безгә биргән иң ышанычлы, иң тугры дусларыбыздыр.

Бер-берсе берлә артык тату торган, бер-берсен сөйгән, көнче булмаган ир туганнар берлә кыз туганнардан күңелгә хуш килми торган һичнәрсә булмас. Шулай ук тату тормый, һәрвакыт бер-берсе берлә кычкырышкан, күңелләре бозык булган, бер-берсенең йөзенә акырган ир туганнар берлә кыз туганнардан да артык күңелсез һичбер нәрсә булмас. Болар җүнсезләрдән вә ата-аналарының өметсезлекләренә сәбәп булырлар.

– Балам, иптәшләрегезне бер матур кием кигән көенчә күрсәгез нишләрсез?

– Бик шат булырмын, чиста йөргәне вә матур киенгәне өчен тәбрик кылырмын.

– Гакыллы торганы өчен үзенә бер яхшы нәрсә бирсәләр яки бернәрсә сатып алсалар, янә шат булырсыңмы?

– Һай-һай, шиксез, мин дә аның берлән бергә шатланырмын, шатлыкны урталай бүлермен.

– Бик яхшы, балам, бу эш ару күңелле булганыгызны бел-дерер. Адәм һәрвакыт сөйгән кешеләренең вә хәтта сөймәгән кешеләренең бәхетле булуы өчен шатланырга тиеш.

Моның хилафынча[44] булганнар көнчеләрдер, хөсет ягъни көнчелек бөтен кимчелекләрнең иң зурыдыр; бу кимчелек үзенә сәбәтлән[45] булган кешеләрне куркынычлы бер сурәттә бәхетсез кылыр, хурлыкка төшерер.

---

[44] Хилаф – кире, каршы.

[45] Сәбәтлән – караган, беркетелгән.

[…]

Кардәшемнең баласы Нажия һич көнче түгелдер. Никадәр хуш холыклы кыз икәнен белсәгез! Анасы, ир туганнары яки кыз туганнары аны сөйгән, иркәләгән вакытта бик шат булыр, ул да барып аларны кочаклар, сөяр.

Конфет яки җимеш өләшкән вакытта, кардәшенә бирелгән алманың үзенекеннән зур яки кечкенә булганын вә үзенә бирелгән конфет кызыл буласы урынына ак булганын һич уйга алмас.

Мондый эшләрне нечкәләрлек кадәр ахмак бала булуына тугрысы һич ышанмас. Соңыннан мондый балалар бер-берсе берлә яхшы бер сурәттә уйнарлар.

Әлхасыйль[46], ничә иптәшләрендә үзенекеннән матуррак уенчыклар күрсә, аның өчен аларны көнләмәс вә мин дә диеп, ул уенчыклар берлә уйнарга эстәмәс[47]. Ата вә анасы вә хәлфәсе аз сөюендә һич көнләшмәс, сөекле, яхшы, тырыш вә итагатьле[48] балаларны бертигез сөйгәннәрен белер. Инде бер ананың унике баласы булса, ялгыз бер баласы булган ана баласын никадәр сөйсә, шулай ук унике бала анасы да үзенең балаларын бертигез сөяр.

*Сөальләр:*

Ир туганнарга вә кыз туганнарга ничек булырга кирәк?

Нажия көнче булмаганын ничек белдерер?

Ата-анасы, ир туганнары вә кыз туганнарына сөекле булыр өчен ни эшләргә кирәк?

---

[46] Әлхасыйль – җыеп әйткәндә.

[47] Эстәү – теләү.

[48] Итагатьле – күндәм, сүз тыңлаучан.

## *XVII. Җылыну ысулы*

– Сөекле Сәгъдиям! Һава суык булса, ни берлә җылынырсың?

– Утын берлә җылынырмын.

– Дөрес, балам.

Шулай кайсы мәмләкәтләрдә ялгыз утын берлә генә җылынырлар, ләкин башка бәгъзе кавемнәр ташкүмер яки гадәти күмер яндырырлар.

Ягыла торган нәрсәнең иң яхшысы, иң кирәклесе булган утынны танырсыз. Аны сөйләү лязем түгелдер. Алай да сезгә күмердән бәхәс итәмен. Күмерне, ягъни ялкын чыгармый торган янган утынны, күмерчеләр агач ботакларын яндырып ясарлар. Менә күмер берлә анагыз аш пешерер вә иртә чәй алдыннан сезгә йомырка пешерер. Бу күмерне җирдән чыга торган ташкүмердән аерыр өчен «гади күмер» диярләр.

Бу күмерне мәгъдән[49] күмере, күмер мәгъдәни дигән мәгъдән учагыннан чыгарылыр.

– Алай булса, мәгъдән күмере агач ботакларыннан булмый түгелме?

– Аслан[50], агач ботакларыннан түгелдер, кызым, ләкин бервакытта алар да агач иде. Мәгъдән учаклары җир селкенүдән яки башка сәбәптән җир астында калган бик иске урманнардыр. Пароход машиналарының суын эсселәндерергә яраган бу күмердер вә көймәләрнең чиксез тиз диңгездә йөрүе, поездларның аз вакыт эчендә никадәр юллар йөрүе, иген вә сату һөнәрләренең чиксез алга китүе бөтенләй җир күмере аркасындадыр.

– Кыш көне ашый торган бүлмәдә куык күмере ягабыз. Бу да мәгъдән күмере түгелме?

Хәер, кызым, һава газын чыгарыр өчен мәгъдән күмерен кыздырганнан соң калган туртаны «куык» диярләр. Бу янган вакытта исе вә төтене бик аз булыр. Кайсы мәмләкәтләрдә торф

---

[49] Мәгъдән – руда.

[50] Аслан – һич, һич тә.

та ягырлар. «Торф» диеп күл вә баткаклык төпләрендә җыелган үлән черекләренә әйтәләр. Менә болар да бертөрле начар мәгъдән күмерен мәйданга чыгарыр.

Балалар, һичбер ут берлә уйнамаска кирәк. Бер кечкенә кыз бер салам өеме янында ут ягып уйнаган вакытта бер очкын чәчрәп, саламга кабынуы вә өйгә дә өрелеп, ялкыннар эчендә калып, җуялып китүе сәбәпле, чиксез фәкыйрьлеккә төшкән бер йорт җәмәгатен беләмен. Шуның өчен бу баланың юньсезлеге бөтен йорт җәмәгатенең афәткә төшүенә сәбәп булмыштыр.

*Сөальләр:*
Ни берлә җылынганны сөйләгез.
Гадәти күмерне ничек эшлиләр?
Таш күмере кайдан чыга?
Торф нәрсәдән була?
Балалар уттан ничек сакланырга кирәк?

## *XVIII. Ашчы Нурия*

– Иртәгез хәерле булсын, Мөхсинә ханым-әфәнде!

– Иртәгез хәерле булсын, Сафия ханым! Кәефегез яхшыдыр, иншаллаһ?

– Әлхәмдулиллаһ, шөкерләр кыламын, әфәндем. Сезнең берлә бераз сөйләшер өчен килдем, аннан соң өйгә китеп, сарыф[51] дәресемне өйрәнермен.

– Ай! Сез шулай сарыф дәресе өйрәнәсезме? Мин бу сүздән бәхәс кылынганын күп мәртәбәләр ишеттем. Сарыф ни дигән сүз?

– Туктагыз, сарыф ни димәктер, белмимен. Бары адәм, теленең сарыфын белсә, яхшы сөйләшер вә сүзләрне ялгышсыз итеп язар. Мәсәлән, ашчы Нурия анасына: «Әфәндем, аны шкафы куйдым, паласка себермәге бетердем», – дигән вакытта, сарыф өйрәнмәгәнне белдерер. Чөнки сарыф өйрәнгән булса иде: «Аны

[51] Сарыф – морфология.

шкафка куйдым, паласны себереп бетердем», – дип әйтү кирәк иде.

Нурия ялгышмаенча вә сүзләренең имлясын бозмаенча һичбер сүз сөйләшмәс. Бүген иртә берлән дә әйтә иде: «Кичә анам берлә базарга бардым. Симез ике казлар сатып алдым. Кирәкмәс җиргә биш тиен дә тотмадым».

Сафия ханым, кардәшем! Ләкин: «Бардым, ике казлар сатып алдым, биш тиеннәр тотмадым», – диелсә, нидән ялгыш булыр?

– «Бардым», «сатып алдым», «тотмадым» фигыльләренең фагыйльләре[52] «анам» дигән сүз берлә «мин» дигән сүздер. Шуның өчен фагыйльләр җан иясе булганда, бер фигыльнең ике фагыйле фигыль җәмгы гаиб булып[53] тотылыр. Бары бер фигыльнең берсе гаиб, берсе мөтәкәллим[54] фагыйле булганда, фигыль һәркайсыннан элек булган кешегә ияреп җәмгыләнер. Шуңа күрә, мөтәкәллим мохатиб[55] берлә гаибә вә мохатиб ялгыз гаибкә тәкаддем[56] иткәннән вә ул фигыльләрнең берсе анамга гаиб бер кешедер, вә икенчесе мин ки, мөтәкәллим бер кешедер. Фагыйльләре булганнан, һәркайсының да җәмигъ мөтәкәллим булып сөйләнүе лязем килер. «Ике казлар», «биш тиеннәр» дигән сүзгә килсәк, сан берлә билгеләнгән кәлимәләр һичбер вакыт әдат[57] җәмгъ була алмас. Шуның өчен Нурия: «Кичә анам берлә мин базарга бардык, ике симез каз сатып алдык вә кирәкмәскә биш тиен дә тотмадык», – дигән булса, сарыф кагыйдәләренә ияреп сүз сөйләгән булыр иде.

Күрәсең бит, Мөхсинә ханым, адәм үз теленең сарыфын өйрәнсә, үзе өчен никадәр файдалы була. Югарыда әйткәнемчә, фигыльләрне ничек җәмгъ булып тотылганын өйрәнсәгез, ничек

---

[52] Фагыйль – ия.
[53] Гаиб булу – күз алдында булмау.
[54] Мөтәкәллим – беренче зат фигыле.
[55] Мохатиб – сөйләүче.
[56] Тәкаддем – алга бару, прогресс.
[57] Әдат – кисәкчәләр, кушымчалар.

язылганын, ничек сөйләгәнен белсәгез, һичбер кеше сезне мыскылламас.

– Сафия ханым, Нурия ялгыш сүзләр сөйләгәндә, аннан көләсеңме?

– Юк, һич, чөнки зур кимчелек кылган булырмын. Нуриянең атасы илә анасы фәкыйрьләрдән, аны бик аз вакыт мәктәпкә җибәрә алганнардыр; һичнәрсә белмәсә дә, аны гаепләнмәс. Өйрәнә алырлык булып та, өйрәнергә эстәмәгән[58] кешеләрне мыскыл ителер.

Шуның өчен, Мөхсинә, әгәр син үз теләгеңне дөрес итеп укырга, язарга белмәсәң, сине мыскыл итәрләр.

– Әйе, алай да сине тынычландырыйм, мине һич мыскыл итмәсләр. Чөнки телемнең сарыфын бик яхшы өйрәнермен.

*Сөальләр:*

Ни өчен телебезнең сарыфын өйрәнергә кирәк?

Сарыфны өйрәнмәгән кешене мыскыл итәргә ярыймы?

[58] Эстәү – теләү.

# ЭЧТӘЛЕК

**Кереш.** «Гаиләнең бәхет вә сәгадәтләре хатыннарның гакыллы вә гыйлемле булуларына бакланмыштыр» ..... 3

**I бүлек. ГАЛИМӘТЕЛБӘНАТ БИКТИМЕРИЯ** ..... 7

Галим кызы Галимә ..... 9

Мәгашәрәт адабе ..... 17

Хөснел-васыять ..... 39

**II бүлек. ФӘХРЕЛБӘНАТ СӨЛӘЙМАНИЯ** ..... 45

«Галимә һәм фазыйлә» ханым ..... 47

Гаилә дәресләре ..... 54

Мөгаллимәтел-бәнат: Кызлар мәктәбенә махсус кыйраәт китабы ..... 130

Кызлар тәрбиясе ..... 172

Мөгаллимәтел-бәнат: Кечкенә ханымнарга уку китабы ..... 200

***Муртазина Ляля Раисовна***
***Зиннатуллина Алсу Анваровна***
*(составители, авторы введения и биографических статей, примечаний, научно-справочного аппарата)*

**ТАТАРСКОЕ ВОСПИТАНИЕ:**
**Вопросы семейного воспитания в трудах**
**Г. Биктимирии и Ф. Сулеймании**

*на татарском языке*

*Научное издание*

Оригинал-макет – *А.Р. Тухватуллина*
Подписано в печать 15.12.2021 г. Формат 60×84 $^1/_{16}$
Усл. печ. л. 14,5 Тираж 100 экз.

Отпечатано с готового оригинал-макета
в типографии ООО «Фолиант»
г. Казань, ул. Профсоюзная, 17в
Тел.: (843) 212-52-25; e-mail: foliantkazan@mail.ru

**Сайт**
**Института истории**
**Академии наук РТ**
**Татаровед.рф**